АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
им. Г. ИБРАГИМОВА

**Р. Т. САФАРОВ**

# ТАТАРСКО-РУССКИЙ СЛОВАРЬ ВОЕННОЙ ЛЕКСИКИ

КАЗАНЬ • 2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Р. Т. СӘФӘРОВ**

# ТАТАРЧА-РУСЧА ХӘРБИ ЛЕКСИКА СҮЗЛЕГЕ

КАЗАН • 2017

**УДК 81′374.822**
**ББК 81.2Тат-4**
**С 24**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

«2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре
һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү
һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында
нәшер ителә

**Фәнни редакторлар:**

филология фәннәре докторы, доцент **А. Ә. Тимерханов,**
филология фәннәре кандидаты **Ф. Ф. Гаффарова**

**Бәяләүчеләр:**

филология фәннәре докторы, профессор **Г. Х. Гыйләҗетдинова,**
филология фәннәре кандидаты **И. Җ. Едиханов**

**Сәфәров Р. Т.**
**С 24** Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге / Ринат Сәфәров. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 112 б.
ISBN 978-5-93091-222-7

Сүзлек сугыш тематикасы белән бәйле 1000 нән артык лексик берәмлекне эченә ала. Материалның күпчелеген иске әдәбиятта, мәкаль-әйтемнәрдә, тарихи романнарда чагылыш тапкан хәрби сүзләр тәшкил итә. Рус теле аша кереп, хәзерге татар телендә үзгәрешсез кулланылган хәрби терминнар бик чикле күләмдә генә бирелде.

Сүзлек тел белгечләре, тарихчылар, музей хезмәткәрләре, тәрҗемәчеләр, журналистлар өчен файдалы белешмәлек булыр дип көтелә. Ул гади укучының игътибарын да җәлеп итәргә мөмкин.

УДК 81′374.822
ББК 81.2Тат-4

**ISBN 978-5-93091-222-7**

© Сәфәров Р. Т., 2017
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017

## КЕРЕШ СҮЗ

Чордан чорга күчкән саен халыкның яшәешендә яңадан-яңа предметлар, процесслар, үзгәрешләр барлыкка килә, кичә булмаган әйберләр бүген мәйданга чыга. Бу яңалыклар халыкның телендә яңа сүзләр, гыйбарәләр тудыра, я булмаса башка телләрдән алынган сүзләр кулланылышка керә. Мисал өчен, күпләп нефть чыгарыла башлагач һәм нефть сәнәгате үсеш алгач, шушы өлкәгә карган меңләгән термин ясала. Соңгы ике дистә ел эчендә мәгълүмат технологияләренең ургылып алга китүе нәтиҗәсендә, төрле аппаратура, программалар, детальләрне белдерә торган бик күп терминнар барлыкка килде. Аларның күбесе башка телдән алынма булса, араларында калька һәм татар теленең үз нигезендә ясалганнары да шактый.

Телебездә бик борынгы заманнардан бирле сакланып килгән сүзләр катламы да бар: туганлык атамалары, тән әгъзаларын белдергән сүзләр, кеше көнкүрештә еш кулланган әйберләрнең исемнәре һ. б. Шундыйлар рәтенә хәрби лексика да керә. Бик күптәнге чорларда формалашып, һәр дәвердә яңа берәмлекләргә байый-байый, хәзерге татар телендә хәрби тематикага бәйле лексик система формалашкан.

Еш кына матур әдәбиятта да, фәнни хезмәтләрдә дә борынгы һәм Урта гасырларга караган хәрби атамаларны кулланганда берникадәр буталчыклык, хәтта ялгышлар да күзәтелә. Шуңа күрә бу өлкәгә нисбәтле лексиканы үз эченә алган һәм кызыксынучыларга җыеп, туплап, системалы

нигездә тәкъдим иткән яңа бер сүзлеккә күптәннән ихтыяҗ бар иде инде.

Бу типтагы элегрәк нәшер ителгән әдәбиятка күз салсак, иң башта татар теле чыганак тел итеп алынган сүзлекләрнең гомумән булмавын ачык күрербез. Башка белешмәлекләргә килгәндә, беренче чиратта, 1926 елда басылып чыккан «Кыскача русча-татарча сугыш сүзләре тылмачы» («Русско-татарский словарь военных терминов (толмач)») турында әйтеп китәргә кирәк. Бу сүзлек хәрби өлкәгә караган лексиканы тәртипкә салу, системалап бирү эшендә тәүге тәҗрибә булган. Аны төзүгә этәргән төп сәбәпләрдән XX гасырның беренче чирегендә татар хәрбиләренең русчаны яхшы белмәүләре, уставлар һәм шуныңише хәрби документларны татарчага тәрҗемә итүдәге төрлелек, бу чорда шактый гына хәрби газеталарның нәшер ителүе һәм башка шундый факторларны күрсәтергә була. Сүзлекнең уңай һәм әһәмиятле сыйфаты анда туган телебез нигезендә терминнар ясау тәҗрибәсе өчен бүген дә игътибар итәрлек мисаллар теркәлүенә бәйле.

Р. А. Мөгыйновның 2000 елда нәшер ителгән «Русча-татарча хәрби терминнар сүзлеге» («Русско-татарский словарь военных терминов») татар теленең хәрби лексикасын системалаштыруда иң җитди хезмәтләрдән берсе. 8 меңгә якын лексик берәмлекне эченә алган сүзлектә автор, русча терминнарга аларның татарча тәңгәлләрен тәкъдим итү белән генә чикләнмичә, аңлатмалы сүзлеккә хас рәвештә байтак кына сүзләрнең мәгънәләрен дә биргән. Шулай да, татарча лөгатьлегендә электән кулланылган һәм язма чыганакларда теркәлеп калган бик күп сүзләрнең чагылыш тапмавы бу белешмәлекнең тулы булмавына ишарәли.

Хәрби тематикага бәйле махсус лексикографик чыганаклар менә шушы сүзлекләр белән чикләнә.

Укучы игътибарына тәкъдим ителгән яңа сүзлектә татар теле беренче планга чыгарылды. Урта гасырлар әдәбиятында, мәкаль-әйтемнәрдә, тарихи романнарда чагылыш

тапкан хәрби сүзләрне туплап бирү максат итеп куелды, шул сәбәпле, рус теле аша кереп, хәзерге татар телендә нигездә үзгәрешсез кулланылган хәрби терминнар бик чикле күләмдә генә теркәлде. Шулай ук тарихи романнар язган авторлар тарафыннан әсәрләренә борынгылык колориты бирү өчен кертелгән сүзләргә дә сак якын килende. Төп игътибар борынгы, искергән һәм кулланыштан чыгып бара торган лексик берәмлекләргә юнәлтелгәнлектән, белешмәлек хәрби терминнарның тулы ике телле сүзлеге булуга дәгъва кылмый.

Сүзлеккә нигездә хәрби кораллар һәм корал төрләренең атамалары, аларның аерым өлешләрен, детальләрен, саклау савытларын белдергән сүзләр; саклану киемнәре һәм аларның аерым өлешләрен тәгъбирләгән берәмлекләр; төрле хәрби берләшмәләр, сугышчыларның исемнәре; гаскәр башлыкларының атамалары; сугыш мәйданының аерым эпизодларын, хәрби символларны белдергән берәмлекләр; әсирләрне тасвиралуга бәйле лексика һәм хәрби өлкәгә караган башка шундый сүзләр алынды. Кулланылышындагы үзенчәлекләрен күрсәтеп, мәгънәсен тулырак һәм төгәлрәк ачу максаты белән һәр сүзгә диярлек мөмкин булган кадәр күләмдә иллюстратив материал бирелде.

Сүзлеккә карата булган барлык файдалы киңәш-фикерләрне, төзәтмәләрне түбәндәге адреска җибәрергә мөмкин:

420111, Казан шәһәре, К. Маркс ур., 12 йорт, 6 бүлмә
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтының лексикография бүлеге
E-mail: iyali.anrt@mail.ru

## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

Сүзлектә баш сүзләр – вокабулалар – үзләренә караган материал белән бергә сүзлек мәкаләсен тәшкил итәләр. Сүзлек мәкаләсе түбәндәге өлешләрдән тора:

1) баш сүз;

2) сүз төркеме тамгасы (бу тамга вокабуладагы сүз берничә сүз төркеменә кергән очракларда гына куелды);

3) баш сүзнең русчага тәрҗемәсе (тәрҗемәләре);

4) мисаллар;

5) компонентлары аерым язылган кушма яки тезмә сүзләр, сирәгрәк – тотрыклы гыйбарәләр һәм аларның русчага тәрҗемәләре;

6) мисаллар.

Сүзлектә баш сүзләр калын баш хәрефләрдән алфавит тәртибендә урнаштырылды.

Компонентлары аерым язылган кушма яки тезмә сүзләр баш сүздән соң ояга урнаштырылып, яңа юлдан бирелде. Мондый сүзләр берничә булган очракта, алар алфавит тәртибендә теркәлде.

**КЫЛЫЧ** меч, сабля; шашка, палаш, шпага. *Аман кычкырганга кылыч юк.* Мәкаль. <…>

**кәкре кылыч** сабля. *XIII гасырның беренче чирегендә каяндыр Кытай чикләреннән кубып чыккан бихисап татар-монгол явы бәләкәй атларда, кәкре кылычларын уйнатып, кара болыттай ябырылып киләләр дә Болгарны да яндырып, таптап узалар.* Ә.Еники

**кылыч гәүдәсе** клинок меча

**кылыч йөзе** острие меча. *Без барыбыз да үткен кылыч йөзендә йөрибез, Лександр.* М.Хәбибуллин

**кылыч сабы** эфес, рукоятка меча. <…>

**кылыч сырты** тыльная сторона меча. *Кенәз Василий ханның башына кылычының сырты белән сукты.* М.Хәбибуллин

**кылычтан кичерү (үткәрү, уздыру)** предавать/предать мечу. <…> *Туганымнан бирле мин болгарларга каршы астыртын эш алып барам, туганымнан бирле мин кылыч күтәрергә җай көтеп тордым.* Н.Фәттах

**туры кылыч** меч. <…> *Уң кулларына алар [урыслар] озын туры кылыч тотканнар, бил каешларына балта белән пычак такканнар иде.* Н.Фәттах

Сүзләрнең лексик мәгънәләре бер-берсеннән җәяле гарәп саны белән аерылды.

Тәрҗемәләрдә бер-берсенә якын синонимнар арасына – өтер, мәгънәләре ераграк торган сүзләр арасына нокталы өтер куелды.

Башка сүз төркеменә күчеп ясалган сүзләр яки изафә белән килеп рус телендә сыйфат буларак тәрҗемә ителгән исемнәр нокталы калын цифрлар белән аерылды.

**БУЛАТ 1.** 1) булат (*старинный сорт стали*). 2) меч. <...>. **2.** булатный. *Булат пычак кынсыз булмас.* Мәкаль

Мәгънәне тулырак ачу максаты белән кайбер очракларда җәяләр эчендә русча кыска гына аңлатма бирелде, кайбер очракларда минималь контекст китерелде.

**ӘМАНӘТ** аманат *(заложник у врагов, у властей и т.д.)*

**ҖӘЯЛЕ** имеющий лук; вооружённый луком; *җәяле сугышчы* воин, вооружённый луком

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*җый.* – җыйма мәгънәдә
*и.* – исем
*к.* – карагыз
*күп.* – күплек сан
*с.* – сыйфат
*ф.* – фигыль
*чаг.* – чагыштырыгыз
<…> – төшереп калдырылган текст

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | |
|---|---|---|---|
| Аа | Зз | Пп | Чч |
| Әә | Ии | Рр | Шш |
| Бб | Йй | Сс | Щщ |
| Вв | Кк | Тт | ъ |
| Гг | Лл | Уу | Ыы |
| Дд | Мм | Үү | ь |
| Ее | Нн | Фф | Ээ |
| Ёё | ң | Хх | Юю |
| Жж | Оо | Һһ | Яя |
| Җҗ | Өө | Цц | |

# А

**АВАНГА́РД 1.** *и.* авангард. *Альп походында – авангардта – иң алдан барган штурм отрядындагы солдатларның яртысыннан күбесе татар егетләре иде.* З.Зәйнуллин. **2.** *с.* авангардный. *Авангард көчләр* авангардные силы

**АЗАМА́Т 1.** *с.* храбрый, мужественный, отважный, бесстрашный, доблестный, смелый *(богатырь, боец, защитник родины, мужчина). Азамат ирнең баласы өстенә яу килсә дә моңаймас.* Мәкаль. *Азамат ир Туктамыш Килә җитеп килгәндә Ул туксанбер тик торды...* Дастан. *Урман авызын Ходайкол угланның азамат егетләре саклый.* М.Хәбибуллин. **2.** *и.* юноша, мужчина (20–30 лет), добрый молодец. *[Акын] Арысланбайга карап: – Атаңның өлкәнлеге даланы каплады, үзеңнең яшең аз булса да, маңлаеңда акыл нуры балкый, йөрәгеңдә азаматлар куәте бар, – дип озак җырлады.* Г.Ибраһимов

**АЗАМАТЛЫ́К** храбрость, смелость, мужественность, отвага, бесстрашие, доблесть. *Җегет булгач, азаматлык белән дан чыгарды.* Г.Ибраһимов

**АЗЫ́К** *к.* **азык-төлек**. ...*Сугышчылар һәм атлар өчен азык әзерләнде, кирәге чыкса, җиңел каеклар, сугыш көймәләре көйләп куелды.* Ф.Бәйрәмова

**АЗЫК-ТӨЛЕ́К** 1) провиант, провизия. *Меңләгән кешене сыйдыру өчен көймәләр күп кирәк иде, корал, азыктөлекне дә санап, йөздән артык струг-көймә кирәк иде Себер явы өчен.* Ф.Бәйрәмова; 2) корм, фураж (*для скота*)

**АЙБАЛТА́** бердыш, секира; алебарда. *Хан боерыгы үтмәде, Хан боерыгы үткәндә Тәңредән узып китмәде – Атага*

*җиткән айбалта Баласына җитмәде.* Дастан. *[Җанбай:] Туктамыш башын чабып өзгән тулгамалы айбалта кайда?* Ю.Сафиуллин. *Көтмәгәндә урал буйларында татарларның атлы гаскәре күренде, алар барысы да кылыч һәм сөңге белән коралланган, билләренә айбалта һәм чукмарлар аскан, һәрберсенең җилкәсендә ук-санайлары, җәя-садаклары беркетелгән иде.* Ф.Бәйрәмова

**АЙБАЛТАЛЫ́** вооружённый секирой, бердышом. *Җәллад булган ул баланы Айбалталы Дөрмән би Кулын кулдан каерып, Туктамыш ханга баш орды...* Дастан. *Малюта аны юатмады, ела-ела, күз яше кайгыны юа, дия-дия капкада торучы айбалталы сакчылар яныннан узды.* М.Хәбибуллин

**АЙКА́У** махать/махнуть, взмахивать/взмахнуть. *Йолдыз кашка җирән атта, Айкап кылычын, Килә алдан татар егете Кош кебек очып.* Ф.Кәрим. *Тимери абзагызның үзенең дә заманында ат уйнатып, кылыч айкап, дошман башларын тәгәрәткән чаклары бар иде...* Г.Бәширов

**АЙПЫЧА́К** боевой нож в форме полумесяца. – *Әй Дөрмән би, Дөрмән би, Айбалтаңны тот, – диде. – Айпычагың так, – диде. – Котлыкыя ялган бине Муйнын ора чап! – диде.* Дастан

**АЛА́Й** полк. *Өреккән куйдай урданы Алаеннан бастырып, Тоякка салып таптады.* Дастан. *Анна ул җәнүбкә табаран ташланылды, рус гаскәрләре берлә Багдад астында сугышта торган инглиз гаскәре берлә кушылу хәрәкәтендә аның алаена зур йөк йөкләнеләчәк булды.* Г.Исхакый. *Бер көзне, моннан егерме еллар элек, сөннәр көнчыгыштагы урман кешеләренә каршы яу чапканда, Банлу да үзенең ярты меңлек алае белән тархан чирүенә кушылды.* Н.Фәттах. *Шаһгали ханның алае зур түгел, атакай.* М.Хәбибуллин

**АЛА́Й БАШЫ** командир полка. *Алай башы тәгин углан, качакларга үз артыннан иярергә кушып, җәяүләп, якындагы сөзәк калкулыкка менеп китте.* Н.Фәттах

**АЛАМА́Н** наёмное войско; ополчение. *Аны әйтеп Шаһ Тимер, Аламанын торгызды.* Дастан. *[Әмир Бырлас Шаһ Ти-*

*мер] Уңына торып бер бакты, Сулына торып бер бакты, Йөзе сүнеп каралган Аламанын күргәндә, Калтырап иман укыган Муллаларын күргәндә Эче янып ут булды, Тышы катып боз булды.* Дастан

**АЛАПА́** 1) военный трофей; премия воину за доблесть в бою *(одежда, меч и т.д.). Алапасы олы, кабыргасы коры.* Мәкаль; 2) жалование военнослужащим. *Эш күрсәткән егетнең Алапасын язган мырзамын.* Дастан; 3) компенсация, пенсия

**АЛАФА́** *к.* **алапа**

**АЛӘ́Т** 1) орудие, инструмент; 2) оружие. *Сугышканда хәзер ике төрле аләт белән сугышалар.* Г.Газиз

**АЛГАСКӘ́Р** *к.* **авангард**. *Дошман явы күренсә, алгаскәр чит яу килгәне турында белгертсә, дәһшәт килүе турында төп гаскәргә хәбәр салыр өчен, манарадагы учакны ягып җибәрергә кирәк.* Р.Батулла

**АЛДАМИЯ́Н** нарукавник (*доспехов*). *Алдамияным ал[ып] килче!* Дастан

**АЛПАВЫ́Т** высшая военная степень (*в Казанском и Касимовском ханствах*)

**АЛПАГЫ́Т** рыцарь, воин-богатырь, исполин; *чаг.* **алпавыт**. *Анда әйтте соргавыл: – Балта салсаң, башы каерылмас, Болгап кылыч чапсаң, муйны биртелмәс, Бәһатырлар батыры, Алпагытлар Алыбы, Андый ирне бер белсәң, Кара Тиен Йосыф ул булыр.* Дастан. *Болгарларның бу иң атаклы батырлары Чәкән алпагыт иде.* Н.Фәттах

**АЛПА́К** 1) шлем, шишак, чечак. *Аннары әкренләп-әкренләп кораллы ирләрнең тимер алпаклары, ат башлары, калканнар күренә башлады.* Н.Фәттах; 2) доспехи, латы

**АЛПА́Р** рыцарь, богатырь. *Алпарына күрә тулпары.* Мәкаль. *[Хөсрәү] Янә әйтте: «Оялыр ул йөзе көн, Торыйм бераз, чыгар ярга бу мескен. [Шириннең] Бу хәлендә якын бару – бу эшме? Чын алпарга шулай кылу тиешме?»* Котб

**АЛТАТА́Р** револьвер *(шестизарядный). Алтатарның тулысы бер кешене куркытыр, бушы – кырыкны.* Мәкаль.

*Алтатардан, ау мылтыгыннан, берданкадан аткан тавышлар Мәскәүнең үзәк урамнарында да, чат-тыкрыкларында да ишетелеп торды.* Г.Ахунов

**АЛТЫКОЛА́К** булава (*шестилопастная*)

**АЛУ́ 1.** *ф.* 1) захватывать, забирать, брать *(в плен)*; 2) захватывать, занимать, овладевать (*городом*). *Ул арада Сафа Гәрәй атлы гаскәре белән Мөрем каласына яу килә, каланы ала алмый, әмма якын-тирәдәге авылларны туздыра, талый, әсирләр җыеп алып китә.* М.Хәбибуллин. *Себерне дә ала алмабыз, үзебез дә бетәрбез...* Ф.Бәйрәмова; 3) брать, поражать *(об оружии)*. *Уктан да оста алган [ул сугышчы].* М.Хәбибуллин. *Аның атларын ук та алмады, ядрә дә җитмәде, артыннан куучылар да тота алмады.* Ф.Бәйрәмова. **2.** *и.* 1) взятие, овладение, захватывание; 2) поражение (*оружием*)

**АЛЫ́П** 1) великан, исполин; 2) богатырь; витязь; рыцарь. *Алып анадан туар, аргамак биядән туар.* Мәкаль. *Алыпның авыз сөте ат өстендә йөреп кибәр.* Мәкаль. *Үзеңне алып дип белсәң, үзгәне арслан дип бел!* Мәкаль. *Анда әйтте соргавыл: – Балта салсаң, башы каерылмас, Болгап кылыч чапсаң, муйны биртелмәс, Бәһатырлар батыры, Алпагытлар Алыбы, Андый ирне бер белсәң, Кара Тиен Йосыф ул булыр.* Дастан. *Атасы тархан алдында, алып ирләр алдында аның [Албуганың] чын ир дә булып күренәсе килде, шул ук вакытта ул теге кичтәге кебек исереп егылудан да курыкты.* Н.Фәттах

**АЛЫ́Ш** 1) бой, сражение; 2) борьба, схватка. *Атышы атаң башына, алышы кирәк!* Мәкаль. *Китте алыш, китте егып салыш.* Әкият

**АЛЫШУ́ 1.** *ф.* 1) схватиться, вступать в схватку; 2) бороться, тягаться, потягаться. *Алыплар алышмый танышмас.* Мәкаль. *Әйтешкән авыз, алышкан кул.* Мәкаль. *Нәүбәттәге бер Сабан туенда Ходайкол чирмеш батыры Гөякка батырга-батыр чыкты. Кылычтан алыштылар. Җиңде.* М.Хәбибуллин. **2.** *и.* схватка; поединок

**АМБРАЗУ́РА** амбразура. *Ул сулга борылып тыңлаучыларның игътибарын амбразурага җайлап куелган пулемётына юнәлтте.* М.Яһудин

**АМУНИ́ЦИЯ** амуниция. *Менә бүген, кырт кисеп, менә иртәгә махсус амуницияле часть килеп җитәргә тиеш, ди.* Х.Камалов

**А́НТ** клятва, присяга. *Эзмәләләр дә хәрби антларына тугрылыклы булалар, төрле фронтларда сугышып, җиңүгә зур өлеш кертәләр.* Т.Нәҗмиев; *чаг.* **бәйгать**

**ант итү** давать/дать присягу, присягать/присягнуть; *чаг.* **бәйгать бирү**

**АРКАНЧЫ́** воин, вооружённый лассо

**АРКАВЫ́Л** арьергард. *Аркавылдан даулаган Даным калсын, дип идем, Сине тагын алдырдым, – Әләман бул миннән соң!* Дастан

**А́РМИЯ** армия. *Әмма Иван патша аларга бер генә нәрсәне рөхсәт итмәде, ул да булса даими армия тотарга ярамый иде патша кулы астындагы кешеләргә.* Ф.Бәйрәмова

**армиягә алу** призывать (брать) в армию

**армиягә китү** пойти (быть призванным) в армию; вступать в ряды армии

**армиядән кайту** вернуться из армии (со службы в армии); демобилизоваться

**армиядән калу** быть освобождённым от службы в армии; быть непригодным для службы в армии

**даими армия** регулярная армия. *Иван патша Себергә ачыктан-ачык үзенең даими армиясен җибәрә алмый, бу инде бөтен дөнья каршында икенче бер дәүләткә рәсми рәвештә сугыш ачу булыр иде.* Ф.Бәйрәмова

**АРСЕНА́Л** арсенал; *чаг.* **коралханә**. *Авыл тирәли сакчылар куеп, яндырылмый калдырылган арсенал янына килделәр һәм тәрәзәсез өй эчендә булган бөтен мушкетларны, дарыны һәм башка кирәк-яракны атларга төяделәр.* И.Хуҗин

**А́РТ ИЛ** тыл, территория воюющей страны вместе с её населением, расположенная за линией фронта. *Алмыш хан,*

*баштагы уен үзгәртеп, арт ил килеп җиткәнче, үз атларына, кешеләренә бераз ял бирергә булды.* Н.Фәттах. *Барлык арт илгә баш итеп хан үзенең өлкән углы Тәкин угланны калдырды.* Н.Фәттах

**АРТИЛЛЕРИ́СТ** *к.* **тупчы**. *Синнән яхшы артиллерист чыгарга тиеш.* З.Зәйнуллин. *Артиллеристларның күзәтү пункты кыр уртасыннан сузылган траншеяларның уң флангысында, урманга барып тоташкан җирдәрәк иде.* Х.Камалов

**АРТИЛЛЕ́РИЯ** артиллерия. *Безнең командование бу турыда алдан белгәнлектән, немецларның һөҗүме башланудан берничә минут элек, артиллериядән кечле ут ачты.* Г.Әпсәләмов

**АРЬЕРГА́РД** *к.* **аркавыл**. *Шәүкәт үзеннән соң берәүне дә калдырмаска кушып, ярсу йөрәк Фаягөлне бу юлы иң артка, арьергардка куйды, үзе, бераз юл ярырга ниятләп, иң алга басты.* А.Хәсәнов

**АТА́КА** атака, наступление. *Шулай да, ату тынгач, безнең пехота атакага алга ыргылды.* Х.Камал

**атакага бару** идти в атаку (наступление), атаковать. *Халыкны әйтәм, роботмени, бет җаннар белән атакага барып кара инде син!* Ф.Дәүләтбаев

**атакага керү** бросаться в атаку

**атака ясау** атаковать. *Тик немецлар атака ясамадылар.* З.Зәйнуллин

**АТКЫ́** стрела, которую метают резким взмахом, насадив на конец палки. *Аткыдан йөгерек ук булмас, атсаң күбә бозалмас.* Мәкаль

**АТКЫ́Ч** 1) метательный; 2) огнестрельный

**АТКЫЮ́Ч** вид стрелы с прямой гранью (?). *Каргышым аткыючтан очлыдыр, Кара таптан үтәдер, Сине каргап нитием?* Дастан

**АТЛЫ́ 1.** *с.* конный, кавалерийский *(полк, корпус, дозор, отряд)*. *Ярдәмгә җибәрелгән атлы взводның командиры безнең авылның Нургали булып чыкты!* Т.Гыйззәт. **2.** *и.* ка-

валерист. *Еракта, бер-берсенә сыенып, койма сыман булып торган сөн атлылары күренде.* Н.Фәттах. *Илнең батыр егетләрен кузгатып, туксан атлының башында, Пугачау гаскәренә булышка киткән.* Г.Бәшир

**атлы армия (гаскәр) сугышчысы** конармеец, конник; кавалерист. *Гаодинең төрле яуларда чыныккан атлы сугышчылары, Албуганың чирүе белән беренче мәртәбә очрашкач, үзләре алдында өтәләнгән кешеләрне күреп хәтта аптырабрак калдылар.* Н.Фәттах

**атлы гаскәр** конница, конное войско; кавалерия. *Тимери агай, җае килгәндә, атлы гаскәрдә хәзмәт итүен искәртеп, шул уңайга үзен дә кыстырып җибәргәли иде.* Г.Бәширов. *Ә менә Сөембикә кызын Казанга озатканда өлкән улы Юныс морзаны утыз мең атлы гаскәре белән Казан тарафына юллар.* М.Хәбибуллин. *...Бар дөньяны тетрәткән атлы гаскәрне татарлар тоткан...* Ф.Бәйрәмова

**атлы гаскәри** *к.* **атлы армия (гаскәр) сугышчысы**. *Кимендә ун мең атлы гаскәри бу айда ук Мәскәүгә җибәрелергә тиеш, аннары тагын...* М.Хәбибуллин

**атлы гвардияче** конногвардеец

**атлы сугышчы** *к.* **атлы армия (гаскәр) сугышчысы**. *Юныс бәктә ким куйганда ун-унбиш мең атлы сугышчы, һәммәсендә дә җайдак ат.* М.Хәбибуллин

**АТУ́ 1.** *ф.* 1) стрелять, выстрелить, производить (дать) выстрел, бить *(из оружия, орудий)*; палить, выпалить; вести огонь; 2) отстрелять (*сколько*); 3) пускать *(стрелу)*, выпускать *(снаряд, пулю)*. *Ходайколның кулыннан корал төшмәде. Уктан төз атты, кылыч белән орышырга тиң табылмады, сөңгене кеше күзенә ыргытыр, хәнҗәр атар, ике кулына ике чылбырлы чукмарбаш тотып, йөзләрчә дошманга каршы торыр иде.* М.Хәбибуллин. *Кем атта чапты, кем дөяләрдә узышты, кем уктан атты, пәһлеваннар көрәште, чичәннәр дастан әйтте, җырларга теләгән җырлады, биергә теләгән егылганчы биеде.* Ф.Бәйрәмова; 4) обстреливать, расстреливать. **2.** *и.* 1) стрельба, выстрел. *Көймәдәге тупларның куркыныч гөрселдәвеннән һәм мылтыкларның утлы төтеннәр чыгарып шарт-шорт*

*атуыннан тирә-як дер селкенеп торды.* Ф.Бәйрәмова; 2) обстреливание, обстрел; расстреливание, расстрел

**ата башлау** начинать стрелять (палить)

**ата тору** продолжать стрелять

**аткан тавыш (тавышлар), ату тавышы (тавышлары)** стрельба, выстрел, выстрелы; залп, залпы. *Искәрне чорнап торган татарлар, аткан тавышларның якынлыгына шикләнеп, монда килеп җиткәндә, урман эче һәм елга буе мәетләр белән тулган иде инде...* Ф.Бәйрәмова

**ату урыны** стрельбище

**атып алу** пострелять, сделать несколько выстрелов

**атып бетерү** расстрелять (выпустить) всю обойму

**атып җибәрү** выстреливать, выстрелить. *Әмма урыс казаклары иштәкләрнең бу такмаклауларына игътибар итмәделәр, төрле яктан, гөрселдәтеп, урман кешесенә атып җибәрделәр.* Ф.Бәйрәмова

**атып карау 1.** *ф.* пострелять; пристреливать *(новую винтовку)*. **2.** *и.* пристрелка

**атып тору** стрелять, палить *(беспрерывно, из многих оружий)*

**атып төшерү** сбивать *(самолёт из зенитки)*

**атып үтерү 1.** *ф.* застреливать, расстреливать, убивать выстрелом. **2.** *и.* расстрел

**атып яралау** ранить выстрелом; подбить

**АТУЧЫ́** 1) стрелок *(меткий, искусный; из лука, из пистолета)*. *Күп аткан белән атучы булмас.* Мәкаль; 2) отстрельщик (*на охоте*)

**АТЫ́ЛМАУ 1.** *ф.* давать отсечку. **2.** *с.* **атылмаган** нестреляный *(о ружье, гильзе)*. **3.** *и.* отсечка

**атылмый калган** нерасстрелянные *күп. (патроны, снаряды, боеприпасы)*

**атылмый калу** давать отсечку

**АТЫЛУ́ 1.** *ф.* 1) быть выстреленным *(о пуле, снаряде)*, быть выпущенным *(о снарядах, пуле и т.д.)*; быть запущенным *(о стреле, камне, из рагатки и т.д.)*; 2) застреливаться, быть застреленным; перестреливаться, расстреливаться, быть

расстрелянным; 3) *(самопроизвольно)* выстрелить, пальнуть *(о ружье)*; 4) *(о самоубийстве)* застреливаться; *(о многих)* перестреляться. **2.** *с.* **атылган** стреляный
**атылып үлү** застрелиться

**АТЫЛЫШУ́** застреливаться *(о многих)*

**АТЫ́Ш** 1) стрельба, пальба, перестрелка; *Атышы атаң башына, алышы кирәк!* Мәкаль. *Ук атышта, сөңге ыргытышта, кылыч белән чабуда беркем аннан уздыралмый иде.* Н.Фәттах. *Яр буенда атыш, суеш, үтереш дәвам итте, урыслар һәм татарлар бер-берләрен рәттән турыйлар иде.* Ф.Бәйрәмова; 2) стрельба, выстрел, выстрелы; залп, залпы

**АТЫШУ́ 1.** *ф.* стреляться; перестреливаться. *Алышмак бар, атышмак юк.* Мәкаль. **2.** *и.* перестрелка
**атышкан тавыш (тавышлар)** перестрелка. *Авылда мәхшәр башланды. Офицерлар кычкырышуы, атышкан тавышлар, янгын чытырдавы – барысы бергә кушылды.* И.Хуҗин

# Ә

**ӘВЕ́Р** боевой клич, громкий призыв во время боя (*произносится с целью подбодрить товарищей, устрашить врага или обратиться за поддержкой к высшим силам*). *Шунда кайсыдыр арттан кычкырды: – Нәрсә карап торасыз! Әвер!* Г.Бәширов

**ӘДЕРНӘ́** огромный лук *(тетиву которого натягивали несколько человек или при помощи лошади)*. *Кырыгар-иллешәр тиенлек санай йәйәләремез йалан башкортларының унарйигермешәр сумлык әдернә йәйәләрендән артыктыр. Андый әдернә йәйә эссе көндә йигерме-утыз мәртәбәдән артык йарамыйдыр.* Батырша хаты. *Менә зәңгәр төтен чыгарып туплар гөрселдәде, татарлар өстенә ядрәләр шаулап очты, менә әдернә җәяләр киереп тартылды һәм Искәргә таба уклар атылды...* Ф.Бәйрәмова

**ӘЗМӘВЕ́Р** 1) гвардеец в охране трона; 2) великан, исполин; верзила, дылда. *Казаклар, дәррәү кубып, урман әзмәверенә ташландылар...* Ф.Бәйрәмова

**ӘЙТЕШҮ́** *к.* **баз**

**ӘКӘ́** войсковой старшина

**ӘКӘ́Й** 1) войсковой старшина; 2) шапка войскового старшины

**ӘЛӘ́М** знамя. *Шушы үләнлектә хан чатыры. Чатыр яшел төстә, дүрт чатында дүрт казык, һәр казык башында ай сурәте, урта бер җирдә яшел әләм.* М.Хәбибуллин. *Нәкъ әнә шул багана төбенә кызыл әләм сурәтләнгән.* Г.Гыйльманов

**ӘЛӘМӘ́Н** наёмное войско

**ӘЛӘМДА́Р** знаменосец

**ӘЛӘФӘ́** *к.* **алапа**. *Күрә дип, чуралар эш җәфасын мул, Саран өләшмәде әләфәсен ул [Хәсрәү].* Котб

**ӘМАНӘ́Т** аманат *(заложник у врагов, у властей и т.д.)*; *чаг.* **тотык**. *Җитмәсә, Андрейның да, Ярослав III нең дә аманәт булып Бату Урдасында яшәмәгәнлекләре тарихта мәгълүм.* И.Хуҗин. *Ул гынамы, Көнбаш атакай угланнарын Бәһрам баһадирга әманәт итеп биреп калдырган, ә теге батыр егетләрне атасы шаһиншаһ тарафына җибәргән.* М.Хәбибуллин

**ӘМЕ́Р** приказ, приказание, распоряжение, повеление, предписание. *Синең һәр әмереңалар карусыз үтәргә тиешләр, үтәмәсәләр, миңа әйт.* М.Хәбибуллин. *Һәм шушы мәгърур татарга урыс илчесе Рәсәй патшасының үзенә буйсынырга дигән әмерен җиткерергә тиеш иде...* Ф. Бәйрәмова

**әмер бирү** отдавать приказ, приказывать, повелевать. *Улмы, ханбикә Сөембикә шулай әмер бирәме?* М.Хәбибуллин. *Казакларына әмер биргән, алар тиз көннәрдә монда булачак, нидер эзләргә кирәк.* Ф.Бәйрәмова

**әмер итү** повелевать. *Рәсәй патшасы сиңа, Күчем хан, Ядегәр бәк кебек, үзенә буйсынырга әмер итә.* Ф.Бәйрәмова

**ӘМИ́Р** повелитель, правитель. *Рус чыганаклары икенче бер ханның – Хәсәннең, Алтын Урда тәхетеннән төшерелгәч,*

*төньякка качуын һәм үзен Болгар әмире дип игълан итүен язалар.* Р.Фәхретдинов

**Ә́РМЕ** *к.* **армия**. *Фан дигән шәһәрдән падиша әрме белән чыгарга җыена юлбасарларны тотарга.* Риваять

**ӘСИ́Р** пленный, военнопленный, пленник; невольник. *Кузгалып китүгә бишенчеме, алтынчымы көн булды дигәндә, сөн әсирләрен тагын да иркен бер ишегалдына алып кердeләр, җиргә төшерделәр.* Н.Фәттах. *Кич кояш баюга таба тәгәрәүгә, алар әсирләрне туктаттылар, атларын җәйләүгә җибәрделәр.* М.Хәбибуллин. *Котыгай аларның беренче дәрәҗәле әсире иде.* Ф.Бәйрәмова

**әси́р итү (алу, итеп алу)** брать (захватывать) в плен. *Ул гынамы, ике туган урыс кенәзе Василийны әсир итәләр һәм аталары каршына алып кайталар.* М.Хәбибуллин. *Берничәсе генә качып котылды, берничәсен әсир итеп алдык, алар барысы да Искәрдә, бөек хан!* Ф.Бәйрәмова

**әси́р төшү (булу)** попасть в плен. *Ошбу хөкемдар Зөя буендагы сугышта урысларга әсир төшә.* М.Хәбибуллин. *Әсир төшкән халыктан ул бу сарайларның кемнеке икәнлеген белгән иде инде.* Ф.Бәйрәмова

**ӘСИРЛӘ́Ү** брать (захватывать) в плен, пленить

**ӘСИРЛЕ́К** плен, неволя. *Ә әсир төшкән Василий кенәзне исә вәгъдә салымнарына иман әйттереп, әсирлектән азат итә.* М.Хәбибуллин. *Казанны искә төшергәч, Сүзгенең тагы йөрәге кысылып куйды, әсирлектә юкка чыккан әнисе исенә төште, Казан фаҗигасе тагы күз алдына килеп басты.* Ф.Бәйрәмова

**әсирлеккә төшү** *к.* **әсир төшү**. *Ниһаять, Ермак беренче теләгенә ирешә – аның кулына Күчем ханның ясак җыючысы әсирлеккә төшә.* Ф.Бәйрәмова

**ӘФИСӘ́Р** офицер. *Яуны солдат җиңә, даны әфисәргә була.* Мәкаль. *Зонадагы әфисәрләр төсле усал кыланырлармы дип көткән иде дә [Вәлиулла], юк, тыныч сөйләштеләр.* Ф.Яхин. *Янараллар, әфисәрләр дүрәкмени?* М.Мәһдиев

**ӘШКӘ́Р** войско; *чаг.* **гаскәр**

# Б

**БА́Г** узы, оковы, путы *күп.*

**БАГАВЫ́Л** наблюдатель *(например, с наблюдательного пункта, со сторожевой вышки)*

**БАГЫНДЫРУ́** подчинять/подчинить, покорять/покорить. *Товар муллыгы белән түгел, товар кытлыгы белән халыкны багындыру сәясәте Русия дигән патшалыкта борын-борыннан ук дәүләт сәясәте буларак яшәп килгән.* М.Гайнетдин

**БАГЫНУ́** подчиняться/подчиниться, покоряться/подчинить. *Бәгъзеләрнең риваяте буенча, аның дөресрәге ошбу булырга кирәк: бер Николай дигән качкын поляк шунда килеп урнашкандыр, бик батыр, көчле, куәтле, хәйләкәр кеше булган, тирә-як кешеләре аңа күбесе баш биреп, багынып торганнар.* К.Насыйри

**БА́З** богатырский спор, похвальба; вызов на поединок. *Ялгыз сөйләп баз булмас.* Мәкаль. *Атасы баз сөйләгәндә углы кан кояр.* Мәкаль. *Бәхел (үчле) уңмас, баз уңар*. Мәкаль

**БАЙРА́К** 1) знамя, флаг, стяг, штандарт. *[Хан (кычкырып):] Олуг Тәңре! Илемез-көнемезне, дәүләтемез-сөялемезне, халкымызны, бала-чагамызны, байрагымыз, гаскәремезне, мал-туарларымызны афәт-бәлаләрдән сакла!* Г.Исхакый. *Биек текмә койманың Көнчыгыш капкасы янында байраклар күтәрелде, капка ачылды.* Н.Фәттах. *Кем яу туннары кигән, кем җиңелчә генә көбә-күлмәкләрдән, кем итектән, кем читектән, кем бүректән, кем кәпәчтән, кем ук-санай аскан, кем сөңгедән, кылыч-хәнҗәрдән, чукмар-балтадан, яу башындагы сугышчыларда исә татар байраклары җилферди...* Ф.Бәйрәмова; 2) полк (*войсковое подразделение, имеющее своё знамя*)

**байрак йөртүче** знаменосец. *Ярулла безнең бригаданың байрак йөртүчесе иде.* Г.Әпсәләмов

**БАЙРАКДА́Р** 1) *к.* **байракчы**; 2) прапорщик, хорунжий (*особая должность и лицо в этой должности в воинских частях тюркских стран*)

**БАЙРАКЧЫ́** знаменосец; *к.* **байрак йөртүче, байракдар**. *Яшь тук, көрән атка атланган бер яшь ир, байракчылар төркеменнән аерылды да, катауга таба чабып китте.* Н.Фәттах. *Алдан гаскәрбашы һәм морзалар килә, алар янында хан байракчылары, ә хан үзе исә иң көчле яугирләр чолганышында уртада бара.* Ф.Бәйрәмова

**БАКРА́Ч** медный шлем. *Томан эченнән борынгы батырлар киемендә: башына бакрач, өстенә кирәүкә кигән берәү шәйләнә.* Н.Исәнбәт

**БАЛГА́** боевой топор (*с длинным топорищем*). *Туң тимергә балга бар, туң кешегә хөкем бар.* Мәкаль

**БАЛДА́К** гарда, обод (*стягивающий рукоять меча, кинжала*). *Балдагы алтын уй булат – Ханияң кылыч бирәдер, Бусана, Идегәй, бусана!* Дастан

**БАЛТА́** 1) топор. *Авыл тирәсеннән алтмышынчы елларда көбә күлмәкләр, сугыш балтасы табылу аның тарихлы булуына ишарә ясый.* Т.Галиуллин; 2) топорец; бердыш; *чаг.* **айбалта**. *Балтасы чабып чапмады, Кыл муйныннан үтмәде. Ул үләсе бу үлде, Ханның әйткән сүзе үлде.* Дастан. *Гомумән, һәр көймә, һәр казак корал белән бик нык тәэмин ителгән иде, алар үзләре белән Уралга мылтыктан башлап үзаткычын, пищален, аркебузын, балта һәм кылычын, ук һәм җәясен – барысын да алып килгәннәр иде.* Ф.Бәйрәмова. *Уң кулларына алар [урыслар] озын туры кылыч тотканнар, бил каешларына балта белән пычак такканнар иде.* Н.Фәттах

**БАРАБА́Н** барабан. *Берәүләрне туп атып үтерәләр, берәүләрне барабан кагып.* Мәкаль. *Җиз быргыга барабан тавышлары кушылды, ул да казакларны татарларга каршы сугышка чакырып ярсый иде.* Ф.Бәйрәмова

**барабан кагу (сугу)** бить в барабан, барабанить

**БАРАБАНЧЫ́** барабанщик. *Алдан мөнадилар вә барабанчылар хәлвәфрүшне алып, урамнарда вә базарларда гиздереп, сәясәт җиренә китерделәр.* К.Насыйри

**БАРУ́Т** порох; *чаг.* **дары**

**БАРЫМТА́** баранта, набег с целью грабежа, угона скота. *Барымта алган мал түгел, куып алган куй түгел.* Мәкаль. *Барымтага барымта, карынтага карымта.* Мәкаль. *Барымтадан зур табыш белән кайткан кешеләрне котлаудан башланып киткән тантаналы шау-шу көне буе дәвам итте.* Н.Фәттах. *Алты ай ятты барымта килгән гаскәр, алты ай буена халыкны таладылар, җәберләделәр, рәнҗеттеләр.* М.Хәбибуллин. *Алар [күчмәләр] бит һәрвакыт барымта, карымталардан интегеп, табигать шартларына бәйле булып яшәгәннәр.* Р.Зәйдулла

**БАРЫМТАЛА́У 1.** *ф.* угонять. **2.** *и.* угон скота

**БАРЫМТАЧЫ́** участник разбойного нападения

**БАСКЫ́Н** 1) набег, налёт, разбой, внезапное нападение (*с целью грабежа и т.п.*). *Урыс гаскәре төрле яктан баскынга хәзерләнә, шуны күреп мин дә ашыктым.* Г.Исхакый; 2) налётчик; *чаг.* **баскынчы**. *Совет халкы бердәм булып немец баскыннарына каршы күтәрелә.* Х.Камалов

**БАСКЫНЛЫ́К 1.** *и.* разбой, грабёж; привычка делать набеги и налёты. *Тарихи фактлар шуны раслый: баскынлыкка йөз тотып, ил-дәүләтләрне яулап һәм талап гомер итәргә исәп тоткан халык иртәме, соңракмы барыбер фаҗигага дучар булыр.* М.Хәбибуллин. **2.** *с.* разбойный, грабительный

**БАСКЫНЧЫ́ 1.** *и.* 1) налётчик, разбойник; человек, занимающийся набегами и разбоями; 2) агрессор, захватчик. *Татар ханы Габдулла – Биләр-Болгар кальгаларын ныгыта, бөтен халкын баскынчыларга каршы күтәрә, ил белән күтәрелә халык.* М.Хәбибуллин. *Һәр заманда да баскынчылар, икътисади мәнфәгатьләрне яшерер өчен, төрле идеологик чаршаулар корганнар.* Р.Зәйдулла. **2.** *с.* разбойный

**БАСКЫНЧЫЛЫ́К 1.** *и.* 1) разбойничество; разбой; занятие разбоями и налётами; 2) захватничество, агрессия. *Ил зарын кяферләр йөзендәге баскынчылыкта күрми, ә илдә барган золымнан күрә.* М.Хәбибуллин. **2.** *с.* захватнический, агрессивный

**БАСМАЧЫ́** басмач *(участник контрреволюционного движения в Средней Азии, ведущего борьбу против Советской власти). Бер хыянәт белән кулга төшергәннәр дә, басмачыларның кара ояларында биек баганалар белән югары асып, түбәннән җәһәннәм кебек ут якканнар, ди...* Г.Ибраһимов. *Басмачыларга каршы көрәштәге батырлыклары өчен орден белән бүләкләнгән улы турында Кызыл Армия дивизиясеннән котлау хаты да килде.* Г.Кутуй

**БАСМАЧЫЛЫ́К** басмачество *(контрреволюционное движение басмачей). Басмачылык хәрәкәте* движение басмачей, басмаческое движение

**БАСТИО́Н** бастион. *Әгәр киләчәктә дә безнең хокукларыбызны, яуланган бастионнарыбызны шулай тартып ала барсалар, без бөтенләй ярык тагарак янында утырып калмабыз микән?* Р.Вәлиев

**БАСТЫРУ́ 1.** *ф.* подавить, усмирять/усмирить *(восстание и т.п.).* **2.** *и.* подавление, усмирение. *Ары таба Ибн Хәлдун исә дәүләтләр турында болай ди: «Әгәр дә мәгәр дәүләт үз гомерен озайтырга теләсә, өч хакыйкатькә тугры калырга тиеш – яулауга, азатлыкка омтылучыларны бастыруны онытмаска һәм үз-үзен саклау чараларын күрергә».* М.Хәбибуллин. *Күтәрелешне бастыру өчен Германия командованиесе анда ашыгыч рәвештә СС гаскәре җибәрә.* М.Әмирханов

**БАСУ́ 1.** *ф.* захватывать, захватить. *Тотыклыгының беренче елында, күзгә табан ул – Тотыш углан – ике мең кешелек чирү белән көтмәгәндә суарларны барып басты: калаларын камап алды, коймаларын яндырып, җимереп, катауларын пыр туздырды.* Н.Фәттах. **2.** *и.* захват; грабёж

**басып алу 1.** *ф.* завоёвывать, завоевать, захватывать, захватить. *Урыслар Себерне басып алгач, анда йөзләгән татар шәһәре күреп, таң калалар.* Ф.Бәйрәмова. **2.** *и.* завоевание, захват. *Барымтага, басып алуга, теге я бу якны буйсындыруга йөз тоткан як иртәме, соңракмы бик тә яман үкенү кичерер.* М.Хәбибуллин. *Аннан соң XIII гасырдагы монгол басып алулары ислам дөньясы*

*чикләрен тулысынча үзгәртә һәм аңа яңа төрки-монгол юнәлеше бирә.* Татар халкы тарихы

**басып алучы** захватчик; *чаг.* **баскынчы, илбасар**. – *Нигә минем белән берләшеп, басып алучыларга каршы яуга чыкмый, ә һаман шымчыланып, нидер көтеп йөри?* Ф.Бәйрәмова

**басып керү** завоёвывать, вторгаться, нападать, покорять. *Әммә Карачаның башында бер генә нәрсә – мал һәм байлык, һәм шулар хакына бөтен тирә-юньгә хуҗа булу, басып керү һәм буйсындыру теләге.* Ф.Бәйрәмова. *Көннәрдән беркөнне, Тотыш яңадан Ага-базарга килеп җитәргә өч-дүрт көн кала, каган илчесенең килеп китүе инде бөтенләй онытылып беткәч, Болгар җиренә каган чирүе басып керде.* Н.Фәттах

**БАТАЛЬО́Н** батальон. *Капитан Вилданов батальоны шул авылда урнашты.* З.Зәйнуллин. *Батальонның сирәгәйгән вакыты, тегендә-монда тишек-тошык ямау, планны өзмәс өчен байтак командалар җибәрелгән икән.* С.Шәрипов

**БАТАРЕ́Я** батарея. *Бәхеткә каршы, шул кискен моментта батареяга яңарак килгән бер кече лейтенант искиткеч салкын кан белән акыллы хәрәкәт итте.* Х.Камалов

**БАТЫ́Р 1.** *и.* 1) герой, доблестный мужчина; молодец, молодчина; смельчак; 2) богатырь; храбрец, храбрый воин. *Батыр яуда беленер, телчән дауда беленер.* Мәкаль. *Яу юкка батыр күп.* Мәкаль. *Туй беткәч сүз, яу беткәч батыр күбәер.* Мәкаль. *Атаклы ике батырыннан колак какса да, акбүреләр белән очрашуның шулай тиз генә, җиңел генә төкәнүенә Алмыш хан сөенми булдыра алмады.* Н.Фәттах. *Ханбикәм, воевод Василийның Казанда кимендә өч мең батыры бар.* М.Хәбибуллин; 3) силач; атлет; борец (в национальной борьбе). **2.** *с.* храбрый, смелый; доблестный. *Батыр егет яу күрке, чичән егет дау күрке.* Мәкаль

**БАТЫРЛЫ́К** 1) героизм, геройство, подвиг; храбрый поступок, деяние. *Ә бу кеше олан кенәзгә мин теге нәселдән, мин бу нәселдән дип тормады, аннары батырлыклар кылдым дип күкрәк тә какмый, сабыр гына тыңлый...*

М.Хәбибуллин; 2) храбрость (как постоянное свойство), решительность, смелость, отважность. *Өстеңә яу килсә, батырлыгың китәр, башыңа яу килсә, белегең китәр.* Мәкаль. *Гәүдә-сынга ыспай, бит-йөзгә дә күз төшәрлек, батырлыгы, тапкырлыгы, кыюлыгы да бар һәм һәрчак үзбаш фикер йөртә [Юныс].* М.Хәбибуллин

**БАҺАДИ́Р 1.** *и.* богатырь, герой. *Гадәттә төрки халкы баһадирлары белән мактана, ил данын алар йөзендә күрә....* М.Хәбибуллин. **2.** *с.* 1) богатырский. *Синең кебек баһадир егеткә кызлар муеннан.* Р.Камал; 2) *к.* **батыр**

**БАҺАДИ́РАНӘ** богатырски, по-богатырски

**БАҺАДИРЛЫ́К 1.** *и.* 1) богатырство; 2) храбрость, мужество, стойкост. *Шушы пәһлеван вышканы күчереп йөртүләрен күрәсең дә, адәм баласының баһадирлыгына, зурлыгына хәйран каласың!* Ш.Галиев. **2.** *с.* богатырский

**БА́Ш** 1) головка, головная часть (*чего-либо*); наконечник, кончик. 2) глава, главарь; начальник, верховод, предводитель. *Кулларын авыз турысына куеп, ул [Туңгак алып] бар көченә: – Башыгыз кем? Монда чыксын! – дип кычкырды.* Н.Фәттах. *Хәтта сарай сакчылары башы Велизарий да император тәкъдиме белән килешә.* М.Хәбибуллин

**баш калкыту** *к.* **баш күтәрү**. *Алай дисәң, сәүдәгәр генә түгелләр, кара халык шундук баш калкытыр, диндарлар кубар, нугайлар телгә килер, Юныс бәк исә кылычка ук ябышыр.* М.Хәбибуллин

**баш күтәрү** восстать. *Сөн йолаларын, сәннәрнең изге ата-бабаларын санламаска, тарханга каршы баш күтәрергә син өйрәтмәдең микән аны, Котлуг бәк.* Н.Фәттах. *Татарлар баш күтәрергә җыенмыйлармы?* М.Хәбибуллин. *Баш күтәрүләр, фетнә-болалар һәрвакыт булып торган.* Р.Зәйдулла

**баш күтәрүче** восставший, участник восстания, повстанец

**баш өсте** слушаюсь! *– Ярар, баш өсте, кошны бирсәң, без сиңа кияүне күрсәтербез, – диде Чулак.* Әкият. *– Кирәк дип табасың икән, унбаш Сөләйман җансакчымны ал. – Баш өсте, ханбикәм...* М.Хәбибуллин

**БАШÁК** наконечник (*стрелы или копья*). *Идегәй аны дигәндә, Тим Чуарын менгәндә, Шайман тагып килгәндә, Киерелмәле җәясен Киереп тартып күргәндә, Карга йонлы кузын, Яурын башак угын – Аны да тартып килгәндә, Акбеләк кыз ул ара Алыпның кулын күтәрде...* Дастан. *Кызыл саплы, тимер башаклы сөңгесен ул [кораллы ир] ике куллап кочаклап тоткан иде.* Н.Фәттах

**балта башак** долотовидный наконечник. *Ук өчен нечкә талны каерысыннан әрчибез, киптерәбез, турылыйбыз, аннары бер очындагы йомшак үзәгенә башак утыртабыз һәм, барып кадалганда эчкә кереп китмәсен өчен, укның башак утыртылган җирен нечкә тимерчыбык белән бик каты урап куябыз... Ук башагы ике төрле була – без башак һәм балта башак.* Ә.Еники

**без башак** шиловидный наконечник. *Без башак тишеп керә, ә балта башак кисеп төшерә. Без башакка калын энә дә ярый, ә менә балта башакны махсус ясарга кирәк. Моның өчен без дага кадагын поезд үткәндә рельс өстенә куеп таптатабыз, аннары бик әйбәт иттереп тигезлибез һәм үткерлибез. Исеменнән күренгәнчә, ул чынлап та балта йөзенә охшап тора.* Ә.Еники

**БАШАКЛÁУ** снабжать наконечником; вставлять/вставить наконечник (*стрелы, копья и т. п.*)

**БАШЛЫ́К** глава, главарь; начальник, предводитель

**БÁШНЯ** башня; *чаг.* **каланча**. *Гыймакай карт танк башнясы кебек йомры башын төп кода ягына борды.* А.Хәлим

**БАШЧЫ́** главарь, вожак; руководитель

**БАШЫБОЗЫ́К** башибузук (*солдат-волонтёр в турецких войсках*)

**БӘЙГÁТЬ** клятва, присяга. *Төрле чуваш, чирмеш, мукшылар кабиләләреннән дә бәйгатьләр килде.* Г.Исхакый

**бәйгать бирү** давать/дать присягу, присягать/присягнуть. *Ил булсагыз, атайга барыгыз, бәйгать бирегез, диде.* К.Насыйри. *Галим бәк төркемендәге бөтен Казан олуглары Олуг Мөхәммәднең кулын үбеп табуг салалар (бәйгать бирәләр).* Г.Исхакый

**БӘЙДӘНӘ́** байдана *(кольчуга из крупных шайбовидных колец, которую носили, как правило, не самостоятельно, а в качестве верхнего или же парадного доспеха)*

**БӘРЕЛЕ́Ш** стычка, битва, схватка, столкновение; небольшой бой. *Патша гаскәре һәм казаклар бандасы арасында көчле бәрелешләрдә ике яктан да шактый кеше үлә.* Ф.Бәйрәмова. *Арча капкасы буендагы бәрелештә, сан ягыннан өстенлек һәм зур югалтулар исәбенә, ул, ниһаять, ныгытма эченә үтеп керүгә ирешә.* Ф.Зариф

**БӘРЕЛЕШҮ́ 1.** *ф.* сталкиваться/столкнуться, схватываться/схватиться, вступать в бой (борьбу), сцепляться, сцепиться. *Божраны бикләргә Мюрат җибәргән француз кавалеристлары урыс гусарлары белән бәрелешәләр.* З.Зәйнуллин. **2.** *и.* столкновение, стычка, схватка. *Көтелмәгән бәрелешүләрдән соң, Мансурның үзен тынычта калдырмаячагын белеп, аңлап яши Сәет.* Т.Галиуллин

**БӘРЕ́Ң** доспехи воина и/или коня *күп. Сөяк тешем кашкарып, Бәреңләй бәнем кадалып...* Дастан

**БӘРМӘ́** ударный, наступательный (*о живой силе*)

**БӘРҮ́** ударять/ударить, стрелять/выстрелить; бить, палить/выпалить, бабахать/бабахнуть

**БЕРДА́НКА** берданка. *Алтатардан, ау мылтыгыннан, берданкадан аткан тавышлар Мәскәүнең үзәк урамнарында да, чат-тыкрыкларында да ишетелеп торды.* Г.Ахунов

**БЕРЛӘШМӘ́** соединение, союз. *Хәрби берләшмә* военное соединение

**БИКТӘ́Р** *к.* **битлек**. *Ак көбәмне ал[ып] килче! Битенә биктәр ташлап киям.* Дастан

**БИ́Л** рукоять (*лука*)

**БИЛТӘ́** 1) пушка; 2) щётка для очистки ствола пушки

**БИРУ́Н КЕШЕ** представитель военного сословия в Казанском ханстве (*преимущественно из марийцев*)

**БИТКӘ́Р** *к.* **битлек**

**БИТЛЕ́К** забрало; *чаг.* **биктәр, биткәр**. *Кораллы ир, битлеген артка ташлап, көлеп җибәрде.* Н.Фәттах

**БИҺБУ́Д** бейбут, бебут (*обоюдоострый боевой нож с изогнутым клинком*)

**БЛИНДА́Ж** блиндаж. *Алексей блиндажга керде генә – чигенеп барган фрицлар, аңнарына килеп, миномёттан ут ачтылар.* Х.Камалов. *Инде блиндажга керергә дип часовой белән сөйләшә башлаган иде, арттан шатланып кычкырып җибәрделәр: – Зәйни-и!* З.Зәйнуллин

**БЛОКА́ДА** блокада. *Ленинград блокадасының өзелүе һәм җиңелмәс Герман гаскәренең чигенүе, Сталинградта фашист генералы Паулюсның әсир төшүе, Киевның азат ителүе.* А.Тимергалин

**БОГА́У** оковы, кандалы *күп. Кул богавы* ручные оковы (кандалы); *аяк богавы* ножные оковы (кандалы); *тимер богау* железные кандалы. *Сезнең муенга да муенчак күптән салынган. Муенчак кына да түгел – богау!* Н.Фәттах

**богау салу** надевать оковы (кандалы). *Аякларына богау салып, зинданга ташланган кенәз Андрей Телепага ышануына үкенепләр бетә алмый, әмма соң була инде.* М.Хәбибуллин. *Боларның аякларына тимер богау салынган иде.* Н.Фәттах

**БОГАУЛАНУ́** заковываться/заковаться (в кандалы)

**БОГАУЛА́У 1.** *ф.* заковывать/заковать в оковы (кандалы). *Хатыны булса, атам, богаулап илтсәң дә бармам.* М.Хәбибуллин. *Мөхәммәткол солтанны, аяк-кулларын богаулап, тизрәк сарайдан алып чыгып киттеләр һәм ташпулат базларының берсенә яптылар, ишек-тәрәзәләргә көчле сак куйдылар.* Ф.Бәйрәмова. **2.** *и.* заковывание в оковы (кандалы)

**богаулап кую** *к.* **богаулау**. *Басып алган халыкны кол итеп үз биләмәләренә алып китәләр, кул-аякларын богаулап куеп, җир асты базларында, чуен заводларында эшләтәләр иде...* Ф.Бәйрәмова

**БОГАУЛЫ́** закованный, в оковах (кандалах). *Бер-берсен кочарлар иде – куллары богаулы, бер-берсенең исемнәрен кычкырырлар иде – эндәшергә ярамый.* Г.Әпсәләмов

**БОЕРЎ 1.** *ф.* приказывать/приказать; повелевать/повелеть; предписывать/предписать. *Бу сүзләрне ул ничектер коры итеп, боергандагы кебек итеп әйтте.* Н.Фәттах. *Бу хәлгә җен ачулары чыккан Дүртенче Иван мылтыкчыларына халыкка атарга боера.* М.Хәбибуллин. **2.** *и.* приказание, повеление. **3.** *с.* приказной, повелительный (*тон разговора*)

**БОЕРЫ́К** приказ, распоряжение, предписание; *чаг.* **әмер**. – *Тархан боерыгы гына түгел, минем боерык та үтәлергә тиеш, – диде Тучи бәк тәгин углан коры гына.* Н.Фәттах

**боерык бирү** приказывать, приказать. – *Алыш минем җансакчым белән, – диде ул боерык биреп.* М.Хәбибуллин

**БОЛА́** мятеж. *Бола вакытында шәфкатьлелек, миһербанлык югала.* Р.Зәйдулла

**БОЛАГА́Й** смутьян. *Элек тә бик болагай хатын түгел иде, хәзер бөтенләй ябылды.* Р.Батулла

**БОЛАЧЫ́** мятежник, бунтовщик. *Старшина патша хезмәтендәге адәм, шунлыктан болачыларга кушылу ул властька каршы бару гына түгел, ә антка хыянәт итү.* З.Мурсиев

**БОЛГАНЫ́Ш** смута; волнения, беспорядки *күп. Экологик кризис икътисади кризис тудыра, ә анысы сәяси болганышлар китереп чыгара.* Н.Гариф

**БОЛҖА́Р** *к.* **бүлҗәр.** *Дүрт болҗарның агасы, Макмал тунның ягасы, Кәмалның улы Киң Җанбай Хан Туктамыш чагында Түрә булып үтсә иде!* Дастан

**БО́МБА** бомба. *Бомбаларың туры төшсен, Бетсен этләр оясы.* Г.Кутуй *Ул бомбага тимәс өчен, аны кузгатмас өчен, акыл белән эш итәргә кирәк.* Т.Миңнуллин

**бомбага тоту 1.** *ф.* бомбить, бомбардировать. *Шул ук АКШ Ливияне, Суданны, Югославияне бомбага тотты.* Р.Зәйдулла. **2.** *и.* бомбардировка, бомбёжка

**БО́МБАЛАУ 1.** *ф.* бомбить, забрасывать бомбами, бомбардировать. **2.** *и.* бомбардировка

**БОРЫНЧА́** наносник

**БӨКӘВЕ́Л** *к.* **бөгәвел**. *...Унҗиде ир җитеп килгәндә Йосынчының ирләре: Ясавылдан ясавыл, Тоткавылдан тоткавыл, Иравылдан иравыл, Чагдавылдан чагдавыл, Бөкәвелдән бөкәвел – Башына дөнья тар булды, Атланып чүлгә таралды.* Дастан

**БӨГӘВЕ́Л** агент-контрразведчик; тайный охранник (*царя, хана*)

**БӨЛГЕ́Н** пленение, плен. *Тарханга ул кыска гына итеп Албуга турында, үзләренең Чиндә бөлгендә булулары, качулары турында сөйләп бирде.* Н.Фәттах

**бөлген(гә) төшү** попадаться в плен. *Шундый үзара сугышларның берсендә Сылу-кызның абыйсы музлыларга бөлген төшкән.* Н.Фәттах

**БӨЛДЕРМӘ́** темляк (*петля на рукоятке шпаги, сабли, шашки*)

**БӨРЕ́Җ** бастион, кремль

**БРОНЯ́** броня. *Ләкин ул рапортында безнең 76 миллиметрлы туплар «тигр»ның алгы бронясын җимерергә көчсезрәк дигән ялгыш бер җөмлә язган иде, шул сүзләргә бәйләнделәр.* Х.Камалов

**БРОНЯЛАНГА́Н** бронированный, покрытый бронёй, броневой. *Командиры: – Әхияр, әллә синең тәнең броняланганмы?* Ф.Яруллин

**БРОНЯЛА́У 1.** *ф.* бронировать, покрывать/покрыть бронёй. **2.** *и.* бронирование, бронировка

**БРОНЯЛЫ́** имеющий броню; бронированный. *«Георгиос Аверов» исемле бронялы крейсер турында сүз бара.* Г.Камал

**БУЛА́Т 1.** *и.* 1) булат (*старинный сорт стали*); 2) меч. *Булат кынга туктый.* Мәкаль. *Алты суның буенда <...> Яшьлегендә ир булган, Судай булат бәйләгән, Арыслан, каплан аулаган <...> Субра дигән ерау бар.* Дастан. *Тартып булат бәйләгән Бура солтан Бәрки хан – Аннан калган картыңмын.* Дастан. *Балдагы алтын уй булат – Ханияң кылыч бирәдер, Бусана, Идегәй, бусана!* Дастан. **2.** *с.* булатный.

*Булат пычак кынсыз булмас.* Мәкаль. *Синең булат кылычыңны улыбыз Али күтәреп алыр.* Ф.Бәйрәмова

**БУ́НТ** бунт; мятеж; *чаг.* **бола, фетнә.** *Июль аенда контрлар оештырган бунт вакытында бу авылның ярлылар комитеты да таркатылган һәм Сәмигулла агай кайтып төшкәндә дә башлыксыз торган булган.* В.Нуруллин

**бунт күтәрү** бунтовать, забунтовать, бунтоваться, взбунтоваться

**бунт күтәрүче** бунтовщик

**бунт чыгару** *к.* **бунт күтәрү**. *Америка дигән җирдә негр дигән халыкларны яклап бунт чыгаруда катнашкан, шуның өчен аны бер җиргә дә эшкә алмаслык итеп пашпортына мөһер басып кайтарганнар.* Т.Гыйззәт

**бунт чыгаручы** *к.* **бунт күтәрүче**

**БУНТА́РЬ** бунтарь; *чаг.* **бунт күтәрүче**. *Патшалар ни өчен Пугачёв кебек бунтарьларның башта аяк-кулларын, аннан соң гына башын кистергән?* Ф.Яруллин

**БУНТАРЬЛЫ́К** бунтарство

**БУНТЧЫ́** бунтовщик. *Бунтчылар әле һаман таралышмаган, Миңнулланы сүгеп, һаман капка төбендә торалар.* В.Нуруллин

**БУТАЛЫ́Ш** бунт; смута, брожение; волнения, беспорядки *күп. Шулай да татар халкында шушы буталыштан саусәламәт чыгарга көч бармы?* Р.Батулла

**БҮЛҖӘ́Р** место встречи воинских частей

**БЫЛАГА́Й** *к.* **болагай**

**БЫРГЫ́** труба, горн. *Яңа орыш башланганын белдереп тагын быргылар кычкырды, тагын дөңгерләр дөпелдәде.* Н.Фәттах. *Җиз быргыга барабан тавышлары кушылды, ул да казакларны татарларга каршы сугышка чакырып ярсый иде.* Ф.Бәйрәмова

**БЫРГЫЧЫ́** горнист. *Быргычы быргысын уйнатып салют бирде.* Ф.Яруллин

# В

**ВА́Л** земляная насыпь. *Калын вал, траншеялар берничә урыннан инде җимерелгән, кайбер ут нокталары юк ителгән иде.* Г.Әпсәләмов

**ВАТА́Н** родина, отечество, отчизна. *Муса бик кайгыра, йөзеннән адәм төсе кача: нинди хурлык, газиз Ватан ут эчендә, ә әсирләрне һаман ераккарак олактыралар.* Г.Әпсәләмов

**ВЗВО́Д** взвод. *Взвод командиры дөнья күргән, акыллы старшина иде.* С.Шәрипов

**ВИНТО́ВКА** винтовка. *Нәҗми, винтовкасын яраштырып, көлү тавышы ишетелгән якка атып җибәрде.* Һ.Такташ

**ВОЕНКОМА́Т** военкомат, военный комиссариат

**ВОССТА́НИЕ** восстание; *чаг.* **баш күтәрү**. *Восстание гаскәр ярдәме белән бастырыла, оештыручылар һәм башлап йөрүчеләр җәзалана.* Г.Камал

**ВОССТА́НИЕЧЕ** повстанец; *чаг.* **баш күтәрүче**. *1554 елның кышында Калатау өстендә Өтернәс шәһәрчеге янында рус гаскәрләре һәм восстаниечеләр арасында каты сугыш була.* Т.Нәҗмиев

# Г

**ГАВЕ́Р** *к.* **кяфер**. *Гавер аткан утчагыр Күкрәгенә батмаган, «Утчагыр алмас» батыр дип, Даны йортка таралган – Аны күргән картыңмың.* Дастан. *Бу гавернең юлына Юл яңылып кергәнсең; Исән-исән икәндә Исән-аман кит! – диде.* Дастан

**ГАДӘВӘ́Т** дошманлык. *Шулай итеп бу кызлар арасында гадәвәт пәйда булды.* Дастан. *Ишетеп Һишам аны, диде: «Угыл, Бу эшнең соңы – гадәвәт, белмеш ул...»* Мөхәммәт Әмин

**ГАДУ́** 1) дошман. *Гадүләр һәр тарафдин күп.* Г.Чокрый; 2) яу

**ГАЗА́** газават, священная война. *Пәйгамбәр галәйһиссәлам үзе 27 газа кыйлды.* К.Насыйри

**ГАЗАВА́Т** *к.* **газа**. *Газаватның башы шул булыр.* Р.Батулла

**ГАЗА́Т** *к.* **газа**

**ГАЗВӘ́** поход, набег, нашествие; война

**ГАЗИ́** 1) гази (*борец за мусульманскую веру, участник газавата*). *Газилар өстән, шәһитләр астан юл таба, ди.* Мәкаль. *Гази диләр тагын үзен [бәкне]... Янәсе, сугышчы... Бәкләре аерылгач, ул берүзе нишли алсын?* Р.Зәйдулла; 2) победитель; 3) завоеватель

**ГАЛӘБӘ́** победа (*над врагом*); превосходство
**галәбә итү (кылу)** побеждать, одерживать победу. *Галәбә иткән сыман көлеп куйды.* Ф.Әмирхан

**ГАЛӘБӘДА́Р** победный; победоносный. *Сугышның галәбәдар соңы* победный конец войны

**ГАЛӘБӘЛЕ́К** победа; победное торжество; радость по случаю победы, торжество успеха

**ГАЛӘ́М** *к.* **әләм**. *Катына һәм вирде ул бер галәм, Кушты мең кеше дәхи аныңлә һәм...* Мөхәммәт Әмин

**ГАЛИ́Б** победитель. *Сездән галиб хан булса, вәгъдәсендә тормасмы?* Дастан
**галиб булу** побеждать, одерживать победу; быть победителем

**ГАНИМӘ́Т** трофей, военная добыча. *Ганимәткә алданып, галәмәт булып калу бар.* Мәкаль. *Тыштан чаналардан капчыклар, итләр, ганимәт малы ташыйлар.* Г.Исхакый

**ГАРНИЗО́Н** гарнизон. – *Син монда, – диде аңа участковый Нәбиуллин, – гарнизон начальнигы.* М.Мәһдиев

**ГАСКӘ́Р 1.** *и.* 1) войско; армия. *Чиксез кузы сансыз куй, Күп гаскәре туйсын дип, Суеп казан асар ул.* Дастан. *Ә урыс гаскәрләре, алар кайда?* Ф.Бәйрәмова; 2) солдат, воин. *Вазифасыз гаскәр булмый.* Мәкаль. *[Хан:] Төмән башлары, мең*

*башлары, йөз башлары, ун башлары, угланнар, гаскәрләр! Хәлемезне күрәсез.* Г.Исхакый. **2.** *с.* военный

**гаскәр башлыгы** полководец, командующий; военачальник. *Мин сезне – Себер ханлыгының бәкләре һәм морзалары, карачалары һәм абызлары, сәедләре һәм шәехләре, гаскәр башлыклары – халыкны шушы сугышка күтәрү өчен җыйдым!* Ф.Бәйрәмова

**гаскәр башы** *к.* **гаскәр башлыгы**. *Бүген Казанда гаскәр башы гаять оста җиһангир Сафа Гәрәй хан белән Кырымнан килгән Көнчак углан тора, диделәр.* М.Хәбибуллин. *Ире «хәрби эшләр» диюгә, Сүзге сискәнеп китте, чөнки үсмер егетне ул берничек тә гаскәр башы итеп күз алдына китерә алмый иде.* Ф.Бәйрәмова

**гаскәр төшерү** высаживать войско, десантировать

**ГАСКӘРБА́Ш** *к.* **гаскәр башы**. *Император тәхет янына карачыларын, куштаннарын, гаскәрбашларын җыя, әүвәл һәммәсенең дә киңәшен тыңларга була.* М.Хәбибуллин

**ГАСКӘРИ́ 1.** *с.* 1) военный. *Гаскәри врач* военный врач; *гаскәри кием* военная одежда. *Гаскәри кешеләргә дәүләт белән идарә итү бары тик зыянга булыр, хан хәзрәтләре.* М.Хәбибуллин. *Килешле иттереп тегелгән ялтыравык погонлы гаскәри френче, шома иттереп төзәтелгән чәчләре, алтын пенсне аркылы мәһабәт карашлары аның бөтен кыяфәтенә бертөрле нечкә матурлык бирә иде.* Ш.Камал; 2) воинский; армейский, войсковой. **2.** *и.* солдат, воин, военнослужащий. *Карача һәм морзалар, дин әһелләре һәм гаскәриләр, шәркычы-җырчылар, казанчы-пешекчеләр – барысы да тантаналы мизгелне көтә...* Ф.Бәйрәмова. *Кәләш арбасы гаскәриләр уртасында калды.* М.Хәбибуллин

**ГАСКӘРИЛӘ́РЧӘ** по-военному, как военные

**ГАСКӘРИЛЕ́К** армейский характер *чего-л.*; военная выправка, армейский вид *кого-л.*

**ГАСКӘРЛЕ́К** 1) для войска, армии; на целое войско. *Бер гаскәрлек кием тегү* шить одежду на целое войско; 2) военная служба

**гаскәрлеккә алу** призывать на военную службу

**гаскәрлеккә ярау** быть годным к военной службе
**гаскәрлектә булу** быть на военной службе, служить в армии; проходить воинскую службу

**ГА́УБИЦА** гаубица. *Безнең гаубица туплары ата башлады.* Х.Камалов

**ГАУПТВА́ХТА** гауптвахта. *Мәүлетдиннең иярдән «егылып төшкәненә» кычкырып җибәргәннәр ягына Барклай кул гына селти – берничә минут үтүгә, үзенең теленә хуҗа була алмаган гусар сак астында гарнизон гауптвахтасына китеп тә бара: тәртип, һәр җирдә тәртип!* З.Зәйнуллин

**ГВАРДЕ́ЕЦ** гвардеец. *Күкрәгемдә бүләк түгел, гвардеец значогы.* Г.Кутуй

**ГВАРДИ́Н** гвардеец. *Ак гвардин кебек булгачмы?* А.Тимергалин

**ГВА́РДИЯ** гвардия. *Ләкин шулай да гвардия капитаны коточкыч сугыш гөрелтесе эчендә үз пулемётларының таныш такылдавын ишетә.* Г.Әпсәләмов

**ГВА́РДИЯЧЕ** гвардеец. *Вокзал бакчасындагы кызыл балчык өеме өстенә гвардияче ун солдат менеп басты.* М.Мәһдиев

**ГВӘРДИ́Н** *к.* **гвардин**. *Гайнулла җизни солдатта гвәрдин булып Варшауның үзендә хезмәт иткән кеше.* Г.Бәширов

**ГЕВӘРДИ́Н** *к.* **гвардин**. *Менә шулай иттереп эләктереп кала Зифа тәтәгез кара мыеклы гевәрдин егетне.* Г.Бәширов

**ГЕНЕРА́Л** генерал. *Рәфкать үскәч генерал булырга хыяллана.* Ф.Яруллин. *Безнең генерал әйтә торган иде: солдатны пуля түгел, паника үтерә дип.* Ә.Еники

**ГЕНЕРАЛИ́ССИМУС** генералиссимус (*высшее воинское звание и человек в этом звании*). *Ничә дистә миллион кешене үтерткән өчен үзенә генералиссимус дәрәҗәсен бирде.* М.Мәһдиев

**ГЕНЕРАЛИТЕ́Т** генералитет. *Генералитет кулында нинди разведка материаллары гына юк.* А.Хәсәнов

**ГЕРО́Й** герой. *Минем әткәй дә герой.* М.Әмирхан

**ГЕРОЙЛЫ́К** героизм, геройство. *Бу геройлык вакыйгасы авыл малайлары арасында минем авторитетны бик күтәреп җибәрде.* Г.Камал

**ГӨРЗИ́** булава; палица. *Энҗү белән Бәнҗүдә Борын үтте биш батыр Биш батырдан иң батыр – Гөрзисе иде биш батман, Кылычы иде йөз тотам, Сукса тауны җимерде, Чапса яуны юк итте, Таубатыр дип дан алды – Аны күргән картыңмың.* Дастан. *Юварилорның өчесе көбә күлмәктән, сөңге-җәяләр, бәләкәй айбалталар, гөрзиләр белән коралланган, ә дүртенчесе гадәти, ләкин зиннәтле киемнән иде.* А.Тимергалин

**ГРЕНАДЕ́Р** гренадер. *Кул күтәреп караса да, гренадер гәүдәле Тинчурин каршында әлегә Гатин бернинди уңышка ирешә алмады.* Р.Низамиев

**ГУСА́Р** гусар. *Аның артыннан йөгергән ике гусар кире борылдылар, тимерләрен ташлап, алачыкка кереп бикләнделәр.* З.Зәйнуллин

**ГУАРДИ́Н** *к.* **гвардин**; *чаг.* **гвардеец, гвардин, гвардияче, әзмәвер, углан**. *Адымнарын гына кара син аның, гуардин солдатмыни, метр гына атламыйдыр.* А.Гыйләҗев

**ГҮӘРДИ́Н** *к.* **гвардин**. *Гүәрдин ялгыз калса да, сугыш яланын ташлап китмәс.* Мәкаль. *Гүәрдин күк ир чагында кадерне белүче күп булыр, мәйтәм.* Г.Ахунов

**ГЫЙСЪЯ́Н** 1) бунт, мятеж, восстание; 2) неповиновение, сопротивление; ослушание; возмущение, негодование. *Әлкыйсса, безнең Болгар әһле фисык вә гыйсъян илә мәшһүр иделәр.* Риваять

**ГЫЙСЪЯНЛЫ́** повстанческий, мятежный, восставший

**ГЫЙСЪЯНЧЫ́** мятежник, повстанец; бунтарь, бунтовщик; смутьян. *Шуңа күрәдер дә патшага каршы күтәрелгән гыйсъянчыларның күп өлешен татарлар тәшкил иткән.* Р.Батулла

# Д

**ДАВЫЛБА́З** 1) парадный или оркестровый барабан; 2) барабанщик

**ДАРЫ́** порох. *Дары белән ут бер җирдә булмый.* Мәкаль. *Күчем Бохарадан утлы таяклар да кайтартып карады, Кырымнан туплар соратты, әмма аларга да даими рәвештә дары, ядрә кирәк булып чыкты.* Ф.Бәйрәмова

**дары амбары** пороховой склад. *Кремльгә кадәр ут капты, дары амбарлары шартлады, Успен соборының түбәсе ябып, эчкә җимерелеп төште.* М.Хәбибуллин

**дары савыты** пороховница. *Аны бер стенд янына алып килдем, анда казахның коштабагы башкортныкы дип, дары савыты элеп куелган.* Ф.Бәйрәмова

**ДАРЫЛЫ́** пороховой, с порохом. *Димәк, Алиягә шушы дарылы чүлмәкне – ут факелын, йөрәген пешерә-пешерә, күтәреп барасы.* А.Юнысова

**ДӘҮРӘ́Н** богатырь-единоборец; борец

**ДЕЗЕРТИ́Р** дезертир. *Ишек төбенә барып җиткәч, борылды да, теш арасыннан сыгып: «Дезертир!» – диде.* Р.Вәлиев

**ДЕЗЕРТИРЛЫ́К** дезертирство. *Дошман ягында калу дезертирлык санала икән.* Х.Камалов

**дезертирлык итү** дезертировать (*с поля боя*). *Әйе, Тәбрикнең әнисе каршындагы әхлакый бурычларын үтәүдән, үз бәхетләреннән яланаяк качкан үги ата һәм туган әтисе кебек үк Тәбрик тә туган җир алдындагы бурычыннан качып дезертирлык итәргә җыенган.* Ә.Баян

**дезертирлыкта йөрү** быть в дезертирах

**ДЕМОБИЛИЗА́ЦИЯ** демобилизация. *Сугышны бетердек, демобилизациягә эләгеп авылга кайтып төштем.* А.Гыйләҗев

**ДИВИЗИО́Н** дивизион (*1) воинское подразделение в ракетных, артиллерийских и бронетанковых частях; 2) соединение военных кораблей одного класса*). *Артиллерия дивизионы*

дивизион артиллерии; *миноносецлар дивизионы* дивизион миноносцев; *дивизион тупчылары* артиллеристы дивизиона

**ДИВИ́ЗИЯ** дивизия. *Бу документларны дивизия штабы начальнигына бирегез.* З.Зәйнуллин

**ДИНАМИ́Т** динамит. *Динамит филтәсе буйлап яндырылган шырпының ялкыны үрмәләде.* А.Алиш

**ДИҢГЕЗЧЕ́** моряк. *Миләүшә күңеле белән гел диңгезче егетне көтеп яшәде.* Ф.Яруллин

**ДОТСА́К** *к.* **тотсак**. *Аны кем, золм илә кылдылар шәһид, Дотсак итеп, каумене – кардәшене, Шама апардылар аның бышыны.* Мөхәммәт Әмин

**ДОШМА́Н 1.** *и.* враг, неприятель, противник; недруг. *Дошман кулына кылыч тоттырмыйлар.* Мәкаль. *Дошман юкта ук атсаң, үз кешеңә тияр.* Мәкаль *Дошманга үлем – сиңа гомер!* Мәкаль. *Кадимге дошман ил булмас.* Мәкаль. *Безгә бүген, дошман килгәнне көтмичә, аңа, аның иленә барымта йөрү мең тапкыр артык булыр.* М.Хәбибуллин. *Дошман илгә керсә, аларга каршы бөтен халык белән сугышырга туры киләчәк.* Ф.Бәйрәмова. **2.** *с.* вражеский, неприятельский

**дошман булу** быть врагом, становиться/стать врагом

**дошман итү** делать/сделать врагом, настроить против себя. *Бу кешене ул дус та, дошман да итә алмады.* М.Хәбибуллин

**дошман күрү** считать врагом, ненавидеть

**ДОШМАНЛАШТЫРУ́** рассорить, раздружить *кого с кем. Ханнар, морзалар, опричниклар, сатраплар – бу мошенниклык мастерлары – халыкларны дошманлаштырып маташалар.* Х.Туфан

**ДОШМАНЛАШУ́** становиться/стать врагами, враждовать. *Инде шулардан соң да дошманлашып торыргамы?* М.Мәһдиев

**ДОШМАНЛЫ́К 1.** *и.* вражда, враждебность, неприязнь; ненависть. **2.** *с.* враждебный, неприязненный. *Безгә урыслар белән сәүдә итәргә, тату яшәргә кирәк, ә Мәскәү баярла-*

*ры бала теленә әллә нинди дошманлык сүзләре салалар.* М.Хәбибуллин

**дошманлык итү (кылу)** враждовать *с кем-л.*

**дошманлык саклау** питать вражду (неприязнь)

**дошманлыкта булу** быть во вражде, враждовать. *Боярдан соң Ермак каршына тагы берничә остяк-вогул князе килде, хәтта аның басып алуыннан курыккан һәм Күчем хан белән дошманлыкта булган берничә татар түрәсе дә килеп Ермак каршында баш иде.* Ф.Бәйрәмова

**ДОШМАНЧЫЛЫ́К** враждебность, недружелюбие, враждебное отношение

**ДӨЛМӘ́Н** доломан (*гусарский мундир*)

**ДӨМБӘСЛӘ́Ү** колотить/поколотить, бить/разбить, раздавить, побить (*противника, вражеское войско*)

**ДӨҢГЕ́Р** *к.* **төңгер**. *Шуннан соң ике якта да, йөрәкләрне җилкендереп, берьюлы унлап-унбишләп дөңгер кагарга тотындылар.* Н.Фәттах

**ДРУЖИ́НА** дружина. *Син ишеттеңме әле, Искәндәр, Тәфтиләү морзаны Палицкий кенәз дружинасы үтереп китә, кызларын әсир итәләр, ә Мөхәммәдъяр үзенең меңбашы белән аларны коткара.* М.Хәбибуллин

**ДРУЖИ́НАЧЫ** дружинник, дружинница. *Ул дружиначы буларак 21 апрельдә иптәш кызы Зоя Кучерова белән «Кармак» операциясендә катнашкан икән.* Т.Нәҗмиев

**ДУЛГА́** *к.* **тулга**. *(Иге Сәет Мәргән) Ишем ханның башындагы дулганы өч чакрым җирдән күреп аткан. Ук тиеп дулганы өзә үткән, аннан барып төшеп җиргә кергән.* Риваять

# Е

**ЕБӘ́** *к.* **җида**. *Уйның утыз бүресенә, инәй, Утыз ебә шай булыр, инәй.* Дастан

**ЕГУ́** побеждать/победить, одолевать/одолеть (*в бою, борьбе с кем-л., чем-л.; в споре, дискуссии и т.п.*)

**ЕГЫЛУ́** полечь, пасть (*в бою, схватке, битве*). *Сугыш кырында егылу* пасть на поле боя

**ЕДА́** *к.* **җида**. *Атаңның шае бар, кылычы бар, саудагы бар, едасы бар.* Дастан

**ЕСАУ́Л** *к.* **ясавыл**. *– Әй, мужик! – дип кычкырды Ермакның хәрби эшләрдә төп ярдәмчесе булган есаул Иван Кольцо.* Ф.Бәйрәмова

**ЕФРЕ́ЙТОР** ефрейтор. *Шуны уйлапмы, миңа да ефрейтор званиесе бирмәкче булдылар.* Л.Ихсанова

# Җ

**ҖА́Н ДОШМАНЫ** заклятый враг; кровный враг

**ҖА́Н САКЧЫСЫ** телохранитель. *Җангали хан тирәли җан сакчылары баскан.* М.Хәбибуллин. *Полковникның җан сакчысы, ягъни адъютанты яшь лейтенант, килеп урнашу белән, бөтен тирә-якны, абзар-кураны, мунчаны, бакчаларны, келәтне карап йөргән иде.* С.Поварисов

**ҖАНДА́Р** телохранитель

**ҖӘБҺӘ́** фронт, линия фронта. *Бу китап, Алманиягә әсир төшкәч, Төркиягә күңелле гаскәр булып китеп, Төркияне саклар өчен җәбһәдә шәһит булган йөзләрчә Идел-Урал егетләренең газиз рухларына багышланадыр.* Г.Исхакый

**ҖӘВӘЛӘНГЯ́Һ** поле битвы. *Иске вакытлардан бирле төрек каумнарының җәвәләнгяһы булган киң сахраларда табылган иске язулар.* Р.Фәхретдин

**ҖӘДРӘ́** *к.* **ядрә**. *Бер җәдрә йөзне үтерер, бер сүз меңне үтерер.* Мәкаль. *Туп җәдрәсеннән үлгәнче, ярман җирендә исән калуың да ихтимал бит әле...* Г.Ахунов

**ҖӘ́НК** *к.* **җәң**. *Баһадирларча мөлакый булып җәнк кылдым.* К.Насыйри

**ҖӘ́Ң** война, битва, сражение, бой. *Итте ул көн ислам әһле җәңге сәхт (авыр сугыш), Кеме – баш кисте, кеме – суйды рәхт.* Мөхәммәт Әмин

**ҖӘҢГЕЛЕ́К** военное дело; военное искусство; военная наука

**ҖӘРГӘ́** строй войск (*шеренга, ряд, цепь*); боевой строй. *Кара һинд явы килде, тезде җәргә.* Котб

**ҖӘЯ́** лук. *Җәядән ату* стрелять из лука; *җәяне бушата төшү* ослабить тетиву лука; *җәяне тарту* а) натянуть тетиву; ә) стрелять из лука. *Аталмаган җәядән күрер.* Мәкаль. *Туры ук тәмеккә тияр, кәкре җәя – кулда калыр.* Мәкаль. *Яуга барган җәясен оныткан.* Мәкаль. *Киерелмәле җәямне Киереп-тартып күрием; Карга йонлы кузымны, Яурын башак угымны – Аны да тартып килием.* Дастан

**җәя бавы** тетива лука; *чаг.* **кереш**. *Ир белән хатын – җәя белән җәя бавы шикелле алар...* А.Гыйләҗев

**ҖӘЯЛЕ́ 1.** *с.* имеющий лук; вооружённый луком. *Җәяле сугышчы* воин, вооружённый луком. **2.** *и.* лучник

**ҖӘЯҮЛЕ ГАСКӘР** пехота

**ҖӘЯЧЕ́** лучник; *чаг.* **укчы.** *Урыс мылтыкчылары туктаусыз ату сәбәпле, җәячеләр баш калкыта алмыйча, таш диварга сыенып ята бирде.* Р.Батулла

**ҖИДА́** копьё, пика; *чаг.* **җыда, чида, чида, еда**

**ҖИҢДЕРҮ́ 1.** *ф.* 1) позволять/позволить победить, давать/дать победить; поддаваться/поддаться; 2) быть побеждённым, потерпеть поражение; поддаваться/поддаться *кому-л., чему-л. Аның әле беркайчан да җиңелгәне юк, бары җиңеп кенә килә.* В.Нуруллин. **2.** *и.* поражение

**ҖИҢЕЛМӘ́С** непобедимый, неодолимый, непреодолимый, непреоборимый; победоносный. *Татарлар беркатлырак һәм ихлас халык, җитмәсә, үзара каршылыклары да күп, менә шулар аша җиңелмәсләрне дә җиңәргә була иде!* Ф.Бәйрәмова

**ҖИҢЕЛҮ́ 1.** *ф.* быть побеждённым, потерпеть поражение; поддаваться/поддаться *кому-л., чему-л. Җиңгән җиңелә дә белер.* Әйтем. *Баскынчылар борын-борыннан бирле җиңелгәннәргә карата вәхшиләрчә кыланганнар һәм һәммә халыкка үз гореф-гадәтләрен такканнар.* М.Хәбибуллин. *Бу*

*сугышта вогул-иштәкләр җиңелсә дә, урысларга уйланырга сәбәп була.* Ф.Бәйрәмова. **2.** *и.* поражение. *Ә җиңелү – үлем дигән сүз.* Ф.Бәйрәмова. **3.** *с.* **җиңелерлек** одолимый, преодолимый, победимый

**ҖИҢЕЛҮЧЕ́** побеждённый, потерпевший поражение. *Җиңелүчеләр ничек яши дә, җиңүчеләр ничек яши?* Т.Нургалимов

**ҖИҢЕ́Ш** победа, успех. *Киң дөнья, минут саен үзгәреп торган хәлләр, планетада барган тартышлар, сугышлар, көрәшләр, җиңешләр, бер мизгелдә кечерәеп, арткы планга-рак күчтеләр.* А.Гыйләҗев

**ҖИҢЕШЛЕ́** победный; успешный

**ҖИҢҮ́ 1.** *ф.* 1) побеждать/победить, побороть *кого-л.*, одерживать/одержать победу *над кем-л.* *Җанын аяган яу җиңә алмас.* Мәкаль. *Сез курыкмагыз, казаклар, ике үлем булмас, берсеннән барыбер котылып булмас, монда үлем язган икән – монда үләрбез, җиңү язган икән – җиңәрбез!* Ф.Бәйрәмова; 2) одолевать/одолеть, преодолевать/преодолеть, осиливать/осилить, сламывать/сломить (*чью-л. волю*), перемогать (*дремоту*), побороть, перебороть *что-л.* *Дошман безне җиңә алмаячак* враг нас не осилит; *дошманның каршылык күрсәтүен җиңү* сломить сопротивление врага. **2.** *и.* победа. *Зур җиңү* большая победа, триумф; *җиңүне бәйрәм итү* торжествовать победу. *Мәскәү кенәзләре гомер-гомергә күп санлы гаскәр белән һәм бихисап корбаннар исәбенә җиңүгә ирештеләр.* М.Хәбибуллин. *Себер солтаннары Мөхәммәткол белән Алинең Уралдан җиңү белән кайтуы бар халыкны аякка бастырды.* Ф.Бәйрәмова

**җиңеп чыгу** одержать победу, победить, побороть *кого-л., что-л.*, восторжествовать *над кем-л., чем-л.*

**җиңеп чыгучы** победитель

**ҖИҢҮЛЕ́** победный, победоносный; триумфальный; наступательный. *Сугышның җиңүле рәвештә бетәчәгенә санаулы гына көннәр калды, туганкайлар.* М.Мәһдиев

**ҖИҢҮЧЕ́** победитель, триумфатор. *Җиңүчегә хөкем юк.* Мәкаль. *Иллә җиңүчеләрне хөкем итмиләр ич.* М.Хәбибуллин

**ҖИҺА́Д** джихад, священная война. *Яуга кузгаласы көн җомга көн иде, намазны Динали сәед үзе укытты, җыелган халык алдында ясаган хөтбәсендә ул бу сугышны дин һәм ил өчен изге сугыш – җиһад дип игълан итте.* Ф.Бәйрәмова

**ҖИҺАНГИ́Р** покоритель мира

**ҖҮРМӘ́** нагайка, плетка

**ҖҮШӘ́Н** военное обмундирование

**ҖЫДА́** *к.* **җида**

# З

**ЗАБИ́Т** офицер. *Саф-саф тезелгән гаскәрләр, ат өстендә командаңнар, забитлар хан өенең ишеге төбенә дәрәҗә-дәрәҗә тезелгәннәр.* Г.Исхакый

**ЗАЛО́ЖНИК** заложник, заложница; *чаг.* **әманәт, рәһен, тотык**. *Заложник итеп үзләре атарга боерык биргән ярлы Тамбов крестьяннарын, Кронштадт матросларын исләренә төшерделәрме икән?* З.Зәйнуллин

**ЗАФӘ́Р** победа, триумф. *Бу триумф иде, бу олы зафәр, зур җиңү иде; бу – еллар буе түккән тиргә, еллар буе түккән нервларга түләү иде.* Р.Батулла

**ЗӘНБӘРӘ́К** пушка; самострел

**ЗИРӘ́Һ** 1) кольчуга; 2) броня

**ЗЫНҖЫ́Р** **1.** *и.* кандалы, вериги, цепи (оковы, путы) *күп.* *Сезнең кулыңызда сәяси көч юктыр ки, зынҗыр вә каһәр берлә яшьләрне изкяр итеңез!* Г.Камал. **2.** *с.* кандальный
**аяк зынҗыры** ножные кандалы
**зынҗыр салу** надевать кандалы, заковать в цепи (оковы, путы)

**ЗЫНҖЫРЛА́У** заковывать в цепи (в кандалы), надевать/надеть кандалы. *Ахыр мәхкәм баглап, берничә әсирләр эченә китереп зынҗырладылар вә, ул урыннан торып, гайре бер тарафка юнәлделәр.* К.Насыйри

**ЗЫНҖЫРЛЫ́ 1.** *с.* закованный в цепь. *Зынҗырлы коллар* невольники (рабы), закованные в цепи (в кандалы). **2.** *и.* кандальник, кандальный. *Зынҗырлылар төркеме* группа кандальников (кандальных); *зынҗырлыларны азат итү* освободить кандальных (кандальников, невольников)

# И

**ИЛБАСА́Р** захватчик, завоеватель, агрессор. *Илбасар белән юлбасар бертуган.* Мәкаль

**ИЛБАСАРЛЫ́К 1.** *и.* захватничество. **2.** *с.* захватнический, агрессивный

**ИЛЕ́М** боец, солдат

**ИЛТӘБӘ́Р** 1) военачальник племени; 2) вассал. – *Юк, Хазар йортның, изге каганның колы... илтәбире, Болгар йортның башы... – дип төзәтте Күрән би.* Н.Фәттах

**ИЛТӘБИ́Р** *к.* **илтәбәр**

**ИЛТИБӘ́Р** *к.* **илтәбәр**

**ИЛХА́Н** ильхан, вождь (*титул высших правителей у тюркских и монгольских народов*). *Әмма Бумын кахан яшь хатын белән озак яши алмый – ул, илхан титулы алып, 552 елда вафат була.* М.Хәбидуллин

**ИНКЫЙЛА́Б** революция. *Гали Афзалетдин улы Динмөхәммәтовның тормышында 20 гасырның беренче яртысында халкыбыз үткән юл искиткеч төгәл чагыла: <...> кыйналган, изелгән, тормышның барлык михнәтләрен үз җилкәсендә татыган күпчелекнең 1917 елгы кораллы инкыйлабка ышаныч белдерүе <...> дә бар анда.* Җ.Юныс

**ИҢСӘ́** плечо (*лука*)

**И́Р** 1) мужчина; 2) муж, супруг; 3) настоящий мужчина. – *Я-я, тор. Ир бул. Беләсең килсә, син миңа кирәксең, туганый.* М.Хәбибуллин; 4) богатырь, храбрец. *Ирнең аты иргә тиң.* Әйтем; 5) воин, витязь. *Шул ук көнне төмән бәгенең боерыгы барлык ирләргә җиткерелде.* Н.Фәттах

**ИРАВЫ́Л** авангард (*часть войск или флота, находящаяся впереди главных сил*). *...Унжциде ир җитеп килгәндә Йосынчының ирләре: Ясавылдан ясавыл, Тоткавылдан тоткавыл, Иравылдан иравыл, Чагдавылдан чагдавыл, Бөкәвелдән бөкәвел – Башына дөнья тар булды, Атланып чүлгә таралды.* Дастан. *Мең кешелек иравыл, өч меңлек уң кул белән ул тиз арада кузгалып китеп, сал-күпердән чыга башларга уйлады.* Н.Фәттах

**ИРӘВЕ́Л** *к.* **иравыл**

**ИРӘ́К** 1) ставка хана, правителя; стоянка главных сил. *Хан ирәге* ставка хана; 2) кремль

**ИХТИЛА́Л** 1) революция. *Ихтилал ясау* совершать революцию; 2) бунт, мятеж, восстание. *Кораллы ихтилал* вооружённое восстание. *Хәлимнең командиры Исәкәй Садиров, җиденче команда башлыгы Юлай Азналин да ихтилалга кушылган.* З.Мурсиев

**ИХТИЛАЛЧЫ́** 1) революционер; 2) повстанец; бунтарь, бунтовщик

# Й

**ЙОЗА́К** затвор, замок

**ЙОЗАКЧЫ́** замковый (*солдат замковой стражи*)

**ЙОРТАВЫ́Л** ертаул (*передовой полк*)

**ЙӨ́З** лезвие (*режущего оружия*). *Батыр егет сазга керә, кылыч йөзенә килеп тотынуы була, яшен чаткысы аның кулын көйдереп ала.* М.Хәбибуллин. *Пычакның йөзе дә салкын һәм үткер иде...* Г.Мирһади

**ЙӨЗБА́Ш** *к.* **йөзбашы**. *Чапкын йөзбаш алдаган булса, аны үлем көтә, хак тәгалә китергән булса – меңбаш булыр һәм йөз алтын аңа.* М.Хәбибуллин

**ЙӨ́ЗБАШЫ** сотник, сотенный (*командир подразделения в сто единиц*). *Йөзбашы чаба-чаба байраклы өйгә китә.* Г.Исхакый. *– Миңа унбашы булу да, йөзбашы булу да кирәкми, –*

*диде Талут.* Н.Фәттах. – *Миңа синең кебек яраннар кирәк. Йөзбашы итәм сине[, – диде Сафагәрәй хан].* Р.Зәйдулла

**ЙӨРӘКЛЕ́** смелый, храбрый; отважный, доблестный

**ЙӨРӘКЛЕЛЕ́К** смелость, отвага; доблесть, удаль

**ЙӨРҮ́** совершать/совершить поход, ходить походом. *Аның угланы Өченче Василий да атасыннан үрнәк ала: Казанга йөреп тора – сугышмый тора алмый.* М.Хәбибуллин

# К

**КАА́Н** *к.* **каган**

**КААНЛЫ́К** *к.* **каганат**. *Без, зәгыйфь коллар, белалмыйбыз Каанлык серләрен...* Һ.Такташ

**КАБА́И АҺӘНИН** тимер өс киеме. *Игненә киеп кабаи аһәнин, Китте сәхрая, әшкяра ул әлине.* Мөхәммәт Әмин

**КАБУРА́** кобура (*пистолета*). *Мылтык, кылыч тагу әсирләргә рөхсәт ителмәгән булса да, [Мөхәммәт] ялтыравыклы ташлар белән бизәлгән буш кабурын да биленә такты.* К.Тинчурин

**КАБЫЗГЫ́Ч 1.** *и.* запал. **2.** *с.* запальный

**КАВАЛЕРИ́СТ** кавалерист. *Кунаклар таралышты, ә Капитан – ярсу кавалерист – тынычланмады.* Р.Камал

**КАВАЛЕРИСТЛЫ́К** положение, служба кавалериста

**КАВАЛЕ́РИЯ** кавалерия. *Кавалерия, авылга кавалерия керде!* Т.Гыйззәт. *1 нче Атлы армияне төзеп, Гражданнар сугышы яланнарында дан алган кызыл кавалерия командиры Думенко Троцкийның тырышлыгы белән 1920 елда юк ителә, кызыл трибунал тарафыннан ялган суд ясап атыла.* З.Зәйнуллин

**КАГА́Н** каган. *Каган – Хазар йортның патшасы.* Н.Фәттах

**КАГАНА́Т** каганат. *Бөек Һун һәм Бөек Төрки каганатлары, уйгур, Кимәк, Кыргыз каганатлары, Алтын Урда ханлыгы,*

*Туран һәм Төмән патшалыклары, Себер ханлыгы һәм Нугай урдалары – болар барысы да Себер киңлекләрендә татар җиһангирләре токкан дәүләтләр, милләтнең алтын чоры...* Ф.Бәйрәмова

**КАГАНЛЫ́К** каганат. *Төрки каганлык чорларында формалашкан кыпчак культурасы шул ук төрки культураны дәвам итә һәм алга таба үстерә генә бара.* Х.Садри

**КАДА́У** вонзать/вонзить, всаживать/всадить, втыкать/воткнуть (*нож и т. п.*). *Шулчак кыз янында басып торган сакчының хәнҗәрен тартып алды да, ике кулы белән өскә күтәреп, үз эченә кадамакчы булды.* Р.Сәгъди

**КАЗА́К** казак. *Ермак үзенә хыянәт иткән яки сугыш вакытында куркаклык күрсәткән казакларны ерткычларча җәзалый торган булган.* Ф.Бәйрәмова

**КАЛАНЧА́** каланча, вышка (*для наблюдения*). *Андый күзәтү каланчалары, гадәттә, зур шәһәрләрдә һәм калкулыкларда төзелгән.* И.Хәйруллин

**КАЛКА́Н** щит. *Сөңгеле яуга тимер калканың әзер булсын.* Мәкаль. *Кулындагы калканы Аның иде өч батман, Иңендәге тимер көбә Аның иде дүрт батман.* Дастан. *Аваз бирде Идегәй – Таймам баскан юлымнан, Салмам сөңге кулымнан, Салмам калкан иңемнең, Яу җыярмын илемнән.* Дастан. *Атымның аягына ук керде дә ат сискәнеп сикерде, мин дә егылдым, торып өлгерә алмадым, бер урыс кылыч берлә салдырды, ат калды, китә идек, калканымны тотып өлгердем, алай да аягыма чапты, киез итек булмаса, аяк киткән иде.* Г.Исхакый

**КАЛЧА́Н** колчан

**КАЛЬГА́** крепость, цитадель. *Татар ханы Габдулла – Биләр-Болгар кальгаларын ныгыта, бөтен халкын баскынчыларга каршы күтәрә, ил белән күтәрелә халык.* М.Хәбибуллин

**КАМАЛА́У** *к.* **камау**

**КАМАЛУ́ 1.** *ф.* осаждаться, подвергаться осаде, быть осаждённым (*о крепости*); блокироваться. *Һәм алар шунда камалган калада очрашалар, тик бер көн дә бергә була*

*алмыйлар – дошман калага бәреп керә.* М.Хәбибуллин. **2.** *и.* осада, окружение. *Казаяклар, берничә бөртек болгарны як-якка сибәләп, камалуны өзделәр дә, ур буенча бераз җир чабып бардылар* <...>. Н.Фәттах

**КАМАЛУЧЫ́** окруженец, оставшийся в окружении (*воин или любой человек*), оставшийся в осаде

**КАМАЛЫ́Ш** окружение, осада; оцепление. *Татар гаскәренең уклары очмый башлаудан Ермак аларның сугышны туктатып торуларын аңлаган иде инде, әмма күпмегә барыр бу камалыш – ул әйтә алмый иде.* Ф.Бәйрәмова

**КАМА́У 1.** *ф.* окружать/окружить, осаждать/осадить, оцеплять/оцепить, блокировать/заблокировать, подвергать блокаде (осаде). *Хәзер хан урыслардан үч ала, нәкъ шул олан әйткән бабасы өчендер, урыс авылларын яндыра, калаларны камый, халыкны әсир итә.* М.Хәбибуллин. *Озакка сузылган Ливон сугышы Россия өчен уңышсыз тәмамлана, 1579 елны шведлар Новгородны алалар, Псков шәһәрен камыйлар, нәтиҗәдә Мәскәү үзе өчен хурлыклы килешү төзергә, ягъни бөтен Балтыйк буе җирләрен яңадан хуҗаларына кайтарып бирергә мәҗбүр була.* Ф.Бәйрәмова. **2.** *и.* окружение, осада, блокада; оцепление. *Җиде ел камауда тота татарларны Мәңге Тимер, җиде ел җаннарын ашый, каннарын эчә.* М.Хәбибуллин

**камап алу** *к.* **камау**. *Тотыклыгының беренче елында, көзгә табан ул – Тотыш углан – ике мең кешелек чирү белән көтмәгәндә суарларны барып басты: калаларын камап алды, коймаларын яндырып, җимереп, катауларын пыр туздырды.* Н.Фәттах. *Һәм алар Сүзген-Каланы камап алдылар, ике атна буе аннан беркемне чыгармадылар, беркемне кертмәделәр.* Ф.Бәйрәмова

**КАМАУЛЫ́** осаждённый, осадный

**КАМЧЫ́** камча, плеть, плётка, хлыст, нагайка. *Арсланга атлансаң, камчың кылыч булсын.* Мәкаль. *Якты Күлдән каһәрләп, сүгенеп, шаулашып, ат өстендә таралучылар да моны шулай аңладылар: шул ачу белән тешләрен кысып, камчыларын селтәп чаптылар.* Г.Ибраһимов

**КАМЧЫЛА́У** бить (хлестать, стегать) плетью (плёткой); пороть/выпороть; наказывать/наказать плетью; бичевать. *Сыерымны үтерделәр – түләмәделәр, хакны сорап бардым – аркамны камчыладылар.* Т.Гыйззәт

**КА́Н ДОШМАН(Ы)** кровный враг. *Чөнки Бельскийлар белән Шуйскийлар – кан дошманнар, пычакка пычак килеп тереклек иткән нәселләр.* М.Хәбибуллин

**КАНА́Т** крыло, фланг. *Уң канаттан рота командирының кул изәгәне күренде.* Г.Бәширов. *Ике канат булып, бераз ара калдырып, Сүрә елгасына таба кузгалдылар.* М.Хәбибуллин

**КА́НКОЙГЫЧ** кровопролитный. *Ике арада канкойгыч сугыш башланып китте.* Ф.Бәйрәмова

**КАҢГЫ́** телега для перевозки оружия в кочевой жизни; телега с запасным оружием (*передвижной арсенал*); *Кыз бала – каңгыда яткан ук.* Мәкаль. *Тотыш углан яткан ялгыз өйне, сүтеп тормыйча, киң арбага – каңгыга урнаштырдылар.* Н.Фәттах

**КАПИТА́Н** капитан. *Капитан әфәнде, андый күңелсез вакыйганы искә төшермик.* Т.Гыйззәт

**КАПИТУЛЯ́ЦИЯ** капитуляция. *Германияне тизләндереп капитуляция ясаттык!* З.Зәйнуллин

**КАПКА́ САКЧЫСЫ** стражник, стоящий у ворот; *чаг.* **тоткавыл**. *Шәһәргә кергәндә, боларны капка сакчысы туктата.* Әкият. *[Феодора] Гап-гади капка сакчысы кызы.* М.Хәбибуллин

**КАПЛА́У 1.** *ф.* прикрывать/прикрыть, ставить/поставть заслон. *Бер өлешебез, көймәләрдә калып, безне ут белән каплый, бер өлешебез сугышка керә!* Ф.Бәйрәмова. **2.** *и.* прикрытие, заслон

**КАПРА́Л** капрал. *Капрал, мыекларын сыпырып, мәчет алдында басып торган картлар төркеменә карап алды.* З.Зәйнуллин

**КАРАБИ́Н** карабин. *Их, кайчан соң инде Фәниярлар шул солдат шикелле кулларына карабин алырлар, өсләренә шинель*

*киярләр.* Ф.Яруллин. *Һәр вагонның баскычында кызыл кырыйлы фуражка кигән, карабин аскан солдатлар тора иде.* М.Мәһдиев

**КАРАВЫ́Л** 1) караул, охрана, стража. *Каравыл алмаштыру* сменить караул; *каравыл кую* выставлять караул. *Торнадан каравыл куйсаң, тиз тотылырсың!* Мәкаль. *Тышта, арба янында каравыл бармы, әллә соң имче аны, әле булса көчсез дип уйлап, үзен генә калдырып киттеме?* Н.Фәттах. *Казаклар Искәргә кереп бикләнделәр, кала диварларына туплар менгереп куйдылар, шәһәр капкасына көчле каравыл басты.* Ф.Бәйрәмова; 2) охрана. *Басу каравылын миңа тапшырдылар* охрану поля поручили мне; 3) *җый.* охрана, стража

**каравыл астында булу** быть под охраной, под стражей; быть под арестом

**каравыл астында тоту** держать под охраной

**каравыл башы** начальник караула. *Күрән би үзенең өлкән углы, каравыл башы Акбогага төтен үрләтергә, икенче углы – субашы Котанга ун каек, йөз ир белән кунакларга каршы китәргә боерды.* Н.Фәттах

**каравыл йорты (өе, балаганы)** караульная, караульня, караульное помещение. *Койма өстендәге каравыл өйләрендә, манараларда, капка төпләрендә көнен-төнен сакчылар кизү торалар иде.* Н.Фәттах. *Элек каравыл өенә җыела торган булганнар, хәзер, шөкер, бакчабыз бар.* А.Гыйләҗев. *Һәм кызыл почмакта сыйланып утырганда, мөдир Сафатдин: – Нурсадә каравыл йортында бозауның дөньяга килгәнен сагалап утыра, – диде.* М.Шаһимәрдәнов

**каравыл каланчасы** сторожевая башня

**каравыл тавы** сторожевая высота, горка (*для наблюдения врага*)

**каравыл тору (булу)** быть в карауле, стоять на карауле. – *Ул бер шәһәреннән икенче шәһәренә күчеп йөри, кирмәнкалалары гаскәр белән саклана, хан бер урында озак тукталмый, аның янында һәрвакыт иң көчле яугирләр каравыл тора...* Ф.Бәйрәмова

**каравылга тарату** разводить караул

**КАРАВЫЛЛА́У 1.** *ф.* 1) караулить, охранять, сторожить. *Патша ич ул, аны меңләгән җансакчылары саклый, аны каравыллыйлар, аңардан куркалар...* М.Хәбибуллин; 2) караулить, стеречь; сторожить. *Чөнки аның башка юлы юк, башка барыр урыны юк – Мәскәү ягында аны патша әмере буенча асып үтерү көтә, Иделдә хәзер аны урыс хәрбиләре каравыллый, ул бары тик Уралда гына вакытлыча тынычлык таба ала.* Ф.Бәйрәмова. **2.** *и.* охрана

**КАРАВЫЛЛЫ́К** караульная служба
**каравыллык итү** караулить, нести караульную службу

**КАРАВЫЛХАНӘ́** караульня, караульная

**КАРАВЫЛЧЫ́** караульщик, сторож, охранник; часовой. *Каравылчыларны бәрә-суга утар ишегалдына килеп керәләр.* М.Хәбибуллин. *Якында гына каравылчы булса, аның йөренгәне ишетелер иде.* Н.Фәттах

**КАРШЫ́ КҮТӘРЕЛҮ** восставать, восстать против *кого-чего-л.*

**КАРШЫ́ҺӨҖҮМ** контратака, контрнаступление, контрудар

**КАРЫМТА́** ответный угон скота; ответный набег. *Алар [күчмәләр] бит һәрвакыт барымта, карымталардан интегеп, табигать шартларына бәйле булып яшәгәннәр.* Р.Зәйдулла

**КА́С** ненавистный враг. *Иленә дус, яуга кас.* Мәкаль. *Үткен пычак кынга кас.* Мәкаль. *Үткер кылыч кынга кас, үтмәс кылыч җанга кас.* Мәкаль.

**КАСӘ́М** клятва, присяга
**касәм итү** клясться/поклясться, присягать/присягнуть

**КАСЫ́Р** крепость, укрепление. *Диделәр, болар – нәби корбаныдыр, Касыр, хыйльгать бонлара – арзанидыр.* Мөхәммәт Әмин

**КАТАПУ́ЛЬТА** катапульта; *чаг.* **мәнҗәникъ**. *Сигарет кабы катапультадан очыртылган кебек тәрәзә пыяласына барып бәрелде.* Р.Мирхәйдәров

**КАТА́У** небольшая крепость на границе. *Акбүре ыруының башы Күрән би үзенең ырудашлары белән яши торган*

*Кызыл Яр катау Чулманның уң ягына – биек, текә ярга җитеп, кырт кына киселгән ачык сырт өстенә урнашкан иде.* Н.Фәттах. *Юл өстендә таланган, яндырылган катаулар очрады.* Н.Фәттах

**КАҺАНЛЫ́К** *к.* **каганат**. *Бу процесс төрки каһанлыклар дәверендә (б.э.ның VI–VII гасырлары) һәм «архаик империяләр» дип аталган башка төрки дәүләтләр заманында. ягъни «төрки» этнонимы барлыкка килгән һәм аннан соң киң таралган борынгы төрки чорда (VI–IX гасырлар) аеруча көчәя.* Татар халкы тарихы

**КАҺАРМА́Н 1.** *и.* герой. *Ә бит кем-кем, Искәндәр белә, Сафа Гәрәй хан тәвәккәл каһарман һәм тапкыр җиһангир ирегет.* М.Хәбибуллин. **2.** *с.* героический, отважный, мужественный

**КАҺАРМАНЛЫ́К** геройство, героизм; храбрость, мужество, отвага; подвиг

**КАЧА́К** 1) беженец. *Сугыш качаклары* беженцы войны; 2) беглец. *Ясавыл, мин монда килгәндә зур өметләр белән килгән идем, хәзер качак хәлендә китәм.* М.Хәбибуллин

**КАЧКЫ́Н** беглец, беглый; дезертир. *Сакал-мыегын да атна чамасы кырмаган, ахрысы, төрмәдән шылган качкын сыман!* Ф.Баттал

**КАЧКЫНЛЫ́К** бегство, дезертирство. *Кайсылары, ул качкынлыкта йөри икән, әнисенең хәлен белергә килгәли икән, дип тә сөйләделәр.* И.Хуҗин

**КӘ́З** деревянная часть стрелы; стрела без наконечника

**КӘЗЛЕ́К** дамский кинжал-стилет. *Ул (Койтым бикә) әледәнәле куенына кулын тыгып, кәзлек сабын тотып-тотып карады.* Н.Фәттах

**КӘМӘ́Р** украшенный пояс (*военного*); рыцарский пояс

**КӘ́НТ** форт, небольшое укрепление (*на границе*)

**КӘРРӘ́** повторная атака

**КӘТАВЫ́Л** комендант (*города, крепости*)

**КӘҮ́Р** *к.* **кяфер**. *Илдә калган минем ир Кузым Инде бер искә төшәрме, кәүр?* Дастан

**КЕРЕ́Ш** тетива; *чаг.* **җәя бавы**. *Кылдан нечкә тартылган Яу [җәя] кереше шул булыр-ай.* Дастан. *Нык тартылган керештәге укны ул, әйтерсең, кире алды.* Н.Фәттах

**КИЕРҮ́** натягивать/натянуть. *Ханбикә аска күз ташлады – татар яугирләре һәрберсе, ук-санайларын тотып, эчке яктан шәһәрне чорнап алганнар, биек диварларда да җәяләрен киереп торткан сугышчылар басып тора...* Ф.Бәйрәмова

**КИЗӘ́К** нәүбәт, чират, сугышта башлап сугу чираты. *Туктамыштай тукал хан Иделдән кубып килгәндә Җаектан кубып барыем. Кизәгемне биргәнче, Кизәнеп сугып калыем, Йорт-казнасын алыем...* Дастан

**КИЗӘ́Ү** надрез на луке для стрелы

**КИЗҮ́ ТОРУ** караулить, стоять на карауле. *Койма өстендәге каравыл өйләрендә, манараларда, капка төпләрендә көнен-төнен сакчылар кизү торалар иде.* Н.Фәттах

**КИЛЕШҮ́** **1.** *ф.* заключать/заключить мир. **2.** *и.* заключение мира, соглашение

**килешү төзү** заключать/заключить мир. *Күпләрне Ермак белән Себерне калдыру турында килешү төзү һәм Мөхәммәткол солтанны азат итү тәкъдиме куандырса да, урысларның бу адымына шикләнебрәк караучылар да булды.* Ф.Бәйрәмова

**КИРӘК-ЯРА́К** *җый.* снаряжение, амуниция. *Күчем хан корал ясау остаханәләрен тагы берничә җирдә ачып җибәрде, хәзер һәр калада диярлек яу кирәк-яраклары җитештерәләр иде.* Ф.Бәйрәмова

**КИРӘҮКӘ́** панцирь (*металлическая одежда*). *Бүз юшанга (ак әремгә) җиткәндә Караң калган кара тун Тугыз күзле кирәүкә – Аны да табып Норадын, Өстенә киеп корганып, Ку күленә юнәлде.* Дастан. *Томан эченнән борынгы батырлар киемендә: башына бакрач, өстенә кирәүкә кигән берәү шәйләнә.* Н.Исәнбәт

**КИРЕ́** обратный, ответный

**кире кайтару** отразить, отбить (*атаку*), заставить отступить. *Кыяларны чокып ясаган ут нокталары эченә кереп поскан немец егерьләре безнең атакаларны берсе артыннан икенчесен кире кайтарып кына торалар.* Г.Әпсәләмов

**кире чигенү** отступать/отступить, отходить (*о войске*)

**кирегә бәрү 1.** *ф.* отдавать/отдать (*о ружье, орудии*). **2.** *и.* отдача

**кирегә чигү** откатываться/откатиться (*об орудии*)

**КИРМӘ́Н** 1) высокая стена крепости, укрепления; 2) крепость; кремль. *Бу мәхшәрдә аның юлдашларының күпчелеге Казан кирмәнендә мәңгелеккә ятып калды...* Ф.Бәйрәмова. *Каланы, кирмән диварларын таштан вә яндырылган кирпечтән күтәртегез.* М.Хәбибуллин. – *Атаң – Казан бәге – сиңа хәзер үк кирмәнгә кайтырга кушты, – диде атчабар.* Р.Зәйдулла

**КИСТӘ́Н** кистень. – *Бүре чабагачлары белән кистәннәр булса, бер погромны түгел, ун погромның әбисенең иманын укытачакбыз, – дип, Сөләймнан ярты сәгатьлек нотык сөйләде.* К.Тинчурин. *Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казып тикшергәндә кылыч, сугыш балтасы, кистән, ук һәм сөңге очлары, дошманның атлы гаскәр һөҗүм итеп килгәндә аяк астына ташлау өчен өч япьле чәнечкеле тимерләр, типке (шпора), көбә, шишәк кебек барлык төр кораллар һәм хәрби киемнәр дә табыла.* Р.Фәхретдинов. *Кистән белән яньчеп илләр башын, Мәет түшәп, юллар салдыра.* Х.Туфан. *Кайчакларны төн буе кулдан кистән төшми.* Г.Бәширов

**КОБУ́Р** *к.* **кобура**. *Лейтенант кобурыннан револьверын чыгарып Галимҗанга төзәде.* С.Поварисов. – *Лошадь есть? – диде [фельдфебель], кулын кобурына куеп.* Г.Ахунов

**КОБУРА́** кобура (*пистолета*); *чаг.* **кабур**. *Өстенә тар погонлы, яшькелт соры френч, аякларында краги белән кара ботинкалар, биленде портупеялы каеш, шуның сул ягында зур пистолет кобурасы.* Ә.Еники

**КОЛЫ́П** 1) запор, засов (*укрепления, крепости*). *Кальга колыбы коллар кулында.* Мәкаль; 2) затвор (*в огнестрельном оружии*)

**КОМА́НДА 1.** *и.* 1) команда (*краткий, устный приказ, приказание, распоряжение*). *Команда бирү* дать команду; *командага буйсыну* подчиниться команде; 2) команда (*подразделение, небольшая войсковая часть*). *Укчылар командасы* стрелковая команда. *Тупчылар командасы* артиллерийская команда. **2.** *с.* командный. *Команда тоны белән* командным тоном; *команда сүзләре* командные слова

**КОМА́НДАЛЫК** 1) командование (*руководство*). *Командалыкны үз кулына алу* принять командование в свои руки; 2) *җый.* командование. *Полк командалыгы* командование полка; *баш командалык* верховное командование
**командалык итү** командовать
**командалык итүче** командующий
**командалык пункты** командный пункт

**КОМАНДА́Н** командир; капитан (*флота*). *Борынгы Сарай шәһәренең команданы Мамай хан Москва князе илә сугышкач, татарларның бер кыйсме русларга әсир төшкән.* Риваять. *Урыс кенәзе Василийның баш команданнары Дмитрий Шемяканы, Дмитрий Юрьевичны күрдек.* Г.Исхакый

**КОМАНДИ́Р 1.** *и.* командир (*боевого подразделения, полка, производства*). *Икенче шәһәрдә мин газеталарның берсеннән командир Таһир Каһармановның госпитальдә үлгәнен белдем.* Г.Кутуй. *Командир иптәш! Мине үзегез белән алыгыз әле. Шундый вакытта хатынны саклап ятасы килми. Мылтык тота беләм.* Ш.Усманов. **2.** *с.* командирский

**КОМАНДИРЛЫ́К 1.** *и.* положение (звание, должность) командира; командирство. **2.** *с.* командирский, командный
**командирлык итү** командовать; исполнять обязанности командира, быть командиром; *чаг.* **командалык итү**

**КОМА́НДОВАНИЕ** командование. *Һәрьяклап үрнәк булганы өчен, командование тырыш кызылармеецларны кат-кат бүләкләде, әти-әнисенә рәхмәт хатлары язды.* Ш.Рәкыйпов

**КОМА́НДУЮЩИЙ** командующий. *8 ноябрьгә каршы төндә башланган Сиваш һөҗүмендә командующий Михаил Фрунзе зур уңышка ирешә.* З.Зәйнуллин. *Баш командующий* главнокомандующий

**КОМЕНДА́НТ** комендант (*крепости, города*); *чаг.* **кәтавыл**. *Иртәгәдән башлап, комендант лагерьда ике атнага карантин игълан итәчәк.* Г.Әпсәләмов

**КОМЕНДАНТЛЫ́К** комендантство; положение (должность) коменданта

**КОНВОЙР** 1) *к.* **конвойчы**. *Аңышырга да өлгермәдем, алыптай калын гәүдәле, чиертсәң каннары сытылып чыгардай бүртек йөзле ике конвоир мизгел эчендә кулларымны артка каерып, чылбырлап та куйдылар.* М.Әмирханов; 2) конвоир (*охранное судно или самолёт*)

**КОНВОИРЛА́У** **1.** *ф.* конвоировать. **2.** *и.* конвоирование

**КОНВОИРЛЫ́К** обязанность конвоира
**конвоирлык итү** конвоировать

**КОРА́Л** **1.** *и.* 1) оружие (*огнестрельное, ядерное, химическое, холодное*). *Корал җитештерү* производство оружия. *Коралга!* к оружию! *Ир мактана, корал җиңә.* Мәкаль. *Корал иясенә дә дошман.* Мәкаль. *Хан өе тирәсендә, кораллар тотып, сакчылар йөренеп торды.* Н.Фәттах; 2) *җый.* вооружение. *Яңа төр кораллар* новые виды вооружения; *коралларны кыскарту* сокращение вооружения. *Шуңа да карамастан, Өченче Иван улганы Өченче Василий Исмәгыйльне яклый: аңа корал белән дә, кирәк тапса, гаскәр белән дә ярдәм итә.* М.Хәбибуллин. *Меңләгән кешене сыйдыру өчен, көймәләр күп кирәк иде, корал, азык-төлекне дә санап, йөздән артык струг-көймә кирәк иде Себер явы өчен.* Ф.Бәйрәмова. **2.** *с.* оружейный. *Корал заводы* оружейный завод; *корал склады* оружейный склад
**корал алу** брать оружие, браться за оружие, вооружаться
**корал йөртүче** оруженосец
**корал остасы** оружейник
**корал коючы** *к.* **корал остасы**. *Шәяхмәт абыйсының, корал коючы Мөхәммәтша абыйсының һәм үзенең яңа*

*дөнья өчен көрәшүгә бушка китмәгәнлеген аңлады [Солтан].* Г.Ахунов

**КОРАЛЛАНДЫРУ́** вооружать/вооружить. *Гаскәр туплау, аны коралландыру 1545 елның гыйнвар аенда гына тәмамланды.* М.Хәбибуллин

**КОРАЛЛАНУ́** вооружаться/вооружиться. *...сикереп торып сүз әйтергә теләүчеләр дә булды, әммә шул мәлдә ишектә бөек кенәзнең баштан-аяккача коралланган сугышчылары – җансакчылары пәйда булдылар...* М.Хәбибуллин. *Ибне Рустә болгарлар атка атланып йөриләр, көбә кием кияләр һәм баштанаяк коралланганнар дип язып калдырган.* Р.Фәхретдинов. *Нурат – теге өрәк булып йөргән шук үсмер – балта белән коралланды.* Т.Нәбиуллин

**КОРАЛЛЫ́** 1) вооружённый, при оружии, имеющий оружие. *Кораллы кул кычулы.* Мәкаль. *Тик койма сакчылары барысы да урыннарында иде, барысы да кораллы, тыныч, кырыс иде.* Н.Фәттах. *...Саклау хәйләсе белән, Третьяк Чабуков койрыгына кораллы отряд та тактылар.* Ф.Бәйрәмова; 2) вооружённый, с применением оружия (*налёт, конфликт и т.д.*)
**кораллы битарафлык** вооружённый нейтралитет
**кораллы көчләр** вооружённые силы

**КОРАЛСЫ́З** безоружный, невооружённый. *Бездә коралсыз кешене кыйнарга ярамый.* Т.Гыйззәт

**КОРАЛСЫЗЛАНДЫРУ́ 1.** *ф.* 1) обезоруживать/обезоружить, отнять оружие; 2) разоружать/разоружить. *Горнизонда бары картрак казачийларны гына калдырып, «ышанычсыз» яшьрәк составны, фронттан кайтучыларны – һәммәсен коралсызландырып, авылларга, станицаларга җибәрәләр.* Ш.Камал. **2.** *и.* 1) обезоруживание; 2) разоружение

**КОРАЛСЫЗЛАНУ́ 1.** *ф.* разоружаться, разоружиться. **2.** *и.* разоружение

**КОРАЛСЫЗЛЫ́К** безоружность

**КОРАЛХАНӘ́** оружейный склад, арсенал. *Ә ул әнә, кайда атына атланып, кайда каекка утырып, ханлыкның бер башыннан икенче башына йөри, ил-җирне кяферләргә каршы*

*көрәшкә туплый, коралханәләрнең эшен барлый, яу кырына сугышчылар барлый...* Ф.Бәйрәмова

**КОРАЛ-ХӘНҖӘ́Р** *җый.* оружие, вооружение. *Һәрвакыт ыспай киенгән абасы бүген хәрби киемнән иде, корал-хәнҗәрләре ялтырап торган морза, Искәндәр ягына күз дә салмыйча, түр яктагы ханбикә янына узды.* М.Хәбибуллин

**КОРАЛЧЫ́** оружейник; *к.* **корал остасы**. *Күр, җамигъ мәчетне зурайтканнар, Туйбикә абыстай мәдрәсәсенең даны тирә-юнь төбәкләргә дә таралган, гыйлем ияләре, төрле һөнәрчеләр-зәргәрләр, коралчы, чүлмәкче, сабынчылар үсеп чыккан.* А.Тимергалин

**КОРАЛ-ЯРА́К** *җый.* боевое снаряжение и защитные доспехи *күп.*, оружие. *Болай да бу арада йокы бик аз эләгә, көндез төрле тикшерүчеләр белән матавыкланасың, төнен инде корал-ярак кабул итәргә туры килә.* Х.Камалов. *Тик менә элек-электән корал-ярак төрләре файдалырак нәрсәләрдән дә тизрәк таралган.* Р.Әхмәтьянов

**КОРГА́Н** *к.* **курган**. *Анда калып Идегәй <...> Кара Тиен Алыпны <...> Гүр казытып күмдерде. Гүре корган тау булды.* Дастан

**КОРУ́ 1.** *ф.* заряжать, зарядить (*пушку, ружьё*). *Мылтык кору* заряжать винтовку. **2.** *и.* зарядка

**КОРУЛЫ́** заряженный (*пистолет, пулемёт*)

**КОРША́У** окружать/окружить, брать в кольцо; *чаг.* **чолгау**. *Шуннан соң заводныкылар ызбаны коршап алганнар.* Риваять

**КОРЫ́К** лассо, укрюк (*для захвата вражеского всадника*). *Корал юкта корык та корал.* Мәкаль. *Комга беткән коба тал, Корык сайлар Кобогыл.* Дастан

**КОРЫЛУ́** заряжаться, быть заряженным (*об оружии*). – *Ялгыз гына йөрмәгез, мылтыгыгыз корылган булсын,* – *дип кычкырды кемгәдер Рәзил.* Г.Гыйльманов

**КОТЫ́К** пороховница

**КОТЫ́Л** *к.* **котык**

**КӨБӘ́** кольчуга, панцирь. *Тузгып йөргән тугыз би Тугыз атка килгәндә, Атланыр ягын тапмады, Баусыз ияр, баусыз ат, Көбәсен киеп менгәндә Ияреннән ауган батырлар Җир басар җир тапмады, Әйләнеп кире атлады.* Дастан. *Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казып тикшергәндә кылыч, сугыш балтасы, кистән, ук һәм сөңге очлары, дошманның атлы гаскәр һөҗүм итеп килгәндә аяк астына ташлау өчен өч яньле чәнечкеле тимерләр, типке (шпора), көбә, шишәк кебек барлык төр кораллар һәм хәрби киемнәр дә табыла.* Р.Фәхретдинов. *...Ишек төбендәге сакчылар тимер көбәләрдән һәм булат кылычлардан...* Ф.Бәйрәмова. *Илбәк үз алдында көбә кигән җайдакны күреп алды.* Р.Зәйдулла

**көбә күлмәк** *к.* **көбә**

**көбә кием** *к.* **көбә**. *Ибне Рустә болгарлар атка атланып йөриләр, көбә кием кияләр һәм баштанаяк коралланганнар дип язып калдырган.* Р.Фәхретдинов

**көбә тун** *к.* **көбә**

**көбә савыт** *к.* **көбә**. *Көзге боздай көдрәгән (ялтыраган) Көбә савыт шул булыр-ай.* Дастан

**КӨБӘ́К** ствол (*ружья*). *Аучыларга «бүре бар!» дип әйт кенә син, бер-берсен уздырып, күгәргән куш көбәкле мылтыкларын эре ядрәләр белән корып, чаба-чаба авыл читенә барып та җиттеләр.* А.Гыйләҗев

**КӨЙМӘ́** лодка. *Су асты көймәсе* подводная лодка

**КӨПЕ́** мягкий, но непроницаемый для стрел боевой предмет одежды. *Егетләрнең өченчесе – карап торуга әүвәлге ике егеткә караганда яшькә зуррагы – көпесен аркасына яба төшеп кырын ятты һәм, кесәсеннән шакшасын алып тезенә бәргәннән соң, пробкасын ачып, сул як кулының учына бер чеметем насбай алып, авызын югары күтәрә төшеп, аскы ирене белән тешләре арасына салып җибәрде дә янган утка карап уйга калды.* М.Гафури

**КӨПШӘ́** дуло, ствол (*ружья*); *чаг.* **көбәк**. *Күз иярмәс тизлек белән мылтыкны көпшәсеннән эләктереп алды да түтәсе белән янындагы каенга китереп бәрде.* Гәр.Рәхим

**КӨРӘ́Ш** 1) борьба; 2) борьба, противоборство

**КӨЧЛӘ́Р** *күп.* вооруженные силы. *Израиль һава көчләре Берләшкән Гарәп Республикасының аэродромнарын, шәһәрләрен бомбага тота, зур танк берләшмәләре бөтен Синай ярымутравында һөҗүм җәелдергәннәр иде.* А.Гыйләҗев

**КРЕ́МЛЬ** кремль

**КРЕ́ПОСТЬ** крепость; *чаг.* **ныгытма, кальга**. *Иван патша аларга бөтен нәрсәгә рөхсәт бирде – бу якларда кала һәм крепостьлар салырга, корал җитештерергә...* Ф.Бәйрәмова

**КУБЫ́Р** кобура; *чаг.* **кабур, кобура**

**КУ́З** оперение (*стрелы*). *Киерелмәле җәямне Киереп-тартып күрием; Карга йонлы кузымны, Яурын башак угымны – Аны да тартып килием.* Дастан

**КУЗГАЛЫ́Ш** восстание; волнение, брожение

**КУ́Л** 1) рука; 2) фланг, крыло; *чаг.* **канат**. *Уң кул урар, сул кур турар, урта кул ук атар.* Мәкаль. *Батыр – тар җирдә кул башлар, чичән – тар җирдә сүз башлар.* Мәкаль. *Карт бүредәй кашкарган, Кап-караңгы төннәрдә Сансыз кулны башкарган, Көн дә сөңге сындырган...* Дастан. *Уң кулында – Ир Каплан, Сул кулында – Кыйгырчак, Маңлай башы – Идегәй, Кыргын юлга юнәлде.* Дастан. *[Хан:] Мәхмүд, син уң кулга баш булачаксың!* Г.Исхакый. *Үзенең өен, олауларын, терлек-туарны сакларга ул урта кул белән сул кулны, чагдавылны калдырырга булды.* Н.Фәттах

**кул гранатасы** ручная граната

**кул сугышы** 1) рукопашный бой. *Син, Гобәйдулла абзый, дошманның кул сугышына шәплеген халыкка гел сөйлисең икән.* З.Зәйнуллин; 2) кулачный бой

**КУНДА́К** ложа (*ружья*)

**КУНУ́** ночевать/переночевать; сделать привал

**КУРГАВЫ́Л** 1) команда охранников, личная охрана (*монарха*); 2) человек из охраны *кого-л.*

**КУРГАВЫЛЛА́У** *к.* **кургау**

**КУРГА́Н** стена укрепления, крепости; вал. *Ялгыз агач урман булмас, ялгыз кирпеч курган булмас.* Мәкаль

**КУРГА́У 1.** *ф.* охранять, защищать/защитить (*окружая со всех сторон*). **2.** *и.* охрана, защита

**КУРО́К** курок; *чаг.* **тәте**. *Гомәр <...> уң кулы белән мылтыкның көпшәсе һәм түтәсе тоташкан нәзек җиреннән тотып алды, имән бармагын курок оясына тыкты, сул терсәге белән өстәлгә таянып, янтыгы һәм сул тезе белән бөтен гәүдәсен кымшанмаслык итеп өстәлгә терәде.* Гәр.Рәхим

**КУЧКА́Р** личный охранник (*знатного лица*)

**КУЧКАРБА́Ш** таран

**КУЧТЫ́** оруженосец; стремянный. *Батырның кучтысы* оруженосец героя

**КУШКӨБӘ́К** двустволка. *Колгага эленгән кәшимир шәлен, чөйдәге сырмасын эләктерде, капчыгын сөйрәп чоланга чыкты, <...> кармалап барып иң кырыйдагы идән тактасын күтәрде, сайгак өстендә яткан кушкөбәкне алды.* Г.Якупова

**КУШЧЫ́** *к.* **кучты**. *Кырык кушчы кол куеп, Кырык дөя әйдәтеп, Кыз куйнында ятадыр.* Дастан

**КУШЫ́Н** войско, рать; войсковое соединение. *Бер кушын ул тага чыктылар, һәман, Килде каршы ләшкәрә – әһле иман.* Мөхәммәт Әмин

**КУЯ́К** *к.* **көбә**

**КҮБӘ́** *к.* **көбә**. *Аткыючтан йөгерек ук булмас, атсаң күбә бозалмас.* Мәкаль

**КҮЗӘ́Т** дозор; разведка; разведывательный отряд. *Күзәттә күзең эленсә, дошман кулына үзең эләгәсең.* Мәкаль. *Үз шәүләңнән курыксаң, күзәткә барма!* Мәкаль

**КҮЗӘТҮ́** наблюдать, следить

**КҮЗӘТЧЕ́** дозорный, разведчик. *Болар юл буенда төн кунган күзәтчеләр иде.* Н.Фәттах. *Безнең ил чигендәге күзәтчеләребезгә Пелым кнізе Аблайның кешеләре килеп әйткәннәр: Ыстругаиыф дигән Урал хуҗалары Ермак гаскәрен Себергә каршы әзерли икән.* Ф.Бәйрәмова

**КҮЗӘТЧЕЛЕ́К** разведка

**күзәтчелек итү** следить, надзирать; разведывать. *Әмма бу юлы эш казаклар уйлаганча булып чыкмады, шымчы «балыкчылар»ны Ябалак күле тирәсендә күзәтчелек итеп йөргән Мөхәммәткол солтан күреп алды һәм үзенең яугирләре белән аларга һөҗүм итте.* Ф.Бәйрәмова

**КҮЗӘ́Ү** прицеливаться/прицелиться, брать (взять) на мушку

**КҮСӘ́К** дубина. *Менә шул чагында кемдер Тотышның башына күсәк белән тондырды.* Н.Фәттах. *Халык кинәт, җил килеп бәргән кебек, гүләп куйды. Сәнәкләр, күсәкләр айкалып китте.* Г.Бәширов

**КҮТӘРЕЛЕ́Ш** восстание. *Ораторлар бу хәзерге эш ташлау хәрәкәтен кораллы күтәрелешкә әйләндерергә чакыралар.* Г.Ибраһимов

**КҮТӘРЕЛҮ́** восставать/восстать, подниматься/подняться. *Татар ханы Габдулла – Биләр-Болгар кальгаларын ныгыта, бөтен халкын баскынчыларга каршы күтәрә, ил белән күтәрелә халык.* М.Хәбибуллин. *Җитмәсә, менә ничә еллар инде илнең көнбатышында поляк һәм литвалылар белән сугыш бара, шведлар урысларга каршы күтәрелә, Кырым ханы килеп, бөтен Мәскәүне яндырып китте, бер Кремль генә утырып калды.* Ф.Бәйрәмова

**КҮШЕ́К** (*угловая*) башня крепости

**КҮШЕ́Н** кош, военный лагерь

**КЫЗЫЛА́РМИЯЧЕ** красноармеец. *Сәясәттән ерак тора Сәләхетдин, элек гап-гади солдат була, берзаман үзен кызылармияче дип йөртә башлыйлар.* К.Миңлебаев

**КЫЗЫЛБА́Ш** кизилбаш (*тюркский наёмник в персидских войсках*)

**КЫЛЫ́Ч** меч, сабля; шашка, палаш, шпага. *Аман кычкырганга кылыч юк.* Мәкаль. *Ике кылыч бер кынга сыймас.* Мәкаль. *Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казып тикшергәндә кылыч, сугыш балтасы, кистән, ук һәм сөңге очлары, дошманның атлы гаскәр һөҗүм итеп килгәндә аяк астына ташлау өчен өч япьле чәнечкеле тимерләр, типке (шпора), көбә, шишәк кебек барлык төр кораллар һәм хәрби киемнәр

*дә табыла.* Р.Фәхретдинов. *Татар гаскәре белән зур кара айгырга атланган, баштанаяк тимердән киенгән, алтын саплы булат кылыч тоткан әзмәвердәй ир-ат юлбашчылык итә иде.* Ф.Бәйрәмова. *Тимери абзагызның үзенең дә заманында ат уйнатып, кылыч айкап, дошман башларын тәгәрәткән чаклары бар иде...* Г.Бәширов

**кәкре кылыч** сабля. *XIII гасырның беренче чирегендә каяндыр Кытай чикләреннән кубып чыккан бихисап татар-монгол явы бәләкәй атларда, кәкре кылычларын уйнатып, кара болыттай ябырылып киләләр дә Болгарны да яндырып, таптап узалар.* Ә.Еники

**кылыч гәүдәсе** клинок меча

**кылыч йөзе** острие меча. *Без барыбыз да үткен кылыч йөзендә йөрибез, Лександр.* М.Хәбибуллин

**кылыч сабы** эфес, рукоятка меча. *Кенәз Василий таныш капка янына туктады да кылыч сабы белән шакыды.* М.Хәбибуллин

**кылыч сырты** тыльная сторона меча. *Кенәз Василий ханның башына кылычының сырты белән сукты.* М.Хәбибуллин

**кылычтан кичерү (үткәрү, уздыру)** *күч.* предавать/предать мечу. *Чөнки Фёдор Пёстрый кенәз бик тә яман кылана, арба чәкүшкәсеннән башы күтәрелгән һәрбер ир-затны кылычтан уздыра.* М.Хәбибуллин. *Күчем хан әйтә: алга таба да нәкъ шулай булачак, татар иленә кылыч белән килгән кеше кылычтан үтәчәк!* Ф.Бәйрәмова. *Туганымнан бирле мин болгарларга каршы астыртын эш алып барам, туганымнан бирле мин кылыч күтәрергә җай көтеп тордым.* Н.Фәттах

**туры кылыч** меч. *Туганай морзаның өстендә Мәскәү кенәзе бүләк иткән камалы сары тун, билендә урысларның янә патша бүләк иткән туры кылыч, башында бәрхет түбәле бүрек.* М.Хәбибуллин. *Уң кулларына алар [урыслар] озын туры кылыч тотканнар, бил каешларына балта белән пычак такканнар иде.* Н.Фәттах

**КЫЛЫЧ-КОРА́Л** *җый.* оружие. *Ошбу юлда тырышып хезмәт иткән һәр мөселман илен генә түгел, кылыч-корал тотып гаилә-күршеләрен дә саклар дип әйтә килде.* М.Хәбибуллин

**КЫЛЫЧЛА́У** рубить/зарубить мечом (*саблей, клинком и т.п.*)

**КЫЛЫЧЛАШУ́** биться на мечах (*саблях*). *Файда юктыр кылычлашып, бер сөйләшик тынычлашып.* Әйтем

**КЫЛЫЧЛЫ́ 1.** *с.* 1) вооружённый саблей, мечом; 2) сабельный. *Кылычлы отряд* отряд конников. **2.** *и.* воин, вооружённый мечом, саблей. *Сафа Гәрәй хан атаң Йосыф бәктән Казанны кире кулыма төшерәм, сәнең биләмәң итәм дип гаскәр сораган, атаң, хәленә кереп, утыз мең кылычлы биргән диләр.* М.Хәбибуллин

**КЫЛЫЧЧЫ́** оружейник; мастер по изготовлению сабель, мечей и т.п.

**КЫМСА́У** *к.* **камау**. *Аксак Тимер килеп Шәһри Болгарны җиде ел кымсап торды.* Риваять

**КЫ́Н** ножны. *Берәү кылыч булса, берәү кын булсын, берәү кызу булса, берәү тын булсын.* Мәкаль. *Казан кабына, кылыч кынына буйсыныр.* Мәкаль. *Күчем хан шунда ук кынындагы кылычына ябышты.* Ф.Бәйрәмова

**КЫНА́П** ножны (*для ножа, кинжала, короткого меча и т.п.*). *Яу булганда Кобогыл Балны эчеп эчмәстән, Пычагын алып кынабтан Сабы белән бер болгар.* Дастан. *Айбалталы Дөрмән би, Кынабы юк бер кылыч, Сабы чыккан бер чукмар Норадынга апкилде.* Дастан. *Аны әйткәндә Норадын Елдырым ташлы пычагын Суырып алды кынаптан.* Дастан

**КЫНЫ́** *к.* **кын**. *Кылыч кынына кисмәс.* Мәкаль. *Биленә кыны буынчы, Бит-кулынңы юынчы. Мин бу кичә төш күрдем, Яхшылык төш ул булса, Яхшылыкка юрачы!* Дастан. – *Китегез, кит! Берегезне дә калдырмый турап бетерәм!* – *дип кычкырды ярсыган яшь җегет, кылычын кыныдан суырып.* Н.Фәттах. *Әмма ярдагылар кулында җилфердәгән татар байрагын күреп, ук-җәяләр төшерелде, кылычлар яңадан кыныга тыгылды.* Ф.Бәйрәмова. *Кыныдагы кылыч белән бергә, Зәңгәр гөлләр исе кулымда.* Х.Туфан

**КЫРГЫ́Н** повальное истребление, резня, геноцид. *Шул Туктамыш өстенә Кыргын җыеп бараем, Әзәлдән килгән киемне Туктамыштан алаем.* Дастан. *Уң кулында – Ир Ка-*

*план, Сул кулында – Кыйгырчак, Маңлай башы – Идегәй, Кыргын юлга юнәлде.* Дастан

**КЫРУ́** истреблять/истребить. *Фетнә була, Казанда урысларны кыралар, күбесе кача әлбәттә, яшеренүчеләр дә булгандыр, чөнки татар халкы күп кенә урыслар белән туганлашкан, аркадаш яшиләр иде инде.* М.Хәбибуллин

**кырып салу** *к.* **кыру**. *Ике яктан да үлүчеләр күп, әмма урысларны илгә уздырмаганнар безнең сакчылар, барысын да диярлек кырып салганнар.* Ф.Бәйрәмова

**КЫРША́У** окружение; *чаг.* **бөҗра, камалыш, камау, чолганыш**

**КЫРШАУЛЫ́** окружённый (*о группе войск*)

**КЫРЫЛЫ́Ш** взаимоистребление, истребление, уничтожение друг друга

**КЫЯ́М** восстание, мятеж. *Капчык һәр яктан тишелә, союзник ямый алмый, көн-төн ишетелеп тора, яңа халык кыямы.* Г.Камал

**кыям итү** восставать/восстать (*на борьбу*)

**КЫЯ́У** латы (*сделанные из бычьей кожи, натянутой на прутья*)

**КЯФЕ́Р** 1) неверный, человек иной веры; 2) враг, недруг

# Л

**ЛАВА́** лава (*боевой порядок конного строя при атаке*)

**ЛА́ГЕРЬ** лагерь. *Хәрби лагерь малайлардан бөтенләй икенче кеше ясады.* М.Мәһдиев

**ЛӘШКӘ́Р** *к.* **гаскәр**. *Бәс, торып иман китерде нәгәзир Ил, вилаять, ләшкәре һәм бикләре – Мөэмин улды. Һәм янә – җөмлә чәри.* Мөхәммәт Әмин. *Шаһ ләшкәре җөмлә аны күрделәр, Камусы ул дәм имана керделәр.* Мөхәммәт Әмин. *Шул заман Габдулла хан ләшкәр егдырды, агыр чиру хәзер кылып каршы йөрде.* Риваять

**ЛЕЙТЕНА́НТ** лейтенант. *Әнә аларны хәзер алгы сызыкка алып баручы лейтенант Сөенчалин да аңардан йөз чөерде.* Х.Камалов

**ЛИВА́** знамя, флаг, стяг. *Тотып милләт ливасын юлга чыктык...* Г.Тукай

**ЛИЧИ́НКА** личинка (*часть затвора винтовки*)

# М

**МАЙО́Р** майор. – *Сез үзегез хәрби кеше, – диде майор Супроненко, – шуңа күрә мине яхшы аңларсыз дип уйлыйм.* Ф.Яруллин

**МАҢГА́Й** центр войска. *Маңгайдан һөҗүм итү* атаковать в лоб

**МАҢГАЙЧА́** налобник

**МАҢЛА́Й** *к.* **маңгай**. *Каршында торган кара яу Туксан башлы урданың Каршыннан килеп акырып, Маңлаена бер сукты, Таңлаеннан ут чыкты.* Дастан

**маңлай башы** командир авангарда. *Уң кулында – Ир Каплан, Сул кулында – Кыйгырчак, Маңлай башы – Идегәй, Кыргын юлга юнәлде.* Дастан

**МА́Р** наблюдательный пост

**МА́РШ** марш. *Синең белән бергә стройда марш атлап җырлап йөрде.* М.Мәһдиев

**МАУЗЕ́Р** маузер. *Безнең яшерен складларда байтак винтовкаларыбыз, пистолет, маузер һәм гранаталарыбыз бар.* Г.Әпсәләмов

**МАҺИЧӘ́** полумесяц на минарете мечети или на древке знамени

**МӘГЪРӘКӘ́** *к.* **мәрәкә**. *Ягъни Әгәр булса сезләрдән 20 сабыр кылгучылар мәгърәкә коталдә, ягъни сугыш йирендә, галиб улыр 200 тән үзәренә мөшрикләрдән, Бу йирдә шарт әмер мәгънәсендәдер.* Тәхризнамә

**МӘНҖӘНИ́КЪ** катапульта. *Бик алыр идең дә, янчыгына кагылсаң, хәзер койма тишегеннән баш зурлыгы бер таш атылып чыга да үзеңне бәреп кенә үтерә. Мәнҗәникъ ташы.* Н.Исәнбәт

**МӘРӘ́** *к.* **мәрәй**. *Мәргән мәрәгә тидерер.* Мәкаль. *Төзәмичә мәрәгә тидерә алмассың.* Мәкаль. *Хәзер инде Капар Миңлебае Краевкада штык сугышына өйрәнә, фашист шәүләсе төшкән мәрәгә ата, граната ыргыта, окоп казый – фашистлар белән сугышырга әзерләнә иде.* З.Зәйнуллин

**МӘРӘ́Й** 1) мишень (*для стрельбы из лука*). *Ирханның дус малае, бик тә шаян һәм башлы малай, маңгаена беркөнне юри мәрәй ясап килде.* Р.Зәйдулла; 2) стрельба из лука (*как состязание, вид спорта*)

**МӘРӘКӘ́** 1) стрельбище; поле брани; 2) скопление народа, праздник, веселье. *Гаҗәп, инде тормыш белән алыш-бирешең бетте дип тынычланганда гына тагын бер мәрәкәсе килеп чыга!* А.Гыйләҗев

**МӘРГӘ́Н** снайпер, меткий стрелок. *Мәргән – угы саен берне бәргән.* Мәкаль. *Мәргән мәрәкәдә беленер.* Мәкаль. *Яурыны яссы, муйны озын, Җәй тартмага кулы озын – Мәргән икән Кобогыл.* Дастан. *Ул да түгел, хан кәләшенең арбасын ыспай киенгән, билләренә кылыч таккан, җәяләрен иң аша ташлаган, ук садаклары көмеш тәңкәләр белән бизәлгән мәргәннәр уратып алды.* М.Хәбибуллин. *Әнә урман аланында мәргәннәр санай-уклар атып ярыша, баһадирлар сөңге бәрешә, кылыч чыңлата.* Ф.Бәйрәмова

**МӘРГӘНЛЕ́К** меткость, мастерство снайпера; умение хорошо стрелять

**МЕ́ҢБАШЫ** тысяцкий; тысячник. *Яуны кара качырыр, җиңгән исеме меңбашына калыр.* Мәкаль. *Меңбашыннан йөзбашы, Йөзбашыннан унбашы, Иравылдан иравыл, Соргавылдан соргавыл, Ясавылдан ясавыл – Бар да атлады каладан.* Дастан. *Калган капкаларга Ходайкол углан үз меңбашларын билгели.* М.Хәбибуллин

**МИЗРА́К** дротик, копьё, пика

**МИНЁР** минёр. *Йөрәк белән эш итүче гашыйк та минёр кебек.* Ш.Галиев

**МИ́НА** мина. *Тыныч заманда тыныч күк астында мина куркынычы булмаган юллардан тыпы-тыпы килеп туган йортыңа таба якыная бару нинди зур бәхет!* М.Мәһдиев

**МИНАМЁТ** минамёт

**МИ́НАЧЫ** минёр

**МИШЕ́НЬ** мишень. *Вертолётның габарит утлары сүнгән, чөнки аларның дошман өчен бер дигән мишень булып куюы ихтимал.* З.Мәхмүди. *Күчерелмә мишень* переносная мишень

**МОБАРИ́З** единоборец, борец; витязь. *Диде кырнак: «Әй мобариз, бәллү бел: Бер хуҗам вардыр, ләгыйнь, бул фозул...»* Мөхәммәт Әмин

**МОРЯ́К** моряк; *чаг.* **диңгезче**. *Без әле моряк та булырбыз, шигырь дә язарбыз!* Н.Фәттах

**МӨБАРӘЗӘ́** единоборство, поединок. *Мөбарәзә мәйданына бу чыккан соң, батырлар була калды югалгандай.* Акмулла

**МӨДАФӘГА́** оборона, защита; самозащита; отпор, сопротивление

**мөдафәга кылу** обороняться, защищаться, сопротивляться, оказывать сопротивление

**МӨЛЧӘ́Р** строй войск; *чаг.* **бүлҗәр**

**МӨХАРӘБӘ́** война, сражение, битва. *Мөхарәбә илә забыт итә алмадылар.* Х.Чистапули

**МУНДИ́Р** мундир. *Аның башында кокардалы фуражка, ялтыр сәдәпле мундир, ә кулларында сөт шикелле ап-ак перчаткалар иде.* Р.Низамиев

**МУ́ШКА** мушка. *Күтәрдем мин мылтыкны, әтәчнең кызыл кикриген нәкъ мушка өстенә туры китердем.* М.Маликова

**мушкага алу** брать (взять) на мушку, прицеливаться. *Мине мушкага алган егетләр үзләре җиргә ауды.* М.Әмирханов

**МУШКЕ́Т** мушкет. *Авыл тирәли сакчылар куеп, яндырылмый калдырылган арсенал янына килделәр һәм тәрәзәсез*

*өй эчендә булган бөтен мушкетларны, дарыны һәм башка кирәк-яракны атларга төяделәр.* И.Хуҗин

**МУШКЕТЁР** мушкетёр. *Башларындагы каурыйларын күрсәң, мушкетёр дип торырсың.* Ә.Дусайлы

**МУШКЕТЧЫ́** *к.* **мушкетёр**. *Аны, татар малае диюдән битәр, француз язучысы Дюма романнарының каһарманы – Урта гасыр мушкетчысы дип атарга булыр иде.* А.Расих

**МЫЛТЫ́К** ружьё; винтовка. *Ат кадерен чапкан белер, мылтык кадерен аткан белер.* Мәкаль. *Атына камчы салган соң, Яуны килеп басадыр, Кайда садак тартадыр, Кайда мылтык атадыр; Кайда кылыч селтәләп, Кайда сөңге белән батадыр.* Дастан. *Аннары кирмән эчендәге мылтыклар, туплар – барысы да аның сугышчылары кулында.* М.Хәбибуллин

**мылтык мае** ружейное масло

**мылтык остасы** ружейный мастер

**мылтык түтәсе** приклад ружья

**мылтык ясаучы** оружейник

**сындырмалы мылтык** централка

**МЫЛТЫКЛЫ́** с ружьём, с оружием, имеющий при себе ружьё (винтовку), вооружённый

**МЫЛТЫКЧЫ́** 1) оружейник; 2) вооружённый ружьём (винтовкой) воин. *Бу хәлгә җен ачулары чыккан Дүртенче Иван мылтыкчыларына халыкка атарга боера.* М.Хәбибуллин

# Н

**НАВО́ДКА** наводка. *Туры наводка белән эше барып чыкмагач, хәйләкәр маневрга күчте: агымы белән аларның тамырын кимерә башлады.* Ф.Яруллин

**НАВО́ДЧИК** наводчик. *Фәрит полкта иң оста наводчикларның берсе булып китте.* З.Зәйнуллин

**НАГА́ЙКА** нагайка. *Синеке дөрес сөйли түгел, нагайка онытты нельзя.* Г.Кутуй

**НАГА́Н** наган. *Маңгайларына наган белән терәгәч тә, баш тартканнар.* З.Мәхмүди. *Хәтта Нарком маршал Ворошиловны да алдап, исемле наган белән сәгать алуга ирешкәнсең.* З.Зәйнуллин

**НАЙЗА́** пика, небольшое копьё, дротик. *Карагай найза таянып, Тукмак яллы турыны Актачыдан тоттырып, Туктамыш хан менгәндә Хан ханәше Йәникә Тезгенгә килеп асылды...* Дастан. *Сулкылдама, ак найза, Суешкан җирдә сынарсың!* Дастан. *Дүрткә аерылып ак найза Түрә авызына төшсә иде!* Дастан. *Касмак бик батыр, куәтле кылыч оргучы, найза тотучы, ук атучы кеше икән, ди.* Риваять

**НАПА́ЛМ** напалм

**НАПА́ЛМЛЫ** напалмовый. *Напалмлы бомба* напалмовая бомба

**НӘБӘ́РД** битва, сражение. *Бакты, күрде ул заман, кем ширмәнд, Кемсә килмәс итмәгә аңа нәбәрд.* Мөхәммәт Әмин

**НӘГӘ́Р** *к.* **нөгәр**

**НӘЙЗӘ́** *к.* **найза**. *Бүген кичә бер төш күрдем, Нәйзә белән чәнчеде.* Дастан

**НӘҮБӘ́Т** караул. *Капка янында да гаскәрләр нәүбәттә капканы саклыйлар.* Г.Исхакый

**НИКРУ́Т** *к.* **рекрут**. *Чынлап та, ул – быел никрут бит.* Г.Ибраһимов. *Ике никрут кереп ишек төбенә бастылар.* З.Зәйнуллин

**НИКРУТЛЫ́К** *к.* **рекрутлык**. *Чөнки аңа никрутлык өчен акча кирәк.* Г.Ибраһимов

**НӨГӘ́Р** дружинник, нукер. *Кыл якалы кырык нөгәр Кылдай булып тартылып, Хансарайга килгәндә, Кыл-кыл чәчен үстергән Кыл түбәле Кобогыл – Ул килгәнен карачы!* Дастан. *Алты кара ат җиктергел, Күп түшәкләр түшәткел, Мамык ястыклар ясаткыл, Ике яхшы нөгәрең утырткыл...* Дастан. *Алар артында урыс явыннан исән калган меңләп нөгәр ияргә берегеп үскәндәй тынып калган.* Р.Зәйдулла

**НҮГӘ́Р** *к.* **нөгәр**. *Калмык түрәсенең улы кырык нүгәре белән Ишем суын кичеп, ау аулап киткәннәр икән.* Риваять

**НЫГЫТМА́** укрепление, крепость; *чаг.* **кальга, кирмән**. *Кальга-кирмән ныгытмасы ерактан ук күренеп тора.* М.Хәбибуллин. *Ханлыкның башкаласы Искәр дә кат-кат урлар белән, таш һәм агач ныгытмалар белән чорнап алынды.* Ф.Бәйрәмова

# О

**ОБО́ЙМА** обойма. *Тукташев пистолетына яңа обойма куйды.* Х.Камалов. *Вилданов пистолетның обоймасын алды да мич артына ыргытты.* З.Зәйнуллин

**ОБОРО́НА** оборона. *Ә дамба калган, хәзер ул оборона ныгытмасы шикелле, бөтен тугайны ямьсезләп, күпме печән бирә торган болынны алып тора.* Ә.Еники
**оборона тоту** занимать (держать) оборону

**ОБОРО́НАЧЫ** оборонец. *Казанга ярдәмгә атлыгучы кырым татарлары кардәшләребезне шундый обороначылар башта туктаткан, аннары чигенергә мәҗбүр иткән.* Р.Зарипов

**ОБОРО́НАЧЫЛЫК** оборончество

**ОКО́П** окоп. *Самат абый әйткән көнне әниләр окоп казырга китте, ә мин Нәсиха җиңгиләрдә калдым.* В.Нуруллин. *Эңгер-меңгер вакытында безнең киемдәге ниндидер солдатлар укчылар окобы янына килеп чыкканнар.* Х.Камалов

**ОЛА́Н** гвардеец, улан

**ОМБЫ́** таран; *чаг.* **таран, кучкарбаш**

**ОҢГЫ́** проушина (*секиры, пики и др.*)

**ОПОЛЧЕ́НИЕ** ополчение. *Ләкин башка ягын да уйладым: кырык беренче елгы ополчение, оборонаны күргән кешеләр күпме калды соң хәзер?* М.Мәһдиев

**ОРА́Н** боевой клич, призыв. *Ул сәбәптән халыкны Бараҗ халкы диер иделәр. Оранннары бараҗ иде.* Риваять. *Садировның ораны яңгырауга алар алга ташланды.* З.Мурсиев
**оран салу** бросать/бросить клич (вызов); кликнуть. *Гаскәрнең бер башыннан икенчесе күренми, ул тоташ*

*бер агым булып, оран салып, җил булып Себер ягына юнәлә...* Ф.Бәйрәмова

**ОРУ́ДИЕ** *к.* **туп**. *Танк туп-туры орудие өстенә ажгырып килә.* Х.Камалов. *Капитан Кәрам Әхмәтҗанов орудиеләрдән ут ачарга команда биргәндә авыз эченнән бик еш: «Әтием өчен дә», – дип әйтеп куя.* Г.Кутуй

**ОРЫ́Ш** война, битва, сражение; брань. *Орышлы җирдән ырыс качар.* Мәкаль. *Сыгыр җылында орыш күп була дип белми әйтмәгәннәр бабайлар.* Н.Фәттах. *Бигайбә, орыш кырында кан коелмый булмый, олуг кенәз.* М.Хәбибуллин. *Татар яугирләре үзләре дә бу урыс коралын өнәп бетерми, аңа ышанмыйча карый, алар орыш вакытында үз көчләренә генә таянырга өйрәнгән иде.* Ф.Бәйрәмова
**орыш кылу** давать бой, сражаться

**ОРЫШ-КЫРЫЛЫ́Ш** *җый.* кровопролитная битва, сражение

**ОРЫШУ́** воевать, сражаться. *– Алайса әйтегез: утыз мең кеш түлибезме, ягы белән орышабызмы? – диде ыру башы.* Н.Фәттах. *Ул кем дә хәзер, мин кем. Ә бит бер сафта орышыр идек.* М.Хәбибуллин

**ОТДЕЛЕ́НИЕ** отделение. *Отделение командирлары алып кайткан мәгълүматлары турында взвод командирына доклад бирделәр, аннары тикшерү башланды.* Г.Әпсәләмов

**ОТРЯ́Д** отряд. *Бу отряд килгән юл халык телендә бүгенгәчә «казаклар юлы» атамасында йөри.* Н.Гариф. *Отряд командиры* командир отряда

**ОФИЦЕ́Р** офицер. *Моны күргән офицерлар берсеннән-берсе уздырып сорау яудыралар, мине үзләренең бердәмлекләре, бер теләктә булулары белән китереп кысмакчылар.* З.Зәйнуллин

**О́Ч** *к.* **очлык**. *Сөяктән ук очлары, сөңге очлары әмәлли беләләр, аларны чәер яки җилем белән таякка ябыштыра алалар.* Т.Нәбиуллин. *Сөңге очы* наконечник пики

**ОЧЛЫ́К** наконечник. *Шуны ничек кирәк алай чүкеп ук һәм сөңге очлыклары, савыт-саба, балта-пычак ясау да әлләни осталык сорамый.* З.Мифтахов

**ОЧЛЫ́М** шлем. *Ул Ермакның башыннан тимер очлымын бәреп төшерде, инде үзен дә юк итәргә дип, тагы кылычын күтәрде...* Ф.Бәйрәмова

**ОЧМА КРЕ́ПОСТЬ** летающая крепость

# Ө

**ӨЗЕЛҮ́** прорваться, быть прорванным. *Госпиталь начальнигы фронтның өзелүе турында әйткәч, Екатерина Павловнаның күз аллары караңгыланып китте.* Г.Әпсәләмов

**ӨЗҮ́** прорывать/прорвать. *Немецлар фронтны өзеп тагын да алгарак үрмәләделәр микәнни?* Г.Галиев

**ӨСТЕ́Н ЧЫГУ** побеждать/победить, взять верх. *Намуслыны җиңәрмен, өстен чыгармын димә.* Г.Хөсәенов

**ӨСТЕНЛЕ́К АЛУ** *к.* **өстен чыгу**. *Аның җирләрендә элек тә утраклыкка күчмәгән һәм күчәргә дә бик үк теләкләре булмаган татар кабиләләре өстенлек ала.* М.Әхмәтҗанов

# П

**ПАЛКА́УНИК** *к.* **полковник**. *Шунда, арыш урганда, бәбиләде ул, йөрәккәем. Хәзер палкауник булып читтә йөри торган малаен тапты ул шунда.* З.Зәйнуллин

**ПА́НЦИРЬ** панцирь (*1) доспех в виде металлической рубахи; 2) металлическая обшивка; броня*)

**ПАТРО́Н** патрон. *Ләкин эшкә җитдирәк караучы халыклар күптәннән инде ул гөрелтеләргә «кысыр патроннар гөрелтесе» дип карый иделәр.* Ш.Камал

**ПАТРОНТА́Ш** патронташ. *Теге эндәшмәде, патронташын атып бәрде, гильзаларның чыжлап чәчелгәне ишетелде.* Х.Камалов

**ПӘНҖӘРӘ́** бойница

**ПӘҺЛЕВА́Н** 1) пехлеван, богатырь, витязь; воин-богатырь. *Калын гөрги тавышлы, пәһлеван гәүдәле, түгәрәк кара*

*сакаллы Ибраһим морзаның, Йосыф бәк белән бәхәсләшеп, бер утыруда бер сарык түшкәсе ашап бетергәне бар.* М.Хәбибуллин; 2) борец-тяжеловес. *Кем атта чапты, кем дөяләрдә узышты, кем уктан атты, пәһлеваннар көрәште, чичәннәр дастан әйтте...* Ф.Бәйрәмова

**ПӘҺЛЕВАНЛЫ́К** богатырьство, геройство. *Аның Дию белән көрәшеп йөрүче «Салсал батыр» кебек көлке пәһлеванлыгына каршы киләләр.* М.Җәлил

**ПЕХО́ТА** пехота; *чаг.* **җәяүле гаскәр**. *Немецларның юллардагы танк колонналарын бомбага тота, «шкас» пулемётларыннан аларның пехотасына ата.* З.Зәйнуллин

**ПЕХО́ТАЧЫ** пехотинец, солдат пехоты. *Дошманның каушап калуын күргәч, гайрәтләнеп китеп, безнең пехотачылар да чигенүдән туктап ут ачтылар.* В.Нуруллин. *Тик эчкәре генә кермәскә кирәк, чөнки бу тирәдә алар иртәнге якта пехотага каршы миналар куйганнар иде, хәзер-хәзер.* М.Мәһдиев

**ПИЛТӘ́** *к.* **филтә**

**ПИСТОЛЕ́Т** пистолет. *Бара торгач, ул үзенә игътибар итмәсеннәр өчен, каешындагы пистолетын алып, кесәсенә салды, ә кобурасын атып бәрде.* Х.Камалов

**ПИСТОЛЕТЛЫ́** имеющий пистолет, с пистолетом. *Габди пистолетлы кулына башын сала.* Э.Яһудин

**ПИСТОЛЕТ-ПУЛЕМЁТ** пистолет-пулемёт; автомат

**ПИСТО́Н** пистон. *Маузер пистонының чакмасы күк, күтәрелде безнең уебыз.* Х.Туфан

**ПИСТОНЛЫ́** с пистоном, имеющий пистон

**ПЛЕ́Н** *к.* **әсир**

**плен(га) алу** пленить, брать (взять) в плен. *Немецлар аны пленга алырга омтылып һөҗүмгә күчәләр.* З.Зәйнуллин

**плен төшерү** брать (взять) в плен (*специально, с особыми мерами*)

**пленга төшү** 1) попадать/попасть в плен. *Пленга төшүең җитмәгән, монда кайтып контр сөйләп йөрисең.* Р.Батулла; 2) сдаваться в плен

**ПЛИ́** пли! (*команда начинать стрельбу*). *Җиңү байрагына җыр язучы Шагыйренә халык дан тели: Данлы шагыйрь Такташ исеменнән Фрицларга яусын, пли, пли!* Х.Туфан

**ПЛИ́Н** *к.* **плен**. – *Тагын нинди хәбәрләр бар? – диде Садыйк карт. – Тегермәнче Чишмәбай плин төшкән.* Г.Ахунов

**ПОГО́Н** погон. *Мин алар белән дуслашып өлгердем, син үзеңнең алтын нашивкаларың, погоннарың белән мине башкалардан аерып куярсың.* М.Мәһдиев

**ПО́ЛК** полк. *Баштанаяк утлы корал белән коралланган полк воеводасы князь Афанасий Лыченицын гаскәре кирәк икән <...> Күчем ханның үзен дә үтерергә тиешләр иде.* Ф.Бәйрәмова

**ПОЛКО́ВНИК** полковник. *Мондый чакта полковникка үзең бару хәерлерәк булыр дигән карарга килде ул.* М.Маликова

**ПОЛКО́ВНИКЛЫК** степень, чин или должность полковника. *Әмма татар булганы өчен аңа полковниклык дәрәҗәсенә ирешү дә җинел булмагандыр.* Х.Миңнегулов

**ПОЛКОВО́ДЕЦ** полководец; *чаг.* **сәргаскәр**. – *Юк, – диде Мәлик, шәһәр алган полководец горурлыгы белән.* М.Мәһдиев

**ПО́ЛКТАШ** однополчанин. *Бу вакытта инде Иргали үзенең полкташы Аким белән шактый ук якынаеп өлгергән иде.* М.Хәсәнов

**ПОЛЫ́Н** плен, пленный

**ПОСКЫ́Н** засада. *Поскын яуны постырыр.* Мәкаль. *Урысларны җиңелү ачысын татудан Шаһ-Галинең поскында торган атлы гаскәре коткарып калды.* Ф.Зариф. *Поскында утыру* сидеть в засаде

**поскын кую** ставить засаду

**ПОСТЫРМА́** небольшая засада, отряд засады. *Шулчак постырмада калган татар сугышчылары, арттан килеп, аларны турый башлый.* М.Гайнетдин. *Постырма җибәрү* послать засаду

**ПОСУ́** *к.* **поскын**. *Дошман көчле, без аз калдык, Сез торыгыз посуда.* Н.Исәнбәт

**ПОХО́Д** поход. *Александр Македонскийның б.э.к. 334–323 еллар арасында ерак көнчыгышка походлары нәтиҗәсендә, Һиндстаннан Карфагенга, Мисырдан Италиягә кадәр гаять зур территория эллинизм йогынтысы астына эләккәч, дөньяның бу өлешендә идеяләр һәм культура алмашы шул чорның үзенчәлекле сыйфатына әверелә.* Татар халкы тарихы

**ПОХОДЧЫ́** поборник похода (походов); воитель

**ПОХОДЧЫЛЫ́К** воинственность; склонность к походам

**ПРИКА́З** приказ, приказание; *чаг.* **боерык, әмер, фәрман**. *Безнең элемтәчеләрдән алынган мәгълүматларга караганда, яңа килгән солдатлар немец командованиесе приказларына теләр-теләмәс кенә буйсыналар.* Р.Мостафин

**приказ бирү** давать/дать, отдавать/отдать приказ. *Бөтен частьларга тәртип белән Кама аръягына чигенергә приказ бирегез.* Т.Гыйззәт

**ПРИКЛА́Д** приклад; *чаг.* **мылтык түтәсе**. *Фин, туктап тормастан, винтовкасын тиз генә борып, приклады белән Зәйнинең башына сугарга омтылды.* З.Зәйнуллин

**ПРИЦЕ́Л** прицел. *Прицелга алу* взять на прицел

**ПРОВИ́ЗИЯ** провизия (*съестные припасы военных*)

**ПУЛЕМЁ́Т** пулемёт. *Пулемёт атудан туктамый торып, дошман алга бару түгел, башын да күтәрә алмый.* Г.Әпсәләмов

**кул пулемёты** ручной пулемёт

**ПУЛЕМЁТЧЫ́** пулемётчик. *Взвод командиры кече лейтенант Зәйнулла Вилданов һәр пулемёттан үзе атып карады, ориентирларның ераклыгын берничә мәртәбә үлчәп чыгып, пулемётчыларга шул саннарны ныклап ятлатты.* З.Зәйнуллин

**ПУ́ЛЯ** пуля. *Мондый чакта, үз башына азына, диләр, ярый әле участковый өченче пуляны башына түгел, аягына җибәрә.* Н.Вахитов

**ПУ́ШКА** пушка; *чаг.* **туп**. *Мин сезгә полк пушкаларын да, утарда булган башка коралларны да бирә алмыйм.* Ф.Бәйрәмова

**ПУ́ШКАЧЫ** пушкарь (*1) литейщик пушек; 2) артиллерист; воин, стреляющий из пушки*)

**ПЫЧА́К** нож. *Булат пычак кынсыз булмас.* Мәкаль. – *Куш-куш пычак асынган, Кушалыклап утау тектергән, Карагай буе ат менгән, Мең чүкечле тимер тун Билен бишкә тарттырган <...> Мөйтәннән туган Кыпчак би, Син бер кереп тулгачы! – дип иде...* Дастан. *Уң кулларына алар [урыслар] озын туры кылыч тотканнар, бил каешларына балта белән пычак такканнар иде.* Н.Фәттах

**пычактан уздыру** резать/перерезать ножом. *...Үзенең мәҗүси динен ташларга теләмәгән халык әүлияларны шулай пычактан уздырган.* Ф.Бәйрәмова

**пычакка пычак килү** 1) быть на ножах, резко схлестнуться. *Чөнки Бельскийлар белән Шуйскийлар кан дошманнар, пычакка пычак килеп тереклек иткән нәселләр.* М.Хәбибуллин; 2) доходить/дойти до резни (драки). *Һәм, әлбәттә, беркемнең дә, бигрәк тә көнбатыш халыкларының, урыска буйсынып яшисе килми, һәм полягы да, шведы да, литвалысы да үз бәйсезлекләре өчен пычакка пычак килеп сугышалар.* Ф.Бәйрәмова

# Р

**РАЗВЕ́ДКА** разведка; *чаг.* **күзәтү**. *...Себер тарафына казак атаманнарын разведкага җибәргән идек...* Ф.Бәйрәмова

**разведка ясау** разведывать/разведать; *чаг.* **разведкалау**. *Башта берсе килеп чыга да, разведка ясап, тикшереп китеп бара, үзәккә хәбәр бирә: фәлән-фәлән җирдә хәрби эшелон күрдек.* З.Мәхмүди

**РАЗВЕ́ДКАЛАУ** разведывать/разведать

**РАЗВЕ́ДКАЧЫ** разведчик. *Әле кичә кич кенә шушы тирәләрдә кызылларның разведкачылары йөргәнне үз күзләрем белән күреп кайттым!* В.Нуруллин

**РАЗВЕ́ДЧИК** *к.* **разведкачы**. *Я, әйттереп бир әле берне, иптәш разведчик, күрсәт егетлегеңне!* Г.Әпсәләмов

**РАЗРЯ́Д** разряд. *Беренче разряд олаулары* обозы первого разряда

**РА́ТНИК** ратник

**РӘДҮ́Т** *к.* **редут**

**РӘМИ́** бросание, швыряние, стрельба. *Мин димен: «Дус, бу рәмиең һич ярамый».* Г.Тукай

**РӘҺЕ́Н** *к.* **тотык**. *Мин үзем олуг углым Мәхмүдне, янымдагы бәкләрем дә үзләренең угылларын сездә тотык (рәһен) итеп калдырамыз.* Г.Исхакый

**РЕ́ДУТ** редут. *Дошман редутлары* вражеские редуты

**РЕЗЕ́РВ 1.** *и.* резерв. **2.** ***с.*** резервный. *Резерв гаскәр* резервные войска

**резервка калдыру** оставить в резерве; не мобилизировать, оставить резервистом

**РЕЗЕРВИ́СТ** резервист; запасник. *Бары күпләгән резервистларны чакыру ярдәмендә дүрт айдан соң гына СССР бу сугышта өлешчә үз максатына ирешә.* Х.Миңнегулов

**РЕ́КРУТ** рекрут; новобранец; *чаг.* **никрут**. *Юк, бу эшкә, бу көрәшкә безнең бөтенләй башка коралларымыз кулымызда: рекрутлар да безнең кулымызда, имана түләүләр дә безнең кулымызда, кара көч тә безнең кулымызда.* Г.Камал

**РЕ́КРУТЛЫК** рекрутчина, рекрутство; *чаг.* **никрутлык**. *Эзәрлекләүләргә каршы көрәшкән кебек үк, рекрутлык битлеге астына яшерелгән законсызлыкларга каршы да көрәш алып барганнар.* М.Гайнетдин

**РИЗЫ́К** *к.* **азык-төлек**. *Ниһаять, барысы да әзер булды – сораган кадәр корал һәм ризыкны, байрак һәм иконаларны да көймәләргә төяделәр.* Ф.Бәйрәмова

**РОГА́ТКА** 1) рогатка (*1) метательное холодное оружие; 2) продольный брус со вдолблёнными накрест палисадинами, для преграды пути*). *Танкка каршы рогаткалар* противотанковые рогатки

**РО́ТА** рота. *Ике ротаны да Ленинградка озаттылар.* З.Зәйнуллин

**РЫ́ЦАРЬ** рыцарь; *чаг.* **алып, алпар**. *Рыцарьлар җиңүле походтан кайтканнар.* М.Мәһдиев

**РЯДОВО́Й** рядовой; солдат. *Алынган плацдармны зур югалтулар белән кулдан ычкындыруыбыз өчен, аны рядовойга кадәр төшерделәр.* И.Хуҗин

# С

**САВЫ́Т** панцирь, латы. *Ак савытның якасы бар, җиңе юк, чын яхшының ачуы бар, үче юк.* Мәкаль. *Шаһ Тимердән бер батыр – Уң кул бие Ир Каплан, Кигәне көмеш ак савыт, Көн ярыктай балк итеп, Тугыз батман, тугыз теш Туң чукмарын кулга элеп, Ат сикертеп уртага, Мәйдан тотып туктады.* Дастан. *Шалтыр-шолтыр чыңлап савыт-сайман, Өстебездә сөңге җайнады*. Ш.Бабич. *Моны белгәннән соң ике мәргән шайланып яуга чыктылар. Савыт киеп атышырга чыктылар.* Риваять

**САДА́К** 1) колчан (*для лука и стрел*). – *Садагын кырык нарга тарттырган, Салтанатын Улда белән Вылдадан арттырган, Хан алдында ат тоткан, Тамагына алты хат тыккан – Кәмалның улы Киң Җанбай, Киңәшең артык би Җанбай.* Дастан. *[Идегәй] Җирдә яткан садагын Иелеп алып бер киде.* Дастан. *Биктимер аның тунын салырга булышты, җәясен, садагын бер читкә алып куйды.* Р.Зәйдулла; 2) стрела. *Садактан йөгерек ук булмас, атсаң тимер кап чыдамас.* Мәкаль

**СА́К** пост, охрана, стража. *Саклының сагы ятыр, саксызның башы ятыр.* Мәкаль. *Мөхәммәткол солтанны, аяк-кулларын богаулап, тизрәк сарайдан алып чыгып киттеләр һәм ташпулат базларының берсенә яптылар, ишек-тәрәзәләргә көчле сак куйдылар.* Ф.Бәйрәмова

**сакта тору** быть (стоять) в карауле (на страже). *Хан тирәсенә аның уллары, якыннары, морза һәм бәкләре, карача һәм сәедләре тезелеп баскан, тәхет янында да, ишек төбендә дә хәнҗәр һәм сөңгеләр тоткан яугирләр сакта тора.* Ф.Бәйрәмова

**сакта торучы** стражник; караульный. *Әмма хан гаскәре инде шәһәр капкасына килеп җиткән, биредә сакта торучы казакларны таптап-изеп, эчкә бәреп кергән иде.* Ф.Бәйрәмова

**САКАЛДЫРЫ́К** подвязка для шлема на подбородке. *Алпак башыннан төшеп китмәсен өчен, ул ияк астыннан сакалдырыгын бәйләп куйды да, кысып билен буды да, кылычын такты.* Н.Фәттах

**САКЛАНУ́** защищаться/защититься, обороняться. *Шөкер, илләр тыныч, ханлык чикләре нык саклана, казнада байлык җитәрлек, халык та ач-ялангач түгел, димәк, онытылып бәйрәм итәргә дә була!* Ф.Бәйрәмова

**САКЛА́У** защищать/защитить, оборонять. – *Әти, мин кырык каек санадым, алар барысы да безне саклыймы? – дип каршы алды аны кызы Ләйләгөл, иркәләнеп.* Ф.Бәйрәмова

**САКЧЫ́** 1) сторож; страж, охранник, караульный, часовой. *Ишекъяры саен баскан сакчылары аны баш иеп каршы алдылар, бил бөгеп озата калдылар, әмма Йосыф бәк гадәттәгечә аларга сәлам юлламады...* М.Хәбибуллин; 2 стража, охрана. *Күчем, юлда очраган сакчылары, әмирләре, карачалары белән сөйләшә-киңәшә, шәһәр буйлап китте.* Ф.Бәйрәмова. *Койма өстендәге каравыл өйләрендә, манараларда, капка түпләрендә көнен-төнен сакчылар кизү торалар иде.* Н.Фәттах

**САЛДА́У** острога

**САНА́Й** лук (*один из видов*). *Өнәндә үтте ун батыр, Ун батырдан иң батыр Санае күк соландай, Тартып атса санаен Күктә йолдыз югалткан, Күк батыр дип аталган – Аны күргән картыңмын.* Дастан. *Ул санай угы белән калмыкларны куалап җибәргән, бичәләрне алардан саклап калган.* Риваять

**САНҖА́К** знамя, флаг

**СА́П** ложа (*винтовочная, оружейная*); *чаг.* **кундак**

**САПКА́Н** праща

**САПКАНЧЫ́** пращник

**САРАВЫ́Ч** козырёк шлема; надлобная часть шлема

**САРДА́Р** *к.* **сәрдар**

**САУГА́** военнопленный. *Батырдан сауга, мәргәннән сыралкы.* Мәкаль

**САУГА́Т** *к.* **сауга**. *Как сөяген каерып, Куйдай итеп маерып, Ир Капланны өереп, Туктамыш хан кашына Саугатка алып китерде.* Дастан

**САУДА́К** *к.* **садак**. *Саудакларын янбаш астына куйган.* Дастан

**СА́Ф** ряд, шеренга, строй. *Алгы сафка атлылар тезелгән, алар артыннан сөңгечеләр килә, артта олаулар күренә, хатын-кызлар.* М.Хәбибуллин

**СӘЕ́Ф** сабля, шашка. *Мостафа Сәефелмөлек, сәефең – белек, юк һич хафа.* Ш.Бабич

**СӘНӘ́К** вилы *күп. Ак бандитлар, кылычларын, сәнәкләрен айкый-айкый улап, акырып, Җәүдәтләрнең артына төштеләр.* Г.Бәширов

**СӘНҖА́К** *к.* **санҗак**. *Гаскәр алдында туг вә сәнҗак.* К.Насыйри

**СӘРГАСКӘ́Р** командующий войсками; главнокомандующий; полководец. *Сәргаскәрләр бер сәгатьтә биш мең адәмне тәйяр кылып куйдылар.* Дастан

**СӘРГАСКӘРЛЕ́К** должность или положение главнокомандующего

**СӘРДА́Р** командир. *Җиңү яулау өчен яхшы өйрәтелгән регуляр армия һәм талантлы сәрдар кирәк икән.* З.Мурсиев

**СЕМӘ́К** шпиль на шлеме, острая верхушка шапки; наконечник стрелы, штырь

**СЕРЖА́НТ** сержант. *Өлкән сержантның бу сүзләреннән соң, яралы янына тезләнгән врачның башын күтәреп борылып каравына бирәү дә игътибар итмәде.* Г.Әпсәләмов

**СИЛА́Х** оружие. *Солых белән силах бергә җыелмый.* Мәкаль

**СИПА́Һ** войско, армия. *Вар иде Багдадта бер падишаһ, Маләсбаб иясе һәм бихад сипаһ.* Мөхәммәт Әмин

**СИПАҺИ́** воин, солдат. *Гаятенчә һәм белер бонлар сипаһилар эшен.* Габдессәлам

**СНА́ЙПЕР** снайпер; *чаг.* **мәргән**. *Каракүз башлыгында костёл янына йөгергән тупчылар бер умырылып беткән киемле немец снайперы гәүдәсен күтәреп килделәр.* Х.Камалов

**СОЛДА́Т** солдат. *Ә нигә соң аны су эчендә тоталар, әнә өстендә солдатлар да йөреп тора, ди.* Т.Гыйззәт

**СОЛЫ́Х** мир, перемирие. *Солых белән силах бергә җыелмый.* Мәкаль. *– Ермак сиңа солых тәкъдим итә! – диде Мөхәммәткол солтан.* Ф.Бәйрәмова

**солых төзү** заключить мир. *Көтелмәгән бу хәлдән мәскәүлеләр сәясәтне кинәт борырга ниятлиләр һәм Польша короле белән солых төзеп Казан ханлыгын акылга утыртырга җыеналар.* М.Хәбибуллин

**СОЛЫХНАМӘ́** мирный договор

**СОРГАВЫ́Л** задний дозор, аръергард; дозорный, оставленный позади основного войска. *Барып бер күрде таш тияк, Таш тияккә җиткәндә, Анда тапты соргавыл. Соргавылны күргәндә Идегәй ир аны әйтте: – Әй соргавыл, соргавыл, Туп-туп баскан, туп баскан, Тоягы җирне тумырган. Тумырылып яткан җир күрдем.* Дастан

**СӨЛЕ́К** (*лучший*) солдат; тренированный воин

**СӨМӘ́К** *к.* **семәк**

**СӨҢГЕ́** копьё, пика. *Сапсыз сөңгедән саплы сәнәк яхшырак.* Әйтем. *Аваз бирде Идегәй: – Таймам баскан юлымнан, Салмам сөңге кулымнан, Салмам калкан иңемнән, Яу җыярмын илемнән.* Дастан. *Күп сөйләп йөрмәгез, яман сүз дөрләп янган уттан да, аел очлы сөңгедән дә ямандыр.* М.Хәбибуллин. *<…> яшьләр көн-төн үзара бәйге тоттылар – ук аттылар, сөңге чөйделәр, төрлечә көчләрен сынаштылар.* Н.Фәттах. *Углан аның аркасына төбәп сөңгесен күтәрде.* Р.Зәйдулла

**сөңге атучы** *к.* **сөңгече**. *Сафа Гәрәй хан бөтен төрки гаскәриләре арасында иң оста сөңге атучылардын санала*

*иде һәм бу корал белән алышканда беркайчан да ялгышмады.* М.Хәбибуллин

**сөңге очы** *к.* **башак**. *Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казып тикшергәндә кылыч, сугыш балтасы, кистән, ук һәм сөңге очлары, дошманның атлы гаскәр һөҗүм итеп килгәндә аяк астына ташлау өчен өч япьле чәнечкеле тимерләр, типке (шпора), көбә, шишәк кебек барлык төр кораллар һәм хәрби киемнәр дә табыла.* Р.Фәхретдинов

**СӨҢГЕ-КЫЛЫ́Ч** *җый.* оружие; копьё и меч. *...Нәрсә булса, [халык] һаман шул ук-җәясенә барып тотына, сөңге-кылычына ябыша.* Ф.Бәйрәмова

**СӨҢГЕЛЕ́** вооружённый копьём или пикой; с копьём. *Иделнең сахралы ягында дөяләргә, атларга атланган озын сөңгеле халык яр буена чабып төшеп кычкыра, бакыра башлап, боларның туктауларын сорый торган галәмәтләр күрсәтә башладылар.* Г.Гобәйдуллин

**СӨҢГЕЧЕ́** копейщик, пикенёр; воин, вооружённый копьём; копьеносец. *Кылычлы, уклы ирләрдән соң изге түгәрәккә сөңгечеләр килеп керде.* Н.Фәттах. *Алгы сафка атлылар тезелгән, алар артыннан сөңгечеләр килә, артта олаулар күренә, хатын-кызлар.* М.Хәбибуллин

**СӨРӘ́Н** 1) (*тревожный*) боевой клич; тревога; 2) крик перед боем

**сөрән салу (кычкыру)** 1) с боевым кличем звать на бой; 2) бить тревогу

**СТА́ВКА** ставка. *«Татар изүеннән котылу» татар ханын православие патшасына алыштыруга һәм хан ставкасын Мәскәүгә күчерүгә генә кайтып кала.* Татар халкы тарихы

**СУ́БАШЫ** главнокомандующий, полководец; *чаг.* **сәргаскәр**. *Патша субашын чакырып алды да: – Хәзер үк шәһәрдәге барлык йортларның ишек бауларын тикшерегез, – диде.* К.Насыйри. *Күрән би үзенең өлкән углы, каравыл башы Акбогага төтен үрләтергә, икенче углы – субашы Котанга ун каек, йөз ир белән кунакларга каршы китәргә боерды.* Н.Фәттах

**СУГЫ́Ш** 1) война. *Җитмәсә, менә ничә еллар инде илнең көнбатышында поляк һәм литвалылар белән сугыш бара, шведлар урысларга каршы күтәрелә, Кырым ханы килеп, бөтен Мәскәүне яндырып китте, бер Кремль генә утырып калды.* Ф.Бәйрәмова; 2) сражение, битва; бой

**кул сугышы** рукопашный бой. *Әмма яугир артыннан яугир ава башлагач, эш кул сугышына да барып җитте, кылыч һәм хәнҗәрләр хәрәкәткә килде.* Ф.Бәйрәмова

**сугыш аты** боевой конь

**сугыш балтасы** боевой топор. *Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казып тикшергәндә кылыч, сугыш балтасы, кистән, ук һәм сөңге очлары, дошманның атлы гаскәр һөҗүм итеп килгәндә аяк астына ташлау өчен өч япьле чәнечкеле тимерләр, типке (шпора), көбә, шишәк кебек барлык төр кораллар һәм хәрби киемнәр дә табыла.* Р.Фәхретдинов

**сугыш кыры** поле битвы. *Казанлылар гомер-гомергә сугыша белмәделәр, сәүдә итәргә яраттылар, сугыш кырында орышу алар өчен ят нәрсә, хәзер дә әллә ни үзгәрмәгәннәрдер.* М.Хәбибуллин. *Җитмәсә, иштәквогулларның барысы да диярлек сугыш кырыннан качып беткән, аларны инде Искәр тирәсендә эзләп табарлык та түгел...* Ф.Бәйрәмова

**сугыш мәйданы** *к.* **сугыш кыры**. *Бу ут яңгырына иң беренче булып иштәк-остяклар түзмәде, алар, акрынлап, агачлар арасына йөгерделәр, аннан бөтенләй сугыш мәйданын ташлап качтылар.* Ф.Бәйрәмова

**үзара сугыш** *к.* **эчке сугыш**. *Үзара сугышлар, урман далагагы ялгыз тормыш безнең халыкны тагы кыргый хәлгә төшермәсме дип куркам.* Ф.Бәйрәмова

**эчке сугыш** гражданская война; междоусобица. *Эчке сугышлар сәбәпле, монда күп нәрсә бозылган, дәүләт тотуның рәте китkән, җитмәсә, халык та диннән-гыйлемнән шактый читләшкән булып чыкты.* Ф.Бәйрәмова

**СУГЫШУ́** 1) воевать, сражаться, биться. *Яуны санап сугышмыйлар.* Мәкаль. *Баярлар, безгә Сафа Гәрәй хан белән сугышырга түгел, килешү төзергә һәм сәүдә итәргә кирәк.*

М.Хәбибуллин. *Әмма Себер халкы Ядегәрнең Мәскәүгә сатылуын кабул итмәде, җиде ел буе аңа каршы сугышканнан соң, тәхеткә Чыңгыз хан нәселеннән булган Күчем хан менеп утырды.* Ф.Бәйрәмова; 2) драться/подраться; сцепиться. *Ул арада бер яктан зур ак бүре, икенче яктан кап-кара эт килеп чыктылар да ырылдашып сугыша башладылар.* Ф.Бәйрәмова

**СУГЫШЧА́Н** 1) боевой. *Патша тыйган сугышчан армия дип аталмасалар да, бу шул ук хәрби гаскәр иде.* Ф.Бәйрәмова; 2) воинственный. *Ә бит ошбу шәех үзенә менә дигән сугышчан мөридләр туплады, бер-берсе ун сугышчыга торырдайлар.* М.Хәбибуллин. *Котлау көйләреннән соң бары җиңү туйларында гына яңгырый торган сугышчан көйләр уйналды.* Н.Фәттах

**СУГЫШЧАНЛЫ́К** 1) боевитость; 2) воинственность

**СУГЫШЧЫ́** 1) воин, боец. *Бүгеннән башлап син – сугышчы ир!* Н.Фәттах. *Ул гынамы, кызының тынычлыгын саклар өчен, өлкән угланы җитәкчелегендә өч мең сугышчы килә.* М.Хәбибуллин. *Татарларның хәтта тимер көбә бөҗраларын өзә торган дүрткырлы уклары да бар иде, шуңа күрә урыс сугышчыларын тимер киемнәре дә саклап бетерә алмады.* Ф.Бәйрәмова; 2) (*рядовой*) боец, солдат

**СУЕ́Л** дубина; палица. *Суелны сала белмәгән үзенә тигезер.* Мәкаль

**СУРГАВЫ́Л** *к.* **соргавыл**. *Шаһ Тимергә Идегәнең күрсәткәннәре ятыш күренде. Ул тизлек белән гаскәрен (чирүләрен) йыйды. Сугыш кораллары, ерткычларын тайярлады. Иравыл, чагдавыл, сургавылларга бүлде.* Дастан. *Инде Мөхәммәткол солтан да яраларыннан савыгып килә, авырлык белән булса да, атка атланып чыгып, сургавыллары белән Искәр тирәләрен күзәтеп йөри иде.* Ф.Бәйрәмова

**СЫБА́Й** всадник, верховой

**СЫНҖА́К** *к.* **санҗак**

**СЫРГАВЫ́Л** 1) шест, столб; 2) *к.* **соргавыл**

**СЫРГА́Н** крепость на горе

# Т

**ТАБЫ́Р** табор, военный лагерь, окружённый телегами

**ТАЛДА́У** *к.* **талта**

**ТАЛПА́** отряд-прикрытие (*состоящее из ополчения*); ополчение

**ТАЛТА́** 1) тыл; 2) заслон, защита от нападения; *чаг.* **талдау**

**ТА́НК** танк. *Төнге өчтән соң гына Ильяс хәбәр ала: урыс танклары башкача урыннарыннан кузгалмаячаклар.* З.Зәйнуллин

**ТАНКИ́СТ** танкист. *Моннан өч ел элек танкистларның Магдебург полигонында аларга, яшь танкистларга, бер яшерен җайланма – яңа танкларга куелырга тиешле булган төнлә күрү приборларын күрсәткәннәр иде.* А.Хәлим

**ТА́НКЧЫ** танкист

**ТАРАВЫ́Л** направляющий (*в войсках*)

**ТАРА́Н** таран; *чаг.* **омбы**. *Бүтәннәр, алдан әзерләнгән бүрәнәләрне алып килеп, шул бүрәнәләр белән капкага таран ясарга керештеләр.* Г.Әпсәләмов

**ТАШАТКЫ́Ч** камнемёт; катапульта; *чаг.* **мәнҗәникъ**. *Сафа Гәрәй хан кирмәнне камый, әмма туплары, ташаткычлары юк, ә Казан кальга-кирмәнен ук-кылыч, сөңге белән генә алыйм димә.* М.Хәбибуллин

**ТАШЛА́У** метать/метнуть, бросать/бросить, кидать/кинуть. *Мәргәннәре очкан кошны атып ала, бер селтәнүдә кылыч белән кешене урталай яра алган батырлары бар, чапкан ат өстенә басып, дошман күкрәгенә сөңге ташлап, бичараны диварга кадаклап куя торган баһадирлары да җитәрлек.* М.Хәбибуллин

**ТӘМЕ́К** мишень. *Туры ук – тәмеккә тияр, кәкре җәя – кулда калыр.* Мәкаль. *Әмма барыбер йөгерештә берәүне дә уздырмаучы, үзе ясаган җәядән укны тәмеккә – ә мишень итеп бакча башындагы биек төпне сайлый идек без – бе-*

*ренче атуда кадалдыручы җитез хәрәкәтчән малайның мин күргән Миркадимгә әйләнүе хыялда гына мөмкиндер, дигән шигем бетте.* М.Хуҗин

**ТӘНСАКЧЫ́** телохранитель; *чаг.* **курчы**. *Күчем хан исә биек тау башындагы күзәтү мәйданына урнашты, аны уллары һәм тәнсакчылары урап алган, ике ягына Карача вәзир белән Динали сәед басканнар иде.* Ф.Бәйрәмова

**ТӘ́Н САКЧЫСЫ** *к.* **тәнсакчы**

**ТӘПӘЛӘШҮ́** биться (*между собой*). *Сөңге атышалар, тәпәчләр белән тәпәләшәләр, чукмарбашлар белән бәргәләшәләр [Япанча атаканың баһадирлары].* М.Хәбибуллин

**ТӘПӘ́Ч** бита, боёк, било. *Кулларына бер башы йомры, икенче башы үткен итеп юнылган тәпәчләр тоттылар.* Г.Гыйльманов

**ТӘТЕ́** курок, собачка (*ружья*). *Ул тәтегә баса алмады.* М.Маликова. *Әстәгъфирулла, хатыным-бәгырькәем чынлап торып котырган гориллага охшап калган: ике күзен кан баскан, чәчләре пумаладай тузган, бер бармагын – пистолет тәтесенә, икенчесен автоматныкына терәгән.* Ф.Баттан
**тәте тарту** спустить курок

**ТЕЗЕ́М** строй (*боевой, пехотный*). *Теземгә басу* встать в строй

**ТЕ́Л** язык (*человек из лагеря противника, используемый для получения информации*). *Кайсы гына малайның, Марат Казей яисә Валя Котик төсле, дошман тылына чыгып «тел» алып кайтасы килмәде икән?* Р.Зәйдулла. *Гвардия сержанты «тел»не штабка тапшырырга тиеш иде.* А.Әхмәт

**ТЕРКЕ́Ш** колчан, вместилище для стрел

**ТИГӘЛӘ́Й** тегиляй *(утепленная ватой военная одежда). Хуҗаш дигән ир әйтер: Ятыр идем бер бостанда, Бостаны терәкнең төбендә Тигәләйне түшәнеп, Алтын ияр ястанып.* Дастан

**ТИЗАТА́Р** скорострельный. *Тизатар туп* скорострельная пушка

**ТИЗАТКЫ́Ч 1.** *и.* скорострельное оружие (*ружьё*). **2.** *с.* скорострельный

**ТИМЕ́Р 1.** *и.* железо; металл. **2.** *с.* железный; металлический

**тимер кием** *к.* **тимер күлмәк**. *Алар барысы да, яуга чыккан сыман, баштанаяк күн, тимер киемнәргә киенгәннәр, ук-җәя белән, сөңге белән коралланганнар иде.* Н.Фәттах. *Ә монда атлаган саен кала, кала саен мәрмәр сарай, сарай саен алтын капка, капка саен тимер киемле яугир басып тора!* Ф.Бәйрәмова

**тимер көбә** *к.* **тимер күлмәк**. *Кулындагы калканы Аның иде өч батман, Иңендәге тимер көбә Аның иде дүрт батман.* Дастан. *Ирләр кебек тимер күбә киеп, кылыч тотып, Койтыш-Алыпша да атасы янында торып сугышты.* Н.Фәттах. *Ирләр барысы да диярлек ат өстендә, ишек төбендәге сакчылар тимер көбәләрдән һәм булат кылычлардан, алар кыяфәтләре белән тирә-юньгә дәһшәт чәчеп торалар кебек...* Ф.Бәйрәмова

**тимер күлмәк** защитное одеяние. *Хан өстендә челтәрле тимер күлмәк, бил каешында кылыч, хәнҗәр, күзләре тулы кимсенү-сагыш.* М.Хәбибуллин

**тимер тун** *к.* **тимер күлмәк**. *Якасы алтын каю тун якалашса ертылмас; итәге алтын тимер тун итәктән тотса ертылмас.* Мәкаль. – *Куш-куш пычак асынган, Кушалыклап утау тектергән, Карагай буе ат менгән, Мең чүкечле тимер тун Билен бишкә тарттырган <...> Мөйтәннән туган Кыпчак би, Син бер кереп тулгачы! – дип иде...* Дастан

**тимер түбәтәй** *к.* **очлам**

**ТОМАРЧЫ́К** тупой наконечник стрелы для охоты

**ТОРА́** *к.* **тура**. *Берсе качучыларны эзәрлекли китте, икенчесе – янган торага ашыкты.* Н.Фәттах. *Ямгырчы би яши торган Шуран катаудан Болгар-торага нибарысы алтмыш-җитмеш чакрым ара иде.* Н.Фәттах

**ТОРАТА́Ш КАТ** встань смирно! – *Тик тор! Сакчы кебек тораташ кат!* М.Хәбибуллин

**ТОСНА́К** *к.* **туснак**

**ТОТКАВЫ́Л** 1) заградительный отряд; 2) застава; 3) служитель заставы; воин при заставе; часовой. *Шулай итеп, Себер дәүләте гөрләп яшәп ята, һәркем үз эшен белә – хан*

*хан урынында, ул илнең эчке һәм тышкы сәясәте өчен җавап бирә, бәкләр бәге Карача вәзир хөкүмәт эшләре өчен җаваплы, диван карарлар чыгара, ясавыллар ул карарларның үтәлешен тәэмин итә, поткавыллар чикне саклый, аталыклар хан балаларын тәрбияли, дин әһелләре милләтнең әхлагын кайгырта...* Ф.Бәйрәмова; 4) стражник у ворот. *Капуда торган поткавыл, Тоткавыллар белән сөйләшеп, Үтеп керде Норадын.* Дастан. *Тотакавыл китми, иреннәрен мелт-мелт иттереп, тик басып тора.* М.Әмирханов

**ТОТКЫ́Н** 1) пленение. *Тоткыннан котылам дип утка кермә.* Мәкаль. *Болар, тоткын булып яшәүгә караганда, йорт өчен үлүне артык күргәннәр, шул уй белән орышка керешкәннәр иде.* Һ.Атласи; 2) пленный, пленник. *Бу мәлдә ул үзенең тоткын икәнлеген бөтенләй онытып җибәрде.* Н.Фәттах; 3) неволя, плен, тюрьма

**тоткын итү** пленить, брать (взять) в плен; делать/сделать пленным. *Беркөн шулай өзелеп сайраганда Сандугачны тоткын иткәннәр.* А.Алиш. *Иванның атасы Василийны да Мәхмүдәк хан тоткын иткән булган ич.* М.Әмирханов

**ТОТКЫНЛЫ́К** неволя, заключение, заточение, плен. *Үрбәт бикә тоткынлыкның ачысын бик яхшы белә иде.* М.Әмирханов. *Тоткынлыкта язган әсәрләре аның русча иҗат ителгән.* Ф.Яруллин

**ТОТСА́К** *к.* **туснак**. *Норадынның Кадыйрбирде кулына тотсак булганы.* Дастан

**ТОТСЫ́К** *к.* **туснак**

**ТОТЫ́К** заложник. *Мин үзем олуг углым Мәхмүдне, янымдагы бәкләрем дә үзләренең угылларын сездә тотык (рәһен) итеп калдырамыз.* Г.Исхакый. – *Юк, син аның тоткыны түгел, тотыгы, – диде Торымтай төзәтеп.* Н.Фәттах

**ТОТЫКЛЫ́К** положение заложника. – *Күрән би тотыклыкка сиңа башка углын бирер, – диде бикә.* Н.Фәттах

**ТӨБӘ́Ү** целить, целиться, прицеливать/прицелить, направлять/направить (*оружие*). *Ул бик тиз, бик туры төбәде.* Н.Фәттах. *Ә алар әнә аякка басу гына түгел, үзләре ажгы-*

*рып өскә киләләр, инде мылтыктан да, туплардан да курыкмыйлар, төбәп аткан уклары белән казакларның кулларындагы коралларын бәреп кенә төшерәләр!* Ф.Бәйрәмова

**ТӨ́З КАТ!** смирно!, стой смирно!; *чаг.* **үрә кату**

**ТӨЗӘГЕ́Ч** прицел; прицельное устройство

**ТӨЗӘ́Ү** прицеливаться; брать (взять) на прицел; наводить; *чаг.* **төбәү**. *Атлар, ярсып кешнәп, Искәр капкасына ташланды, аларга каршы кургаш ядрәләр очты, татар яугирләре аттан егылганчы шәһәр диварларындагы казакларга укларын төзәп өлгерде, нәтиҗәдә урыс һәм татар сугышчылары янәшә аудылар...* Ф.Бәйрәмова

**ТӨЗӘҮЧЕ́** *к.* **наводчик**. *Кайту белән приборны өченче орудие командиры һәм төзәүчесе Кардәшевкә бирде.* Х.Камалов. *Болар икенче пулемёт расчетының төзәүчесе Константин Стариков белән аның ярдәмчесе Газинур Гафиятуллин иде.* Г.Әпсәләмов

**ТӨКЕРТКЕ́Ч** *эвф.* пистолет; автомат

**ТӨЛЕ́К** фураж

**ТӨМӘ́Н** 1) темь, тьма (*десятитысячное войсковое подразделение*). *Йосыф бәк кулында төмән булмаса да, шуңа якын гаскәрдер.* М.Хәбибуллин. *Әгәр дә бу хәл дөрес булып чыкса, өч төмән белән дә кальганы алуы кыен булачак.* Г.Сәгъди; 2) темь (*1) административная единица, которая должна была предоставить десять тысяч воинов; 2) центр такой административной единицы*)

**төмән би, төмән бәге, төмән агасы** *к.* **төмәнбашы**

**ТӨМӘ́НБАШЫ** темник (*командующий десятитысячным войском*). *Олыс бие Барынны, Орыш бие Шарынны, Төмән башы Туйбакны, Аждарканнан Мулайны, Мөйтәннән туган Кыпчакны, Кәмалның углы Җанбайны, Тугыз ирен янга алып, Анда киңәш кылдырды...* Дастан. *[Хан:] Төмәнбашлары, меңбашлары, йөзбашлары, унбашлары, угланнар, гаскәрләр! Хәлемезне күрәсез.* Г.Исхакый. *Гаскәрбашы итеп Али солтанны билгеләделәр, төмәнбашларында Кашкар, Карача, Бегиш морзалар тора иде...* Ф.Бәйрәмова

**ТӨҢГЕ́Р** 1) бубен; 2) барабан

**ТӨФӘ́НГ** ружье, винтовка

**ТӨФӘ́Ң** *к.* **төфәнг**

**ТРОФЕ́Й** трофей; *чаг.* **улҗа**. *Мифодий трофей сигаретлар чыгарды, алар төтәтеп җибәрделәр һәм уйланып калдылар.* Х.Камалов

**ТУ́** боевое знамя; знамя всего войска. *Кушагын алып ту итеп, Анда мәйдан күтәрде.* Дастан. *Чыңгыздан калган кара ту, Кара туны кулга алып, Яу кырганын карачы, Хан түрдәй утырып, Дау кырганын карачы!* Дастан

**ту кадау (тегү)** втыкать/воткнуть знамя; ставить знамя в знак объявления определённого места центром *чего-л.*

**ту киңәш** военный совет, совещание в ставке (*у главного знамени*). *Дүртәү-бишәү бер булып, Әүвәлгедәй безнекеләр Ту киңәшкә килсә иде!* Дастан

**ТУБЫКА́** наколенник

**ТУБЫЛДЫРЫ́К** наколенник (*боевой лошади*)

**ТУ́Г** *к.* **ту**

**ТУКЫ́Ш** *к.* **сугыш**. *Туйгуҗа улы Туктамыш Тукыш белән хан булды...* Дастан. *Чирүе белән шәһәрнең каршысына килеп, урын казып яттылар, орыш-тукыш кылмадылар.* Риваять

**ТУ́Л** боевой конь

**ТУЛГА́** шлем

**ТУЛПА́Р** боевой конь; хороший, сильный, выносливый и быстрый конь. *Ябаганы мактау белән тулпар булмас, ябалакны сыйпау белән шонкар булмас.* Мәкаль. *Алпарына күрә тулпары.* Мәкаль

**ТУМА́Н** *к.* **төмән**

**ТУ́П** 1) пушечное ядро, артиллерийский снаряд. *Ук җитмәгән җиргә туп җитәр.* Мәкаль; 2) пушка, артиллерийское орудие. *Кара туп сөйрәп, гөрс итеп, Азамат ир Туктамыш Каладан чыгып туктады.* Дастан. *Күчем Бохарадан утлы таяклар да кайтартып карады, Кырымнан туплар*

*соратты, әмма аларга да даими рәвештә дары, ядрә кирәк булып чыкты.* Ф.Бәйрәмова. *Аннары кирмән эчендәге мылтыклар, туплар – барысы да аның сугышчылары кулында.* М.Хәбибуллин

**тупка тоту** обстреливать снарядами; подвергать/подвергнуть артиллерийскому обстрелу. *Мәскәү, Ленинград шәһәрләрен тупка тоткан немецларны хәтерләп, Берлинга килеп җиттек без.* Г.Кутуй

**ТУПЛА́Н** конный отряд; конный строй; конница. *Тай менсәң, тупланга кермә.* Мәкаль

**ТУПЛА́У** сбор. *Казнадагы бар булган байлыкны гаскәр туплауга, корал алуга тотабыз.* М.Хәбибуллин. *Котыптан алып кыпчак далаларына кадәр ханлык өчен ясак җыюны тәэмин итү алар эше иде һәм сугыш булган очракта гаскәр туплау да шушы морза-бәкләргә йөкләнгән иде.* Ф.Бәйрәмова

**ТУПЛЫ́** с пушкой (пушками); имеющий пушку (пушки). *Чириковның унбиш-унсигез туплы корабы моңардан күпкә калыша иде.* И.Хуҗин

**ТУПЧЫ́** артиллерист, пушкарь. *Хак, тупчылар арасында татарлар да бар.* М.Хәбибуллин

**ТУРА́** (*передвижная*) осадная (*штурмовая*) башня (*для осады городов*); 2) передвижная стена (*как защитное сооружение*)

**ТУРКА́** ватная броня рыцаря (*обшитая шёлком*); ватная подстилка шлема

**ТУСНА́К** пленный раб; пленник. *Ул [Күчем батыр] болай да ярсулы, ә чакырылмаган көенчә ишектән атылып кергән егетнең кыйланышы түземлеген тәмам корыткан иде. – Хәзер туснаклар илә бишектәге сабыйларның гына безне өйрәтәсе калды.* В.Имамов

**ТУЧЫ́** хорунжий; знаменосец. *Ак сарайда балчымын, Ана Иделдә салчымын, Әчтерханда тучымын, Кыр-далада уенчымын.* Дастан

**ТҮБӘТӘ́Й** железный шлем, надеваемый под шапку

**ТҮТӘ́** приклад (*ружья*). *Тикшерүченең гадәте – пистолет түтәсе белән башны төю.* Г.Әпсәләмов

**ТЫ́ЙГ** кылыч. *Үз эшедер, һәр кешея уграян, Кәнде тыйгыдыр вөҗүден туграян.* Мөхәммәт Әмин. *Бәс, ул дәм, тәкбир әйтеп уграштылар, Тыйг орып, баш кисүбән, качтылар.* Мөхәммәт Әмин

**ТЫ́Л** тыл. *Бүген Язучылар союзында башка частька газета эшенә күчәргә яки тылдагы подразделениеләрдә калырга тәкъдим иткәннәр иде, уйлап та тормыйча баш тарттым.* Г.Кутуй

**ТЫЛЧЫ́** тыловик (*военнослужащий, работающий в тылу*)

**ТЫША́У** оковы; *чаг.* **богау**

**ТЬЮ́** *подражание свисту пули*
**тью итү** просвистеть (*о пуле*)

# У

**УГЛА́Н** воин гвардии, гвардеец. *[Хан:] Төмәнбашлары, меңбашлары, йөзбашлары, унбашлары, угланнар, гаскәрләр! Хәлемезне күрәсез.* Г.Исхакый. *Җәй урталарында җыен булды һәм бәкләр, һәм морзалар, һәм тарханнар, һәм угланнар, һәм имам-хатипләр Үтәмеш Гәрәйне хан итеп ак киездә күтәрделәр.* М.Хәбибуллин

**УЕ́М** прорезь (*в прицельном приспособлении огнестрельного оружия*). *Төзәгеч уемы* прорезь прицела

**У́К** стрела. *Аткан ук кире кайтмый.* Мәкаль. *Бер ук ике кошны үтермәс.* Мәкаль. *Җантимернең биш угыл – Бишенә дә баш булды. Алтысында ат менде, Җидесендә җәй тартып, Җиде тотам ук атты.* Дастан. *Татарларның хәтта тимер көбә бөҗраларын өзә торган дүрткырлы уклары да бар иде, шуңа күрә урыс сугышчыларын тимер киемнәре дә саклап бетерә алмады.* Ф.Бәйрәмова
**уктан алу** *к.* **укка алу**. *Җангали хан ике төлкене уктан алды.* М.Хәбибуллин

**укка алу** застрелить из лука. *Олуг кенәз өч пошины укка алган.* М.Хәбибуллин

**ук очы** *к.* **башак**. *Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казып тикшергәндә кылыч, сугыш балтасы, кистән, ук һәм сөңге очлары, дошманның атлы гаскәр һөҗүм итеп килгәндә аяк астына ташлау өчен өч япьле чәнечкеле тимерләр, типке (шпора), көбә, шишәк кебек барлык төр кораллар һәм хәрби киемнәр дә табыла.* Р.Фәхретдинов

**ук савыты** *к.* **уклык**

**УК-ҖӘ́Я** *җый.* оружие, вооружение. *Килсәң, миңа ук-җәя китерәсеңме? Булса – кылыч?* Н.Фәттах. *Ә анда, җиңел каекларда, Күчемнең шәхси гаскәре Искәрне саклый, яр буйларында исә ук-җәя аскан атлы татарлар да күренә.* Ф.Бәйрәмова. *Мине аерым хөрмәтләп, алар [башкортлар] миңа ук-җәя бүләк иттеләр, мин аны камин өстенә элеп куйдым.* Р.Зәйдулла

**УКЛЫ́К** колчан; *чаг.* **садак**. *Шунда ук агулы уклар белән тулы ике уклык, җәя ята иде.* Н.Фәттах

**УК-САДА́К** *җый.* оружие, вооружение. *Искәндәр үзе дә һәрчак Җангалигә ярарга тырышты, аның ук-садагын тотып йөрде, кайчак хәтта туфракка төшеп түбәнсенде.* М.Хәбибуллин

**УК-САНА́Й** *к.* **ук-садак**. *Янәшә каеклардагы сакчы татар яугирләре ук-санайларын киереп тоттылар...* Ф.Бәйрәмова

**УКЧЫ́** стрелок, лучник. *Укчы тидерә алмаганга, ук гаепле түгел.* Мәкаль. *Капка тирәсендә төркем-төркем укчылар, сугышчылар тора, сөйләшәләр, көлешәләр.* М.Хәбибуллин

**УЛА́Н** *к.* **углан**

**УЛҖА́** трофей, военная добыча. *Артык улҗа башка имгәк.* Мәкаль. *Ачкүз улҗа өчен үлә, көнчел көнләве белән бөлә.* Мәкаль. *Качкан яуның улҗасы юлда калган.* Мәкаль. *Яманга улҗа төшсә, өләшә алмый җаны чыгар.* Мәкаль. *Ханәкәдәй күреклене, Көнәкәдәй сылуны Тәңре үзе миңа биргәндә, Тиген (буш, түләүсез) улҗа кылганмын. Кисмә-кисмә сары алтын, Мөһер суккан саф алтын, Энҗе-гәүһәр, якутны Халкыма мин барын Кисеп улҗа кылганмын!* Дастан. *Ханәкәдәй аруны,*

*Көнәкәдәй сылуны, Йәникәдәй бикәчне Ат өстенә мендереп, Алсу йөзен сулдырып Тиген улҗа кылыр ул.* Дастан. *Касмак калмык түрәсенең унсигез яшьлек бер хуп җәмаллы кызын улҗа кылып тотып алган да, <...> үзенең бертума агасы Исәнмәтне алып килеп, кызны янында калдырган.* Риваять

**У́НБАШЫ** десятник. *[Хан:] Төмәнбашлары, меңбашлары, йөзбашлары, унбашлары, угланнар, гаскәрләр! Хәлемезне күрәсез.* Г.Исхакый. – *Унбаш Сәпәй, минем бу сәүдәгәрне каядыр күргәнем бар.* М.Хәбибуллин

**У́Р** 1) вал (*со рвом*). *Тышкы яктан койма буйлап өч кат тирән ур казылган, ур кырыйларында очлы башлы юан казыклар утыртылган иде.* Н.Фәттах. *Ханлыкның башкаласы Искәр дә кат-кат урлар белән, таш һәм агач ныгытмалар белән чорнап алынды.* Ф.Бәйрәмова; 2) копаный ров; окоп; глубокая канава; *чаг.* **хәндәкъ**

**УРА́** ура (*боевой клич при атаке*). *Бөтен халык «ура» кычкырды.* М.Мәһдиев

**УРА́Й** 1) *к.* **ур**; 2) крепостной вал

**УРАТУ́** окружать/окружить

**уратып алу** *к.* **урату**

**УРА́У** окружать/окружить

**урап алу** *к.* **урау**

**УРДА́** 1) ставка хана. *Күп тә үтмәде, басмалар буенча би үзенең урдасына кайтып керде.* Н.Фәттах. *Казаяклар өчен Күгән би үз урдасында киез өйләр кордырды, казан асарга дип бер көтү сарык бирде.* Н.Фәттах; 2) армия, войско. *Кашыклап җыйган малыңны, Чүмечләп чәчеп бетәр ул. Бар урдаңны алыр ул.* Дастан. *Сансыз татар урдам бар, Алтын егач тәхетем бар.* Дастан

**У́Т** огонь; стрельба, пальба

**ут ачу** открывать/открыть огонь. *Назимов аны туктатмакчы булып артыннан йөгерә башлаган иде, вышкадан ут ачтылар.* Г.Әпсәләмов

**ут ноктасы** огневая точка. *Мөниржаннарның танкы дошманның әллә ничә ут ноктасын изде, пехотасын*

*кандала урынына сытты, пулемёттан кырды.* Н.Әхмәдиев

**утка тоту** обстреливать/обстрелять из огнестрельного оружия. *Бар халыкны утка тотып, кырып-seбереп, яндырып һәм үтереп алачак алар Себерне, ул чагында да халык сиңа рәхмәт әйтмәячәк!* Ф.Бәйрәмова

**УТЛЫ КОРА́Л** огнестрельное оружие. *...Әмма хәзер заманы башка, утлы корал заманы, мәкер заманы.* Ф.Бәйрәмова

**УТЧАГЫ́Р** пушка; *чаг.* **туп**. *Гавер аткан утчагыр Күкрәгенә батмаган, «Утчагыр алмас» батыр дип, Даны йортка таралган – Аны күргән картыңмың.* Дастан

# Ү

**ҮЗАТКЫ́Ч** самострел. *Гомумән, һәр көймә, һәр казак корал белән бик нык тәэмин ителгән иде, алар үзләре белән Уралга мылтыктан башлап үзаткычын, пищален, аркебузын, балта һәм кылычын, ук һәм җәясен – барысын да алып килгәннәр иде.* Ф.Бәйрәмова

**ҮЛҖӘ́** *к.* **улҗа**

**ҮРӘ́ КАТУ** стоять/стать по стойке смирно. *Сержант Тимербаев, яшен тизлеге белән гимнастёркасын, каешын рәтләп, үрә катып калды һәм көр тавыш белән рапорт бирде.* А.Әхмәт

# Ф

**ФЕТНӘ́** бунт, мятеж; волнения, беспорядки *күп.*; смута. *Фетнә була, Казанда урысларны кыралар, күбесе кача әлбәттә, яшеренүчеләр дә булгандыр, чөнки татар халкы күп кенә урыслар белән туганлашкан, аркадаш яшиләр иде инде.* М.Хәбибуллин

**фетнә салучы (таратучы)** *к.* **фетнәче**

**фетнә чыгу (кубу)** подняться, вспыхнуть (*о мятеже, смуте*)

**ФЕТНӘЧЕ́** бунтовщик, мятежник; смутьян. *Василий кенәзне фетнәчеләр юк иттеләр, Морозны исә тапмадылар.* М.Хәбибуллин

**ФИЛТӘ́** фитиль. *Динамит филтәсе буйлап яндырылган шырпының ялкыны үрмәләде.* А.Алиш

**ФИЛТӘЛЕ́** фитильный. *Филтәле мылтык* фитильное ружьё

**ФЛА́НГ** фланг; *чаг.* **кул, канат**. *Безнең сугышчылар фрицның сул флангысынарак төшеп ата башладылар.* Х.Камалов

**ФРО́НТ** фронт. *Шул чигенүдән оборонага күчеп, җиргә ябышып каршы торып, фронт сызыгында Курск дугасы дигән оборона урыны килеп чыга да инде.* З.Зәйнуллин

**ФУГА́С** фугас. *Танкның нәкъ алдына тиз-тиз өч фугаслы снаряд атты һәм шактый тирән чокырлар ясап куйды.* Х.Камалов

# Х

**ХАКА́Н** каган

**ХА́Н** хан

**хан гаскәре** дружина хана. *Бу – хан гаскәренең башлыгы Мөхәммәткол яугирләре иде.* Ф.Бәйрәмова. *Хәсән белән Хөсәен шул бәрабәргә үз кешеләре, үз атлары, үз кирәк-яраклары белән хан гаскәренә теркәлә.* М.Әмирханов

**ХА́СМ** *к.* **хәсым**. *Хур күрмә хасмеңне, әй бихәбәр, Кечечекләр чук олугларны екар!* Мөхәммәт Әмин

**ХӘМЛӘ́** нападение, атака; штурм, бросок. *Бу форсатта урыс ханнары Казанга күп хәмлә кыла башладылар.* Риваять

**ХӘНДӘ́КЪ** ров (*вокруг крепости, нередко заполненный водой*). *Шәһәрне саклаучылар янып торган шәһәрнең утын сүндерергә ташланганнар һәм хәндәкътән киткәннәр.* Риваять

**ХӘНҖӘ́Р** кинжал. *Яуга салсаң – хәнҗәрең, дауга салсаң – чәчәнең.* Мәкаль. *«Димәк фетнә буласы», – дип уйлады ул һәм ни сәбәптәндер күкрәгенә хәнҗәр кадалган воеводны*

*күз алдына китерде.* М.Хәбибуллин. *Хан тирәсенә аның уллары, якыннары, морза һәм бәкләре, карача һәм сәедләре тезелеп баскан, тәхет янында да, ишек төбендә дә хәнҗәр һәм сөңгеләр тоткан яугирләр сакта тора.* Ф.Бәйрәмова

**ХӘРБИ́ 1.** *с.* 1) военный, воинский. *Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казып тикшергәндә кылыч, сугыш балтасы, кистән, ук һәм сөңге очлары, дошманның атлы гаскәр һөҗүм итеп килгәндә аяк астына ташлау өчен өч япьле чәнечкеле тимерләр, типке (шпора), көбә, шишәк кебек барлык төр кораллар һәм хәрби киемнәр дә табыла.* Р.Фәхретдинов. *– Әй, кем бар анда, минем хәрби киемнәрем килтерегез!* М.Хәбибуллин; 2) боевой, строевой. **2.** *и.* военный, военнослужащий. *Икенчедән, хәрбиләр өчен киң мөмкинлекләр ачыла.* Р.Зәйдулла

**ХӘСЫМ** враг. *Әгәр бу дәрттән үлсәм, Мәхбүбәмнән гайре мәнем хәсымым юк.* К.Насыйри

**ХИСА́Р** цитадель. *Хан сорады: «Каланың хисары астына берәүне-берәүне салдыгызмы?» – диде.* Риваять. *Казанның крепость хисарында унике капкасы бар һәм крепость хисары бу замандагы крепостьтан зуррак булгандыр.* К.Насыйри

**ХИ́СН** *к.* **хисын**. *Хәйбәрнең хиснен ачарса, ул ачар, Аннан үзгә кемсә кылмас моңа чар.* Мөхәммәт Әмин

**ХИСЫ́Н** крепость, цитадель, твердыня

# Һ

**ҺӘДӘ́Ф** мишень. *«Ләтаиф риваятьнең» әүвәлге җөзләре халыкларның тәгъриз вә тәгънәләренә һәдәф булды.* Р.Фәхретдинов

**ҺИҖА́** сугыш. *Укы, Максуди аның мәдхене син, Ул торар чөн сәрафраз әнҗүмин, Сәрвәре мәйдан, һиҗа ул торыр, Камыг ахшам әгда ул торыр.* Мөхәммәт Әмин

**ҺӨҖҮ́М** нападение, наступление, атака, штурм; налёт, набег; приступ, удар. *...Әрсез калмыкларның эреле-ваклы һөҗүмнәрен кире кагарга урман-далада гайрәтле татарлар җитәрлек иде...* Ф.Бәйрәмова. *[Шаһгали хан] Берничә тап-*

*кыр Казанга яу йөрде, һөҗүмдә һәрчак алда булды, ягъни үз канкардәшләренә кул күтәрде.* М.Хәбибуллин

**һөҗүм итү** нападать/напасть, наступать, атокавать, штурмовать, совершать/совершить набег; ударять, ударить; наваливаться, навалиться. *Кяферләр аларга бертуктаусыз һөҗүм итеп торалар.* М.Хәбибуллин

# Ц

**ЦЕ́ЛЬ** цель. *Әнвәр тагы төзәде, тагы атты, әмма барыбер цельгә тидерә алмады.* Х.Камал

# Ч

**ЧАБУ́** рубить, отрубать/отрубить, разрубать/разрубить, сечь. *Атымның аягына ук керде дә ат сискәнеп сикерде, мин дә егылдым, торып өлгерә алмадым, бер урыс кылыч берлә салдырды, ат калды, китә идек, калканымны тотып өлгердем, алай да аягыма чапты, киез итек булмаса, аяк киткән иде.* Г.Исхакый. *Аңа каршы чәчән ниндидер өн чыгарды, Тотышка төртеп күрсәтә-күрсәтә, чандыр кулы белән селтәнеп-селтәнеп алды – аның бу селтәнүен кылыч белән чабу, сөңге белән кадау дип аңларга була иде.* Н.Фәттах

**чабып өзү** отрубить, разрубить, отсечь. *Кылыч белән чабып өзү* разрубить мечом

**ЧАВЫ́Ш** 1) офицер охраны дворца. *Күпер авызында тыгыз койма булып торган атлы чавышлар атларны, кешеләрне салга икешәрләп кенә, билгеле бер ара саклап кына керттеләр.* Н.Фәттах; 2) офицер полиции. *Кашыңны җыерма! Әнә юл буенда чавышлар карап тора!* Н.Фәттах

**ЧАГДАВЫ́Л** *к.* **аркавыл**. *...Унҗиде ир җитеп килгәндә Йосынчының ирләре: Ясавылдан ясавыл, Тоткавылдан тоткавыл, Иравылдан иравыл, Чагдавылдан чагдавыл, Бөкәвелдән бөкәвел – Башына дөнья тар булды, Атланып чүлгә таралды.* Дастан. *Үзенең өен, олауларын, терлек-туарны*

*сакларга ул урта кул белән сул кулны, чагдавылны калдырырга булды.* Н.Фәттах

**ЧАКМА́** 1) замок (*кремнёвого ружья*); 2) боёк. *Тик чакмага басарга өлгермәдем, шартлау яңгырады.* А.Вергазов. *Чакма капсульгә бәрелде* боёк ударил по капсулю

**ЧАКМАЛЫ́** кремнёвый; с кремнием. *Чакмалы мылтык* кремнёвое ружьё

**ЧАПКАЛА́У** перерубать, разрезать. *Әле Строгановларга ялланганчы ук, 1581 елның августында, Самара елгасы буенда урыс илчесе Пепелицын күз алдында ул үзенең казаклары белән нугай илчесен һәм аның өч йөз кешесен чапкалап, тураклап ташлаган иде [Иван Кольцо].*Ф.Бәйрәмова

**ЧА́СТЬ** часть (*войсковая единица*)

**ЧӘРИ́** *к.* **чирү**. *Таңда керәм каһр илә мәйдана мән, Буяям җаду чәрисен кана мән.* Мөхәммәт Әмин. *Бәс, торып иман китерде нәгәзир Ил, вилаять, ләшкәре һәм бикләре – Мөэмин улды. Һәм янә – җөмлә чәри.* Мөхәммәт Әмин. *Юк, торырсән, бу эшә чикмә әмәк, Бу чәрия вирә белмәзсән йимәк.* Мөхәммәт Әмин

**ЧЕРЧЕ́Т** орда, враждебное полчище

**ЧЕ́СТЬ БИРҮ** отдавать честь; козырять

**ЧИГЕНЕ́Ш** отступление

**ЧИГЕНҮ́** **1.** *ф.* отступать, отступить. *Фронт сызыгының бу якларга да якынлашып килүен, Колчак бандалары кысрыклавы нәтиҗәсендә безнең гаскәрләр чигенергә мәҗбүр булуын Миңнулла белә иде.* В.Нуруллин. **2.** *и.* отступление. *Ләкин М. Гафуриның бу зарлану һәм өметсезлеге аның корал ташлап чигенүен һич тә аңлатмый.* М.Җәлил

**ЧИГЕ́Ш** *к.* **чигенеш**. *Хәзер артка чигеш юк инде!* Р.Батулла

**ЧИДА́** *к.* **чыда**

**ЧИ́К** граница

**чик сакчысы** пограничник. *Шулай ук Дурдының чик сакчысын үтерүе, илгә эшләгән пычрак эшләре ике урында әйтелә.* Ф.Яруллин

**ЧИ́Н** чин (*звание, ранг*). *Газеталар тагы баллар хакында, генералларның чин алулары хакында яза башлады...* Я.Абдуллин

**ЧИРҮ́** войско; *чаг.* **гаскәр**. *Чыңгыздан килгән кара ту – Кара туны күтәртеп, Чирүен әйдәп атлатып, Кара туп сөйрәп, гөрс итеп, Азамат ир Туктамыш Каладан чыгып туктады.* Дастан. *Акбеләк кыз анда әйтте: <...> Сине миңа ир кылыр, Чирүенә баш кылыр, Ни сорасаң – ул бирер!* Дастан. *Аны әйтеп, Шаһ Тимер Сырлатып хат яздырды. Ерагына хат юллап, Якынына ат юллап, Чирүен җыеп алдырды.* Дастан. – *Сарайның куылган ханы Мөхәммәд чирүе белән Казанга якынлаша...* Р.Зәйдулла. *Чирүнең күпчелек өлешен Алмыш хан шулай да үзе белән яуга алды.* Н.Фәттах

**ЧОЛГАНЫ́Ш** окружение, блокада; *чаг.* **камалыш**. *Ермак моңа бик сөенде, чөнки чолганышта ачтан үлүгә караганда, ничек булса да хәрәкәт итә алу аның өчен бик мөһим иде.* Ф.Бәйрәмова

**ЧОЛГА́У 1.** *ф.* окружать/окружить, осаждать/осадить. **2.** *и.* окружение, осада, блокада

**чорнап алу** окружать/окружить, осаждать/осадить. *Бары тик Казанны Явыз Иван гаскәре чорнап алгач кына казанлылар үзләренең ялгышларын аңладылар, әмма соң иде инде.* Ф.Бәйрәмова

**ЧУКМА́Р** булава, палица. *Чукмарны ора алмаган – үзенә тигезер.* Мәкаль. *Инеп күренеш итмәмен Иңсәмә имән чукмар тигәндә!* Дастан. *Айбалталы Дөрмән би, Кынабы юк бер кылыч, Сабы чыккан бер чукмар Норадынга апкилде.* Дастан. *Көтмәгәндә Урал буйларында татарларның атлы гаскәре күренде, алар барысы да кылыч һәм сөңге белән коралланган, билләренә айбалта һәм чукмарлар аскан, һәрберсенең җилкәсендә ук-санайлары, җәя-садаклары беркетелгән иде.* Ф.Бәйрәмова. – *Чукмарыңны ясап бетердеңме? – Ясадым. Әйбәт булды. – Матур итеп ясарыңа шикләнмәдем дә мин. Башына чәнечкеләр куярга онытмадыңмы?* М.Хуҗин

**ЧУКМАРБА́Ш** *к.* **чукмар**. *Ходайколның кулыннан корал төшмәде. Уктан төз атты, кылыч белән орышырга тиң*

*табылмады, сөңгене кеше күзенә ыргытыр, хәнҗәр атар, ике кулына ике чылбырлы чукмарбаш тотып, йөзләрчә дошманга каршы торыр иде.* М.Хәбибуллин

**ЧУРА́** 1) дружинник, воин в княжеской дружине; 2) отрок, молодой воин в качестве слуги у знатного лица. – *Әй егетләр, чуралар! – Урманбит би үлгәндә, Ун сан нугай бөлгәндә...* Дастан; 3) военачальник

**ЧЫДА́** копьё, пика

# Ш

**ША́Й** 1) *к.* **шайман**. *Ат өстеннән алыштылар, һәрберенең шайлары өзелде, кораллары уалды.* Дастан; 2) снаряжение. *Би углына монда ни калган? Кая атың, кая шаең?* Н.Фәттах

**ШАЙЛАНУ́** снарядиться. *Моны белгәннән соң ике мәргән шайланып яуга чыктылар. Савыт киеп атышырга чыктылар.* Риваять

**ШАЙМА́Н** доспехи *күп.*; латы *күп.* *Ат шайманы* боевое снаряжение коня. *Бырлас улы Шаһ Тимер Шайманы белән шаһ булды...* Дастан. *Тимгел чуар атым бар, Шул атыма мением, Шайман таккан сыным бар, Шайман тагып килием.* Дастан

**ША́Ң** доспех, изготовленный из цельного металла. *Хан сарайга килгәндә, Хансарайның ишеген Каһәр белән ачып кергәндә, Тимердән суккан шаң киеп, Вәзирләр белән куршаның Түрдә утырган Кыйгырчык – Аны күрде Идегәй.* Дастан

**ШАРТЛА́У** 1) взрываться/взорваться; 2) стрелять, производить/произвести выстрелы. *Кылыч белән дә орышалар, уктан да алышалар, мылтык дигәннәре дә бар, яман шартлый үзе, колакларны тондыра менә, туплары да бар.* М.Хәбибуллин

**ШӘМШИ́Р** кылыч. *Варды ул кыз чен Галинең касдына, Каһр итеп, шәмшир алубән дәстенә.* Мөхәммәт Әмин

**ШӘРӘФӘ́** зубец крепостной стены

**ШӘҺИ́Д** шахид (*мученик, павший в священной войне*). *Янә пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Галимнәрнең язу яза торган карасы вә һәм шәһидләрнең каны кыямәт көнендә үлчәнер: катибләрнең карасы шәһидләрнең канына бәрабәр килер», – диде.* К.Насыйри

**ШӘҺИ́Т** *к.* **шәһид**. *Газилар өстән, шәһитләр астан юл таба, ди.* Мәкаль. *Батырлар тау башында туган илләре өчен тамчы каннары калганчы көрәшергә кан эчкәннәр һәм дошманнар өстенә ыргылып, тигезсез сугышта шәһит булганнар.* Риваять

**ШЕРЕ́НГА** шеренга. *Хәкимҗан очып-кунып шеренгаларны тигезләп йөрде.* М.Мәһдиев

**ШИШӘ́К** шишак. *Аларның төп кораллары: ук һәм җәя, кылыч һәм балта, кистән һәм сөңге, калкан, шишәк һәм көбә күлмәк.* Р.Фәхретдинов

**ШЛЕ́М** шлем. *Ермак сугыш кырында бер татар яугиренә аеруча игътибар итте, ул өстенә тимер көбә, башына очлы шлем кигән һәм үлем мәйданында карчыга кебек очып йөри иде.* Ф.Бәйрәмова

**ШО́МПОЛ** шомпол. *Теге Варшау янындагы сугышта полякларга плен төшеп, арт ягына илле шомпол алып, качып кайткан Котбетдин Хисаметдиновмы?* Т.Гыйззәт. *Мылтык көпшәсен шомпол белән чистарту* чистить ствол ружья шомполом

**ШО́МПОЛЛАУ** чистить (почистить) шомполом (*канал ствола ружья*)

**ШТУ́РМ** штурм. *Штурм башланырга әле бер сәгать чамасы вакыт бар иде.* Г.Әпсәләмов

**ШТЫ́К** штык. *Теләсә, атып үтерә, теләсә, штык белән чәнчи.* З.Зәйнуллин. *Штык сугышы* штыковой бой

**ШУРПАЧЫ́** чорбачи (чорбаджи), снабженец в войсках

**ШЫБЫ́Н** шомпол. *Аны бит мылтык шыбыны белән суктырганнар иде.* Т.Гыйззәт

**ШЫГАВЫ́Л** ишек сакчысы. *Хан сарае ак ишек, Бер ишектә Аңгысын, Бер ишектә Тыңгысын – Ике торган шыгавыл, Туктамыш хан колы иде.* Дастан. *Туктамыш: Кичә ишегемдә торган шыгавыл бүген сараема кереп, миңа бирелергә куша!* Н.Исәнбәт

# Ы

**ЫРГА́К** зацепка (*лука*)

**ЫРГЫТУ́** метать/метнуть, кидать/кинуть, бросать/бросить. *Ат өстендә кылыч айкау, сөңге ыргыту, төз ату ярышларында да Сак олан хата җибәрмәде.* Р.Батулла

**ЫСТА́Н** стан, ставка. *...Искәрдән тыш, ханның үзенең берничә каласы, туктар өчен ыстаны, җәйләү вә кышлау урыннары бар...* Ф.Бәйрәмова. *Алар безнең халыкка моңа кадәр булмаган ясак салачаклар, чибәр хатын-кызларыбызны хан ыстаннарына җыеп алып китәчәкләр.* М.Хәбибуллин

# Э

**ЭЛӘГУ́** попадать/попасть (*в цель*). *Исән вакытында, ул хакта сүз чыкканда: «Чоңгылына ук эләкмәгәнмендер инде?» – дип кенә куя иде.* Ф.Яхин

**ЭЛУ́** нацепить, натянуть (*стрелу на лук*). *Азамат егетләр җәяләренә укларын элделәр, әммә Сафа Гәрәй хан янә кулын күтәрде.* М.Хәбибуллин

# Ю

**ЮВАРИ́** военный муж, воин. *Миңа я кылыч, я хәнҗәр кирәк. Мин ювари булам.* А.Тимергалин

**ЮЛБАСА́Р** захватчик, агрессор. *Ояты юк сатлык юлбасарның, Бүген менә йөзе ачылды.* Һ.Такташ. *Ул юлбасарлар арасында өч меңе кенәз Родослав ирләре булганлыгын да беләм.* Н.Фәттах

# Я

**ЯВЫ́Р** *к.* **яугир**; *Күкрәге яулы үссен дип, Качкан яуны кудырды, Яуда явыр булсын дип, Яуны бергә кыдырды.* Дастан. *Күңаталтак киеп күн итек, Җайдак менгән сыбайның, Җәяүләп төшкән явырның, Исәбе-саны булмады.* Дастан

**ЯГЫ́** *к.* **яу**. *Мөсхәф алып әлемдән дагытыр, Кубарып биртәр санасын, ягыдыр.* Мөхәммәт Әмин. *Утташ камны ул үзенең бабасы буларак кына түгел, ыруда беренче урынны яулар алырга, ыру башы булырга омтылучы көндәше, ягысы буларак та күралмады, шулай да түзде.* Н.Фәттах. – *Кем йортын үз кулы белән ягыга бирә? – дип кычкырды ул [Илбәк]...* Р.Зәйдулла

**ЯГЫ́** *к.* **җәя**. *Әртишнең биек ярына агынып, агач төбендә чукыну урынына килеп чукына башлаганда, бараба халкының иң оста, төз атучысы ягыдан Ярмакның маңгаена аткан.* Риваять

**ЯДРӘ́** 1) ядро, дробь (*для ружья*); 2) ядро, артиллерийский снаряд. *Күчем Бохарадан утлы таяклар да кайтартып карады, Кырымнан туплар соратты, әмма аларга да даими рәвештә дары, ядрә кирәк булып чыкты.* Ф.Бәйрәмова. *Идел бозы астына киткән йөзләрчә туплары, ядрәләре, ат-чаналары, оста тупчылары хакында уйланырга да куркыныч.* М.Хәбибуллин

**ЯДРӘЛЕ́** дробовой

**ядрәле мылтык** дробовая берданка

**ядрәле снаряд** бризантный снаряд

**ЯЙ** *и.* **җәя**. *Таһир, йөзең ай икән, кара кашың яй икән.* Дастан

**ЯЛА́У** 1) маленький флажок или кисть на верхушке шапки у воинов как знак отличия; 2) *к.* **байрак**. *1938 елда җәй көнне Хәмит өч мәчетенең манарасына кызыл ялау элеп куйдылар.* Р.Батулла

**ЯНАРА́Л** *к.* **генерал**. *Ярман янараллары бала-чага өстендәге киндер күлмәкне дә ике малайга берне генә калдыргач, оклау*

*малай-шалайның баш түбәсенә куныйп йөдәтте.* Г.Ахунов. *Янараллар, әфисәрләр дүрәкмени?* М.Мәһдиев

**Я́Н** *к.* **җәя**. *Йиртөшлек, кара кошның оясына килде, янын алып, кара кошны йоклап ята торган оясында коргыннан-коргына үтә атты.* Дастан

**ЯНДАВЫ́Л** боковое охранение (*в боевом походе*)

**ЯНИЧӘРИ́** янычар, янычары

**ЯН-У́К** *җый. к.* **ук-җәя**. *Йиртөшлек янын-угын алып, киекне кара йөрәккә атты.* Дастан

**ЯНЫЧА́Р** *к.* **яничәри**. *[Сафа Гәрәй ханның сугышчылары] Сөләйман Кануниның данлы янычарларыннан бер дә ким түгелләр иде.* М.Хәбибуллин

**ЯРА́К** *к.* **корал**. *Җайлы көнне кунак юлыкмас, яраклы көнне яу юлыкмас.* Мәкаль. *Йөз көн ярак бер көн кирәк.* Мәкаль. *Ярагы барның җаны урынында, ярагы юкның җаны учында.* Мәкаль. *Яраклы көндә яу юлыкмас, эш бар көндә дус юлыкмас.* Мәкаль. *Яраклыга яу юлыкмас.* Мәкаль. *Яу юкта ярак күп, яу килгәндә таяк та табылмас.* Мәкаль. *Яу яуның ярагын белмәс.* Мәкаль

**ЯРАКЛАНУ́** вооружаться. *Аннан соң янә Болгар шәһәренә килергә яракланды, күп-күп катаргылар белән Болгар шәһәрен алырга менде.* Риваять

**ЯРАКЛА́У** вооружать/вооружить, оснастить оружием. *Ахырында, бик кыстый башлагач, чарасыз Ибраһим карт, унҗиде кешене яраклап атка атланды вә үзе дә, күсәккә таянып, анлар илә берлектә, җәяүләп, Пугачёв янына дип, Арча кырына китте.* Риваять

**ЯСАВЫ́Л** конный дозорный; ответственный за внутреннее спокойствие дворца. *Ясавыллар тотып Таһирны анда, Ки сандык эчрә салып мисле бәндә.* Дастан. *Шулай итеп, Себер дәүләте гөрләп яшәп ята, һәркем үз эшен белә – хан хан урынында, ул илнең эчке һәм тышкы сәясәте өчен җавап бирә, бәкләр бәге Карача вәзир хөкүмәт эшләре өчен җаваплы, диван карарлар чыгара, ясавыллар ул

*карарларның үтәлешен тәэмин итә, воткавыллар чикне саклый, аталыклар хан балаларын тәрбияли, дин әһелләре милләтнең әхлагын кайгырта...* Ф.Бәйрәмова

**ЯСАНУ́** вoружаться/вооружиться. *Көткәндә кунак кунмас, ясанганда яу килмәс.* Мәкаль. *Капкасы ябык таш кала, Аны юлда бер күрде, Әйләнеп илен тапмады, Ясаныл явын тапмады, Ачтан карны юрылды, Сусыздан бөере борылды, Адәм җитмәс кола чүл, Янәдән йөреп юл алды.* Дастан

**ЯСИ́Р** *к.* **әсир**. *Тик хатыннарыны Аксак Тимер ясир кылды.* Риваять

**ЯТАГА́Н** ятаган. *Болак буенда ук-җәя, корал-кылыч, ятаган-хәнҗәр саталар.* М.Хәбибуллин. *Себер урманында кәкре хәнҗәрнең дә кирәге чыга дип, шушы авыл кешесе бүләк иткән ятаганны фатирында калдырган була Рухан.* М.Хуҗин

**ЯУ́** 1) враг, противник; неприятель; недруг. *Ул яу микән, ил микән – Аны шунда сынаек.* Дастан. *Мондый чакта катау кешеләре, билгеле, яу килүен генә көтмиләр иде.* Н.Фәттах; 2) полчище, рать; нашествие. *Шулай итеп, билгеләнгән көнгә, мартның урталарында, татар явы Искәр ягына кузгалды.* Ф.Бәйрәмова; 3) бой, битва, брань. *Яу кырында баһадирларча сугышкан чыңгызлы Күчемне исә хан нәселе белән туганлаштырырга булдылар...* Ф.Бәйрәмова. *Сафа Гәрәй хан исән имин яудан әйләнеп кайтса, иншалла, таҗны киюгә ирешер.* М.Хәбибуллин

**яу башы** главнокомандующий. *Ул арада яугирләрнең йөгерешкәне, яу башларының әмер биргән тавышлары ишетелде.* Ф.Бәйрәмова

**яу чабу (йөрү) 1.** *ф.* ходить походом. *Аннан алар, коры җиргә чыгып, ат менделәр, болгарларга каршы яу чаптылар.* Н.Фәттах. *Себер һәрвакытта Казанның Мәскәүгә каршы булган көчләрен яклаган, урыска каршы Идел-Урал татарлары белән бергә яу чапкан.* Ф.Бәйрәмова. *Сезгә мәгълүм булса кирәктер, углан морзалар урыс җирләренә еш кына яу йөриләр.* М.Хәбибуллин. *Казан ханы Сафа Гәрәй ил калаларына яу чаба башлаган –*

*үч ала.* М.Хәбибуллин. **2.** *и.* военный поход; *Яу чабуны, шуннан табыш ясауны кәсепкә әверелдергән урыс кенәзләре, баярлары үз җирендә хезмәт итүдән, талап яшәүне кулайрак күрәләр.* М.Хәбибуллин

**ЯУГИ́Р** воин. *...Искәргә исә аның [Себер елгасы] аша салынган күпердән генә керергә мөмкин, ә ул татар яугирләре тарафыннан бик нык саклана.* Ф.Бәйрәмова. *Яугир ирләребез ничә заман Ак тирмәдә кылыч кайрады.* Ш.Бабич. *Болгар мөлселманныры, мескеннәр, күрше арларга күчеп китәргә мәҗбүр булдылар, тәмам яшәр әмәл калдырмадылар Мәңге Тимер хан яугирләре.* М.Хәбибуллин. *Егермеләп яугир, учак тирәсенә җыелып, ялкау гына ни турындадыр сөйләшәләр иде.* Р.Зәйдулла

**ЯУЛА́У 1.** *ф.* завоёвывать/завоевать, захватывать/захватить. *Магуллар Болгар каласын яулаганда аларның күбесе ут эчендә кала, магуллар китап кадерен белми, яуланган калада вәхшиләрчә кылананалар.* М.Хәбибуллин. **2.** *и.* завоевание, захват. *Әмма ил эчтән череп ятканда, ваба чире котырганда, халык ач һәм куркытылган булганда, нинди яңа җирләр яулау турында сүз булырга мөмкин?* Ф.Бәйрәмова. *Казан кешеләре аңа каршы торырга уйласа, кирмәнне яулавы җиңел булмаячак аңа [Сафагәрәй ханга].* Р.Зәйдулла

**яулап алу** *к.* **яулау**. *Аның турыдан-туры Себергә бәреп керерлек гаскәре дә, көче дә юк, ә яулап алу теләге көчле, бик көчле иде!* Ф.Бәйрәмова

**ЯУЛАУЧЫ́** завоеватель. *Ил-җирне басып алып, яуланган халыкны үз диненә көчләп керткән яулаучылар ешаеп бара.* М.Хәбибуллин

**ЯФРӘТИ́Л** *к.* **ефрейтор**. <...> *яфрәтил белән әфисәрләр бик яман.* Г.Бәширов

ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

Сүзлекнең төзелеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8

Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10

Татар алфавиты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10

Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11

Справочное издание

**ТАТАРСКО-РУССКИЙ СЛОВАРЬ
ВОЕННОЙ ЛЕКСИКИ**

Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать 11.10.2017 г.
Формат 60×84$^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman
Печать офсетная. Усл. печ. л. 6,5. Уч.-изд.л. 4,1. Тираж 600 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12